АБДУЛЛА АЛИШ

Сайланма әсәрләр

АБДУЛЛА АЛИШ

АБДУЛЛА АЛИШ

Сайланма әсәрләр

ӘКИЯТЛӘР, ХИКӘЯЛӘР, ПЬЕСАЛАР
ҺӘМ ШИГЫРЬЛӘР

ТАТКНИГОИЗДАТ
Яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе
Казан 1957

* * *

Төзүчесе
А. ӘХМӘТ

Редакторы
ХИСАМ КАМАЛОВ

Художниклары
П. ГРИГОРЬЕР, И. ИГЛАМОВ

* * *

УРТА ҺӘМ ОЛЫ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

ЯЗУЧЫ ҺӘМ КӨРӘШЧЕ

Абдулла Алиш!

Менә ул — тыйнак кына, атылып-сугылып кешедән алга чыкмыйча, иптәшен бүлдермичә, игътибар белән генә тыңлап тора. Шул арада барлык тешләрен күрсәтеп иркен генә көлеп җибәрә һәм син басынкы, кыюсыз кебек күренгән Алишны бөтенләй икенче яктан таный башлыйсың. Эре сөякле, тере һәм хәрәкәтчән бу кешенең үткен сүзле, кинаяле карашлы һәм шат күңелле икәнен белергә күп вакыт кирәкми. Ул гади генә вакыйга турында сөйләп китә, анда баш әйләндерерлек берни дә юк. Әйтик, берәү редакциягә шигырь китергән: шул гади хәбәргә Алиш мәгънәле генә бер сүз кыстыра һәм шул сүзнең тапкырлыгы сине хәйран калдыра, кинәт көлү кабындырып җибәрә.

Яки ул менә Феодосия шәһәрендә Айвазовский йортында булуын сөйли. Бөек рус художнигының даһи полотнолары аны шулкадәр дулкынландырган, шулкадәр йөрәгенә сеңеп калган — ул бу турыда сокланып, эчке бер моң белән сөйли. Аның сүзләреннән Айвазовскийның бөек талант көчен күз алдына китерәсең. Алиш аны сөйләгәндә үзе дә диңгезнең дәһшәтле легендаларын хәтерли төсле, ул сиңа да мәңге дулкынланып торган диңгезнең стихия көчен, серле тынлыгын сиздерә, шәфәкъ кызыллыгына манчылган дулкын очларын, болыт арасыннан караган ай нурларының ямансылап чагылуын җанландыра. Бөек художникның поэтик сәләтенә гашыйк булган Алиш, Айвазовскийга хөрмәт йөзеннән, үзенең улына Айваз исеме бирүен әйтә.

— Русча да, татарча да бертөрле языла, үзе җиңел, үзе матур,— ди ул, сүзенә йомгак ясап.

Ул шулай бик күп вакыйгалар, бик күп очрашулар истәлеге аша күз алдына килеп баса. Кайда гына булмасын, кайда гына очрашмасын,— ул киң күңелле иптәш, матур йөрәкле язучы, изге омтылышлы совет кешесе иде! Аның тормышны сөюе, киләчәккә ачык йөз һәм ышанычлы күз белән каравы, олы йөрәгенең җылысын балаларга өләшеп бирергә хәзер торуы һәрбер адымыннан сизелә иде. Әйе, ул балаларны аеруча сөя һәм барлык иҗатын аларга багышлый. Дөрес, моңа ирешүе җиңел булмый. Кечкенә дуслар өчен, киләчәк алмаш өчен зур әдәбият тудыру, ягъни аларны киң дөньяга алып чыгып, бай табигать белән таныштыру белән бергә, зур тормышка хәзерли торган әдәбият тудыру җиңел эш түгел.

Менә ул «Отряд флагы» (1930), «Дулкыннар» (1931), «Ант» (1934) исемле әсәрләрен бастырып чыгара. Аз вакыт эчендә ул балалар өчен унбишләп хикәя бирә. Аның бу хезмәте әдәби тәнкыйть игътибарыннан читтә калмый. Балалар әдәбиятын системалы күзәтеп барган, үзе дә балалар өчен дистәләрчә әсәрләр биргән Муса Җәлил Абдулла Алишның «Дулкыннар» исемле җыентыгына да, А. Әхмәт белән бергә язылган «Күршеләр» пьесасына да рецензияләр язган. Муса Җәлил А. Алишның беренче хикәяләренә югары бәя бирә: «Хезмәткә яңа карашлы, чын күңелдән бирелгән төзүчеләр итеп тәрбияләү, завод коллективына мәхәббәтләрен үстерү, сыйнфый дошман калдыкларына карата сизгер һәм килешүсез итеп чыныктыру, чит илләрне өйрәнергә дәртләндерү һәм андагы революцион хәрәкәткә бердәмлек хисен уяту һәм ахыр килеп, таза тәнле итеп үстерү идеяләре — барысы да безнең балаларны яңача тәрбияләүдә мөмкин моментлар булып торалар» [1]. Шушындый катлаулы идеяләрне чагылдыруын мактап, М. Җәлил әсәрнең сәнгатьчә эшләнешен дә

---

[1] *Муса Җәлил.* Сайланма әсәрләр, 3 том, 174 бит.

күрсәтә, «кызыксынуны саклау һәм көчәйтү өчен хикәянең композициясендә дә төрле табышлы моментлар» бирүне яхшы таба. Шул ук вакытта ул хикәяләрне зурларга язган кебек язарга ярамавын әйтә: «Алишта балалар теле эшләнмәгән. Хикәяне ул зурларга язган төсле яза. Балалар теленә хас сүзләр юк»,— ди ул.

Нәкъ менә иң авыры да шунда. Әгәр Абдулла Алиш тәнкыйтькә колак салмаса, үзенең осталыгын югары күтәрүгә әһәмият бирмәсә, аның балалар өчен уңышлы әсәрләр язарга омтылуы — яхшы теләк кенә булып калырга мөмкин иде. Матур идеяләр бирергә була, бик әйбәт эшкә үгетләргә, яхшылыкка өндәргә була. Ләкин балага ялангач дидактика бирү художник эше түгел, баланы мавыктырырлык вакыйгалар аша гына зур идеяләргә китерергә мөмкин һәм ул идея балаларча шаян, җылы тел белән сөйләнсен! А. Алиш шушы катлаулы эшне үзләштерен килә. «Күршеләр» пьесасы буенча ук инде М. Җәлил язучыларның «тип эшләү, аларны үз телләрендә сөйләтә белү һәм диалогларны матур төзү осталыклары барлыгын» [1] сизә.

А. Алиш баштарак зурлар өчен яза иде. «Якты күл буе» повесте язучының бу өлкәдә дә уңышлы эшли алуын раслый торган әсәр. Ләкин үзе дә, иптәшләре дә аңа балалар әдәбияты өлкәсендә хезмәт итү — яхшырак дип табалар. Балалар язучысы булу өчен Алишта барлык сыйфатлар бар. Барыннан да бигрәк, ул балалар психологиясен, аларның бер үк вакытта төрле нәрсә белән мавыгуларын белә. Ә бу бик кирәкле, кыйммәтле сыйфат. Балалар күңелен таба белүе, аларны яратуы — Алишны күренекле балалар язучысы итеп үстерде. Ул бу эшкә бөтен көчен, барлык сәләтен бирде. Тәрҗемә иткәндә дә ул балалар әдәбиятын сайлады. Борис Житковның «Мин нәрсәләр күрдем?» исемле атаклы китабын оригиналындагыча балалар теле белән тәрҗемә итүче Абдулла Алиш

---

[1] *Муса Җәлил.* Сайланма әсәрләр, 3 том. 183 бит.

булды. Шуны да әйтергә кирәк, А. Алиш балалар әдәбиятының да иң җаваплы, иң авыр өлкәсен сайлады. Ул мәктәп яшендәге балалар өчен түгел, мәктәпкәчә яштәге балалар өчен язды, меңнәрчә аналарга һәм балалар бакчасында эшләүчеләргә үзенең ярдәм кулын сузды. Бу өлкәдә эшләүнең, барлык авырлыкларыннан тыш, тагын бер ягы бар: бу хезмәт — күләме белән кечкенә, әһәмияте белән әйтеп бетермәслек зур һәм ул хезмәт инә белән кое казуга тиң... Аңа да карамастан, Абдулла Алиш елданелга балаларга якыная, елдан-ел аның бу эшкә мәхәббәте үсә бара.

Яшьтә язылган — ташка язылган, ди халык, ул җуелмый да, кырылмый да. Яшь чакта күңелгә кереп калган нәрсә, ташны чукып язган кебек, кыршылмый, онытылмый. Абдулла Алишның нәниләр өчен әкиятләр иҗат итүе нәкъ шул принципка нигезләнеп, кайгыртучан ана омтылышыннан чыгып язылганнар. Изге ана, үзенең сөекле баласын үскәч ничек итеп күрергә тели — шул юнәлештә аңа тәрбия бирә; кече яшьтән үк баланың күңеленә бик күп нәрсә салып калдыра. Ул баланы һәръяклап камилләшкән, тормышка хәзерлекле итеп үстерү өчен бөтен көчен сала. Абдулла Алиш та, түземлелек белән баласына тәрбия бирүче ана кебек, баланың рухын сафландыра, күңелен нурландыра торган фикерләрне әкият теленә салып бирә. Аның «Ана әкиятләре» сериясенә кергән әсәрләре шундый изге максат белән язылганнар.

«Ана әкиятләре» гаҗәп киң программаны эченә алырга тиеш иде. Язучы әле шул юлда илһамланып эшли иде. Чыннан да бала тәрбияләү эше иң җаваплы һәм иң мактаулы эшнең берсе бит! Бала йокыдан уянгач та нишләргә тиеш? Битне-кулны юу белән генә аның беренче эше тәгәлләнми ич! Әллә ул үз урын-җирен җыярга өйрәнсенме, үзе киенсенме, йорттагы кешеләрнең исәнлек-саулыгын белешү дә аның гадәтенә керсенме? Ашарга утыргач, ул үзен ничек тотарга тиеш? Елның вакытына карап, ничек киенергә икәнен онытмасмы?! Шундый санап бетергесез

гадәтләргә кече яшьтән өйрәтү, элементар тәртип һәм кагыйдәләрне ташка язган кебек аның күңеленә язып калдыру белән эш тәгәлләнми. Язучы олы фикергә акрынакрын килә; ул игътибарын баланы чын гражданин итеп, иҗтимагый файдалы эшкә күнеккән һәм коллективист итеп тәрбияләүгә юнәлтә. Шуңа күрә аның әкиятләре Ватанчылыкка, күмәк хезмәткә, халыкка турылыклы булуга, батырлыкка һәм эшчәнлеккә өндиләр.

Мондый фикерләр ялангач килеш, турыдан-туры әйтелмиләр. А. Алиш әкиятләре балаларны табигать белән, кошлар, хайваннар, җәнлекләр белән, аларның үзләренә хас сыйфатлары белән таныштыра, шул ук вакытта кош-кортларның тормышлары белән бәйле вакыйгалар укучыга нәтиҗә ясарлык итеп биреләләр. Мәсәлән, «Сыерчык белән карт чыпчык» әкиятен алып карагыз. Анда чыпчык, мактануы аркасында, үлем тырнагына эләгә, ярый әле бу бәладән сыерчык коткара. Нәтиҗә ачык: мактану яхшылыкка алып бармый. «Сер тотмас үрдәк» әкиятен хәтерләгез: йортның (Ватанның) серен саклау — изге бурыч, ул тыныч һәм бәхетле тормыш итү дигән сүз!

Гади генә сюжетлы әсәрләрдә художестволы образлар аша олы фикерләр, кешенең гражданлык сыйфатын үстерүгә юнәлтелгән идеяләр бирелә.

А. Алиш әкиятләренең художество осталыгы бәхәссез. Ул телдә тәгәллеккә, музыкальлеккә ирешә; ул әсәрен шигъри яктан да эшли, аның җөмләләре эчке рифма белән тулы, аның шулай ук ритмикасы да бар. Бу — аның әсәрләренә аһәңлелек бирә, укуны җиңеләйтә, нәтиҗәдә — әсәрне хәтердә калдыру уңайлы була.

Кайчандыр Казан ТЭЦ төзелешендә техник булып эшләгән, Казан җир төзү техникумын (1935) тәмамлаган, берничә ел «Техника» журналының җаваплы секретаре булып эшләгән Абдулла Алиш танылган балалар язучысы! Ул бу өлкәдә үзен таба һәм талантына киң мәйдан ача. Сугышка кадәр ул «Пионер каләме» журналының

әдәби сотрудникгы булып эшләде; үзенең белемен күтәрә баруны да онытмады. Педагогия институтының кичке бүлегендә укыды, аның өченче курсын тәмамлады.

Абдулла Алиш бөек Ватан сугышы башлангач, сугышның беренче атналарында ук, илне саклаучылар сафына килеп баса. Баштарак аннардан хатлар килеп тора. Сугыш шартларында ул берничә хикәя дә язып җибәрә. Ләкин 1941 елның октябрь аеннан башлап хат-хәбәр килүдән туктый. Алиш — хәбәрсез югала. Ватан сугышы тәмамланмыйча, аның язмышын ачыкларга мөмкинлек тә булмый. Ниһаять, Муса Җәлилнең Моабит төрмәсендә язылган дәфтәрләре илгә кайткач, аның язмышы ачыклана башлый. Абдулла Алиш Муса Җәлил белән бергә фашистлар тарафыннан гаепләнеп кулга алынган икән. Шунысы да билгеле (һәм бу турыда матбугатта бик күп язылды инде) Муса Җәлилнең «Дуска» исемле шигыре Абдулла Алишка адресланган.

Нинди фаҗигале язмышка очраган безнең язучыбыз, нинди дәһшәтле хәлләрне башыннан кичергән ул? Тоткынлыкта ул үзен ничек тоткан һәм, язучы буларак, нәрсәләр калдырган? Гомере ничек төгәлләнгән?..

Соңгы вакытта А. Алишның фашистлар тоткынлыгында ничек яшәве һәм нинди әсәрләр язуы турында яңа материаллар килде. Моңа кадәр әле безнең кулда Т. Нигъмәт исемле кешенең блокнотыннан башка бернәрсә дә юк иде. Ул блокнотның иясе пленда булган һәм Алиш белән М. Җәлил шигырьләрен күчереп алган. Аның язуына караганда, ул бу шигырьләрне бер генә тапкыр күчермәгән: бер биттә ул 1944 елда Франциядә күчереп алганын һәм яңадан кабат күчерүен белдерә. Һәм бу блокнот үзе дә бик күп илләрне кичеп, бик күп кулларда булып, Казанга килеп җиткән бер документ. Блокнотка язылган Муса Җәлил шигырьләре барысы да укучыларга билгеле. Бу блокнотта Алиш язган унөч шигырь бар. Боларның оригиналлары кайда — әйтүе кыен. Шул кадәресе билгеле, Алишның, Берлинга күчерелгәнче ук, Муса белән очра-

шып, бер үк оещмада фашизмга каршы көрәш башлаганчы ук, берничә дәфтәре булган һәм анда патриотизм рухын чагылдырган шигырьләре булган. Ул шигырьләрне Польшадагы концлагерьда булган татар солдатлары күчереп алганнар. Шул җөмләдән Газыйм Кадыйров исемле иптәш тә аларны күчергән һәм, байтак өлешен күңелдән ятлап, туган иленә алып кайткан. Ул шигырьләрне күчереп алганнан соң Кадыйровка Чехословакиядә, Франциядә йөрергә туры килә, соңыннан, союздаш армия солдатлары пленнан азат иткәч, Англия аша үзебезгә кайта. Шулай йөри торгач, блокнот таушалып, теткәләнеп бетә.

Бу шигырьләрнең Алиш тарафыннан язылган булуына без шикләнмибез, чөнки җентеклап тикшерү аларның Алиш йөрәгеннән чыкканлыгын сөйлиләр (дөрес, күчерүченең ялгыш күчерү фактлары һәм, искә төшереп язганда, тегс я бу сүзнең үзгәреп китү ихтималы юк түгел). Т. Нигъмәт блокнотында «ул төшне мин тагын күрерменме?» исемле шигырь бар. Бу шигырьне Кадыйров та искә төшереп язып җибәрде. Һәм алар икесе дә бер үк шигырь...

Шул рәвешчә, Абдулла Алишның фашист тоткынлыгында күрсәткән эшчәнлеге шактый ачылды, дип уйларга кирәк.

Нигъмәт блокнотында Алишның «Тормыштан хроникалар» дигән бер бит язмасы бар. Анда Алиш үзенең Брянск янында Десна елгасы буенда чолганышта калып 1941 елның 12 октябрендә пленга эләгүен яза. 1941 елның кышын ул Литвада Алитус шәһәрендәге лагерьда үткәрә. Анда 17 мең кеше исәпләнә. Аларның нинди шартларда яшәгәнлекләрен бер цифр бик ачык итеп, барлык трагедиясе белән күз алдына китереп бастыра. Кыш узганчы 17 мең совет кешесеннән 14—15 меңе үлеп бетә. Бу фаҗиганы Алиш көн-төн тәне белән, җаны белән кичерә, шулай да үлем аның үзен бу юлы читләтеп уза: «Тәмәке тартмавымның бик зур файдасы тиде»,— ди ул. Шундый ук язмышны кичергән кешеләрнең истәлекләренә караганда, Алиш үзе тапкан тәмәке төпчекләрен иптәшләренә

бирә барган, ә дуслары аны бәрәңге кабыгы кебек «тәмле» ашлар белән сыйлый торган булганнар.

1942 нче елның апрель, май айларында Алишны Германиягә алып киткәннәр, аннары бик күп лагерьлар аша йөртеп, Чехословакиягә озатканнар. Анда ул эшчеләр лагеренда шлифовальщик булып эшләгән.

Август айларында аны яңадан лагерьга кайтарганнар. Бераздан Берлин янындагы лагерьга китергәннәр. Монда ул Муса Җәлилне очраткан һәм аның белән бергә эшләгән. Алиш газетада тәрҗемәче булган. «Без Муса белән легиончылар арасында листовкалар таратуда гаепләнеп кулга эләктек. Берлин төрмәсендә утырдык»,— дип яза Алиш. Ул моны 1943 елның 24 ноябрендә язган.

Билгеле булганча, Муса Җәлил, Алиш һәм аларның иптәшләре төрмәдән тышкы дөнья белән бәйләнеш тотканнар. Бу дәфтәрнең шул 1943 елда ук Моабит төрмәсеннән чыгып дусларына бирелгән булуы мөмкин. Ләкин моннан тыш Алишның башка дәфтәрләре дә булганы билгеле. Муса һәм Алиш шигырьләре тупланган башка бер блокнотның 1944 елның августында Моабит төрмәсеннән тышкы дөньяга чыгуы турында хәбәрләр бар. Гитлерга покушение булганнан соң, 1944 елның сентябрь яки октябрь аенда А. Алиш, Әхмәт Симаев, Фуат Булатовларны фашистлар җәзалап үтергәннәр. Аларның хәлен белергә килүче, беркөнне төрмәгә килгәч, Муса Җәлил һәм Алишларның кичә үтерелүләрен ишеткән; надзиратель аңа үлүчеләрдән калган блокнотны тапшырган. Ул нинди кеше һәм блокнотны кая куйган — хәзергә билгесез.

1956 елның көзендә совет шагыйрьләре П. Антопольский, С. Михалков һәм К. Симонов Бельгиягә халыкара поэзия фестиваленә баралар. Константин Симонов Бельгия партизаны Андре Тиммерманга Әминә Җәлилованың хатын алып бара (Муса Җәлилнең Моабит дәфтәрләренең берсен Тиммерман саклап калуын укучылар беләләр булыр) һәм бельгияле шагыйрь Роже Бодар ярдәмендә Андре Тиммерманны эзләп таба. Тиммерман-

ның Симоновка сөйләгән истәлекләрендә Муса Җәлил һәм Абдулла Алишның биографияләренә ачыклык бирелә.

Андре Тиммерман Муса белән бер камерада утырган, уңдагы һәм сулдагы камераларның берсендә Булатов, икенчесендә Алишев утырганын сөйли. «Бу Алишев, әгәр хәтерем ялгышмаса,— дип сөйли Тиммерман,— элек, сугышка кадәр, балалар өчен әкиятләр язган бугай. Миңа бу турыда Муса Җәлил сөйләде. Бу татарлар белән бергә һәр камерада берәр бельгияле бар иде. Бу бельгиялеләр минем танышларым, аларның икесе дә минем белән бер үк көнне, минем белән бер үк эш өчен кулга алындылар. Минем алар белән, ә Җәлилнең үз иптәшләре — татарлар белән ничек булса да элемтә урнаштырасыбыз килде. Без стенада язулы кәгазьләр үткәреп булырлык кечкенә тишек тишәргә теләдек, ләкин моның өчен бернинди дә инструментыбыз юк иде».

Муса Җәлилнең Алиш белән сөйләшәсе бик килгән, ләкин Алиш утырган камера арасындагы стенаны тишеп өлгергәнче, Мусаны да, Алиш белән Булатовны да Дрезденга судка алып киткәннәр. Аларны кире Берлинга кайтарулары турында да истәлекләр бар. Тиммерман үзенең истәлегендә Муса Җәлилне Шпандау төрмәсендә яңадан очратуын сөйли. Бу инде 1944 елның августы була. Гитлерга һөҗүм булганнан соң, барлык политик тоткыннар Берлин төрмәсеннән Шпандауга күчерелгәннәр. Андре Тиммерман Муса Җәлил белән төрмәнең душында очрашырга тырыша һәм очраша. «Анда мин Җәлилне күрдем һәм, бер-беребезгә бик якын торып юынган арада, аның белән ун минут бүс сөйләштем. Җәлил миңа үзенең һәм татар иптәшләренең үлем җәзасына хөкем ителгән булуларын әйтте»,— ди Тиммерман.

Бельгия партизаны Тиммерман сөйләгән истәлекләр Муса Җәлил һәм Абдулла Алишның соңгы көннәрен күз алдына китерергә ярдәм итәләр.

Әйе, дөнья күләмендә сөйләрлек кыю, куркусыз көрәшчеләр алар!

Абдулла Алишның ялкынлы патриот, намуслы совет кешесе, куркусыз керәшче һәм язучы икәнен күз алдына китерү читен түгел. Чыннан да, Абдулла Алиш, башыннан нәрсә генә кичмәсен, илгә турылыклы булып кала, совет язучысы һәм совет солдаты дигән изге исемне югары тотып, тормыш юлын намус белән уза. Ул кайда гына булмасын, үзенең гражданлык бурычын онытмый. Ул — совет гражданины, советлар иленең турылыклы солдаты, партиясез большевик, совет халкының язучысы! Һәм һәрбер адымын ул совет гражданлыгы намусы кушканча атлый.

Менә ул Седльце лагеренда.

А. Алиш белән бергә концлагерь авырлыкларын кичергән Г. Кадыйров болай сөйли:

— «Седльце лагере бик зур. Немецлар хәле булган әсирләрне көн саен Польшадагы байларга эшләргә алып баралар. Эш күбесенчә тирес түгү, җир ашлау була. Җиде-сигез кешене бер арбага җигеп тирес түктерәләр. 25 кешегә 700 грамм икмәк, анысы да яртысы агач оны, яртысы чүгендер... Эш кояш чыкканнан алып кояш батканчы таяк астында алып барыла. Кайткач, йоклау урыны балчык идәнле такта сарай. Ул урынны да алданрак кайтып алып кала алмасаң, башы ачык һава белән япкан, стеналары дүрт-биш катлы чәнечкеле чыбык белән уралган лагерь эче кала. Ачык һавада, эт балалары кебек, җыйналышып ятасың. Җир салкын чык, кырау белән капланганга, бик читен була. Немец сакчылары күрмәгәндә, яшеренеп кенә чүп-чар җыеп, учак ягып, ятасы урынны җылытабыз, көлен түшәк итеп җәябез, җыйналышып ятабыз. Безнең өске киемнәребезне дә немецлар салдырып алган иде, без бер кат күлмәк белән гел шәрә калдык...

Көннәрдән беркөнне мин кояшка җылынып утырган төркем янына туктадым. Алар арасында бер урта гына буйлы, кара калын кашлы, кара күзле абый шигырьләр укып утыра, кайберәүләр язып та алалар. Миңа аның шигырьлә-

ре ошады һәм мин аңардан шул шигырь дәфтәрен күчереп алырга сорадым... Ул минем кемлегемне сорашты... Алиш икәнлеген әйтте. Шул көннән башлап ашау-эчүләрне без бергә бүлешеп ашадык. Ул тәмәке тартмый иде. Беркөнне немец солдатлары чыгарып ташлаган бәрәңге кабыкларын Алишев абый белән чәнечкеле чыбыклар арасыннан кул тыгып ала башлаган идек, кайдандыр каравыл килеп чыгып, зәһәрләнеп мылтык сабы белән башларыбызга, билләребезгә төшерде, кемгәдер барып әләкләп, су агып торган бетон идәнле подвалга яптылар. Анда бастырып, зур электр лампасына карап торырга мәҗбүр иттеләр. Сакчы пычаклы мылтыгы белән төн буе безне төрткәләп, үртәп, көлеп чыкты. Икенче көнне күз нурлары беткән, баш әйләнә, бернәрсә күрмибез, ләкин барыбер безгә берәр котелок борчак кадәре генә ак вак таш җыйнарга куштылар. Лагерьдагы комда тавык кебек чокчынып йөрсәк тә, котелок тутырып булмады. Шуннан соң Алишев абый чирләде, чөнки ул бу лагерьга бик авыр хәлдә килгән булса кирәк, бикябык, көчкә үзен йөртә иде... Хәтерлим, ул бер аягына аксабрак йөри иде. Ул бик күп шигырьләр язган иде, гарәп хәрефләре белән, кызыл каләм белән. Мин аларның тик бер өчесен генә белмим... «Таңны каршылау», «Газиз анам», «Ялгыз каен»... Күпләрен хәзер онытып та барам. Аңарда ике-өч дәфтәр иде.

Ул азрак хәлләнгәч тә күмәкләшеп качу юлын оештырырга кирәк дип сөйли башлады.

— Безнең кемнәр билгеле бит, ничек моның номерларын ертып ташлыйсың?— дигәч:

— Басуда карга-чыпчыкларны куркытырга элгән сәләмә кемнәрне булса да рәтләрбез әле. Азрак сабыр итү лучше булыр,— дия иде.

Алишев абыйның бер иптәше лагерь төрмәсендә ята иде. Ул кем, белмим. Ул аңа аш җыйнап, тәрәзә аша Польша солдатлары аркылы бирә иде».

Менә Газыйм Кадыйров истәлегеннән кайбер өзекләр шулар. Кадыйровның истәлекләре вакыйганың тышкы кү-

рәнешен җанландыру белән кыйммәт, ләкин Кадыйров истәлекләр генә бирми, ул егермеләп шигырьне хәтерли һәм ул шигырьләр татар совет язучысының эчке дөньясын, рухи байлыгын, намусы сафлыгын чагылдыралар. Дөрес, бу шигырьләрнең кайбер строфаларын инде Газыйм онытткан, кайбер шигырьләр исә бик үк эшләнеп тә бетмәгән. Шуның өстенә — искә төшереп язганда була торган хәл — кайбер шигырьләргә строфалар икенчесеннән килеп кергән кебек тә тоела. Әле боларны, билгеле, өйрәнәсе бар. Ләкин аларда Совет кешесенең йөрәк тибеше бирелгән: аларда туган илгә булган сагышлы хис бар, алдагы көннең бәхетенә ышаныч бар, балалары өчен борчылу һәм дошманга нәфрәт бар.

Өметем зур минем киләчәккә,
Җиңмәк булам тормыш агымын,—

дип яза ул бер шигырендә һәм «халык өчен... агымга да каршы» баруы турында әйтә.

«Үзем турында җыр» исемле шигыре аның философик карашларын яктырта. Туган илдән дә кадерле, Ватаннан да изге һичнәрсә юклыгын поэтик сурәтләгәннән соң, ул нәтиҗә рәвешендә шундый юлларны яза:

Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын.
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер Ватанын.

Тирән философик фикерләр белән тулы «Күзләр» шигырен алыйк. Немец фашистларының концлагеренда көрәш һәм качучылар төркеме оештыруның никадәр куркыныч булуын һәм бу эштә осталык та, саклык та кирәклеген хәтерләткән бу шигырьдә:

Күзләр алар сөйдерә белгән кебек,
Дошманнан да безне саклыйлар.
Итәгендә үлем котырганда,
Күрә торып утка атмыйлар.

Кеше карбыз түгел, беркайчан да
Ярып карап булмый уртасын.
Шуңа күрә әйтер сүзеңне дә
Әйтмиенче аннан куркасың,—

дигән юллар бар.

Поэтик яктан да оста эшләнгән «Ярканат» шигыренә дә философик эчтәлек салынган. Монда аның тормышны сөюе, яктылыкны сөюе, туган илне сагынуы һәм Ватанның да аны көтеп торуы эмоциональ көч белән әйтелгән. Язучы киң мәгънәне кыска гына юлларга сыйдыра алган, шигыренең музыкасын яңгыраткан.

Мин ярканат кебек һич тә
Яктыдан качмам.
Иркәләп сөйгән кояшка
Булмамын дошман.
Мин барамын якты көнгә
Ачык йөз белән,
— Хуш киләсез, көләч иртә,—
Дигән сүз белән.

Күрәсез, гади, матур, мәгънәле, күңелгә ятышлы.

Седльце концлагеренда ук күмәкләп көрәшү турында яшып йөргән Алиш, Муса Җәлил белән очрашкач, үзен тулысынча көрәшкә багышлый. Муса Җәлил тарафыннан оештырылган яшерен коммунистик оешмада партиясез язучы Алиш алгы сафта тора һәм Мусаның иң ышанычлы ярдәмчесе булып кала. Муса белән бергә аның иң зур эше — дошман армиясен таркату була һәм алар бу юлда уңышка ирешәләр. «Дуска» шигыренең М. Җәлил тарафыннан аңа багышлануы да очраклы түгел:

Бәлки менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер?..
...Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда.

М. Җәлил бу юлларда үзе турында гына сөйләми, ул Алишка да гаять югары бәя бирә, чөнки Алиш «безнең авыр яшерен көрәшне» узган һәм аны «җанлы әкият

итеп» (М. Ж.) сөйли ала торган кеше. Ул шул җанлы әкиятнең уртасында кайнаган.

Безнең Абдулла Алишны коммунист язучы-көрәшче булып үлде, дип әйтергә хакыбыз бар. Нәкъ менә аны коммунистик намусы куркусыз патриотлар сафына китереп бастыра, большевистик йөрәге дошманның өнендә тиңдәшсез көрәш алып барырлык көч таба. Һәм нинди генә авырлык кичермәсен, нинди каты җәзалаулар күрмәсен, ул чыныккан көрәшче-большевик булып, туган илгә, совет халкына, Коммунистлар партиясенә турылыклы булып кала. Дошман илендәге яшерен коммунистлар оешмасының көрәшчесе сафында үлә. Шуның өчен дә без аны хөрмәт итәбез, исемен олылап искә алабыз!

Абдулла Алиш Берлинда көрәш алып барганда һәм Моабит төрмәсендә утырганда, Муса Җәлил кебек, шигырьләр язуын туктатмаган. Безгә килеп җиткән шигырьләренең саны күп түгел, ләкин аларда Ватан сугышы поэзиясе өчен уртак авазлар, уртак мотивлар табуы читен түгел. Мин, беренче чиратта, ул шигырьләрдә Ф. Кәрим һәм М. Җәлил шигырьләренә аваздаш моментларны әйтер идем. Менә ул үзенең ике улы белән горурлана, «Ике күзем кебек, ике улым сизгер саклар илнең постларын!» ди ул. Һәм:

Шуышмасын дошман тирә-якта,
Колакларым яхшы ишетә,
Мин үлсәм дә, ике улым кала,
Алар ишетер икесе ничек тә,—

кебек юлларда батырлык сыйфатларының, патриотик хисләрнең яңа буыннарда кабатлануы турындагы фикер бирелә. Шул ук философик фикерне Ф. Кәрим дә үз поэтик образы белән бик матур итеп әйткән иде ич:

Үзем үлсәм — балаларым кала,
Минем гомерем булып — Ватаным.

Әнисенә багышлап язылган «Көтмә инде, көтмә...» шигырендә А. Алиш ана күңелендә туган изге тойгыларны

сурәтли. Бу шигырь шулай ук ана мәхәббәте, ана кайгысы, ана сагышы турында язылган иң яхшы шигырьләр рәтеннән урын алырлык. Анда сагыш белән балаларын көтеп тилмергән ананың төшендә дә алар белән, көндез — хатлары белән яшәвен бик матур итеп, җанлы һәм эмоциональ көчле итеп күрсәткән.

«Өченче көз», «Очкычка карап», «Туган илгә», «Ничек килер үлем» кебек шигырьләрдә тоткын шагыйрьнең тирән хисләре, тормышка булган ялкынлы мәхәббәте, Ватанга турылыклы булып калган яралы йөрәгенең нәфрәт моңы, ирек даулаган протесты, ниһаять, гомер юлының соңгы сулышына кадәре туган илгә багышланган булуын аңлап горурлану тойгысы — болар барсы да безне сокландырырлык язылганнар. М. Җәлил шигырьләренә аваздаш тойгыларны һәм шундый ук эмоциональ көч белән тетрәнгән йөрәк хисләрен табуы читен түгел. А. Алиш Муса тәэсирендә, бәлки аның киңәше белән, бик күп шигырьләр язган.

Күпме кәгазь языла безнең хакта,
Бәлки кабат аны укырлар.
Иптәше өчен кеше корбан була,
Шундый инде безнең гасырлар.
Көрәш белән тудык, көрәш белән
Керәбез дә, ахры, кабергә.
Язган икән соңгы сулышыбызны
Илебез бәхте өчен бирергә.

(«Ничек килер үлем».)

Мондый юллар олы йөрәкле шагыйрь авызыннан гына чыга алалар. Һәм алар безнең Ватан сугышы чоры поэзиябезне өстәмә бер нур белән бизиләр. Сугыш елларында үзенең барлык матурлык көчендә яңгыраган, совет кешесенең рухи портретын күп төрле һәм җуелмый торган буяуларда сурәтләгән безнең поэзиядә А. Алиш үз урынын алырга хаклы.

Ул үзе кайта алмады, фашист палачлар аның якты гомерен кистеләр. Лэкин аның турындагы чынлыкны, аның

йөрәк серләрен тартып ала алмаган шикелле, ялкынлы җырларын да үтерә алмадылар! Ул исән, ул безнең арада. Аның әсәрләрен совет балалары сөеп укыйлар, шигырьләрен ятлап алалар, исеменә дан җырлыйлар!

Гази Кашшаф.

ЯКТЫ ИСТӘЛЕК

Абдулла Алиш совет балаларының сөекле язучысы иде. Ул татар балалар әдәбиятын үстерүдә бик зур хезмәт күрсәтте. Аның «Kапкорсак патша», «Чуар тавык», «Нечкәбил», «Сертотмас үрдәк», «Kаз белән аккош», «Аерылганны аю ашар — бүленгәнне бүре ашар» һәм башка әкиятләрен, шулай ук башка күп кенә хикәяләрен балалар аеруча яратып укыйлар.

Абдулла Алишны мин беренче тапкыр 1932 нче елда «Пионер каләме» журналы редакциясендә күрдем һәм аның белән шунда таныштым. Безне әсәрләребез таныштырды. Үзен күрмәсәм дә, Уралда яшәгән вакытта ук аның әсәрләрен укый идем.

Мин редакциягә килеп кергәч:

— Абдулла,— дип исемемне әйтеп кулымны суздым. Ул да:

— Абдулла Алиш,— дип куйды һәм елмайды.

Шул көннән башлап, без аның белән көн саен диярлек очраша идек һәм шулай итеп якын дус булып киттек. Бу икебезнең дә исемнәребез «Абдулла» булган өчен түгел, бәлки, бу үткен кара күзле, чем-кара чәчле, йөзендә ниндидер бер үзенә җәлеп итә торган ягымлылык, мөлаемлык, җылылык балкып торганга күрә, без шулай бик тиз дуслашып киттек.

Язучы халкында шундый бер гадәт бар: яңа гына өл-

тереп «мичтән» чыккан кайнар әсәрләрен алар иң элек иң якын иптәшләренә укыйлар. Без дә шулай итә идек. Әле ул миңа килә, әле мин аңа барам. Иҗат тәҗрибәләре белән уртаклашуда Алишның тагын бер якын дусты язучы Гариф Галиев тә якыннан катнаша иде. 1934 нче елның бер көнендә Алиш:

— Давай, ике Абдулла дип, бергә язып карыйк әле, нәрсә килеп чыгар икән?—диде.

Без аның белән бергә өч пьеса яздык: «Йолдыз», «Күршеләр» һәм «Йөрәк ялкыны». Аларның икесе басылды һәм мәктәп сәхнәләрендә барды. Тик «Йөрәк ялкыны» исемле пьесабыз гына басылмады да, сәхнәгә дә менә алмады. Исеме ялкын булса да, үзе салкын булган ахры.

Абдулла Алиш үз-үзенә һәм башкаларга бик таләпчән язучы иде. Шуның белән бергә ул кешеләр белән күркәм мөгамәләдә була, укучы балаларның иҗатына игътибар белән карый, аларга һәрвакыт ярдәм итә, өйрәтә. «Пионер каләме» журналы редакциясенә кайчан гына кермә, аны кызыл галстуклы укучы балалар сырып алган була. Мәрхүм кайвакыт зарланып та куя:

— Кайберләре хәбәр дә яза белмиләр, ә дистәләп шигырь китерәләр, дәресләренә зарар килми микән?—ди. Ләкин, ул өметле, сәләтле яшь каләмнәрне күрә белә, аларны үстерүдә чын күңеленнән ярдәм итә иде.

Хәзерге зур художниклардан Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов һәм танылган балалар язучысы Җәүдәт Тәрҗемановлар ул вакыт пионерлар иде һәм алар үз журналлары булган «Пионер каләме»нә еш киләләр һәм анда әсәрләре белән якыннан катнашалар иде. Алар художник һәм язучы буларак, А. Алиш эшләгән «Пионер каләме»ндә үстеләр.

Алиш үткен, өлгер һәм актив язучы иде. Көннәр буе редакциядә эшләү белән бергә, ул еш кына мәктәпләрдә була, балаларга үзенең кызыклы әкиятләрен укый торган иде. Мәктәп балаларын ул үз балалары кебек ярата, якын күрә. Балалар да мәктәптә аны:

— Алиш абый килгән.

— Әкият сөйли торган абый килгән,— дип сырып алалар һәм төрле сораулар белән күмәләр иде.

Якын дусны, каләмдәшне иң актык күрүем дәһшәтле 1941 нче елның июль көннәрендә булды. Бу вакыт ул башына янып торган кызыл йолдызлы пилотка, өстенә җиз төймәле гимнастерка кигән Алиш солдат иде инде. Рухы күтәренке, тик аның элек һәрвакыт диярлек елмаеп торган йөзе ул чакта җитди иде. Сөйгән иптәшеннән, газиз балаларыннан аерган, туган иленә басып кергән явыз дошманга нәфрәт утлары чагыла иде анда...

Абдулла Алишның искиткеч яраткан газиз әнкәсе бар һәм ул исән. Газизә апа Казанда яши. Аңа инде 82 яшь. Ул үзенең Габдуллаҗанын бик ярата, аны ул әле дә теленнән төшерми, гел искә ала. Алай гына да түгел, Газизә апа Алиш сугышка киткәннән соң аны сагынып, аңа ана нәсихәтләре биреп күп кенә шигырьләр язды.

Сугыш башларында Газизә апаның улы Абдулла Алишка язган хатында түбәндәге юллар бар:

Әгәр дошман каршы килсә,
Мылтыктан рәхимсез ат,
Теләгем шул минем сиңа:
Батыр исемен алып кайт!..

Бала ананың сүзен үтәде. Ул, әйләнеп кайта алмаса да, дошманга каршы рәхимсез сугышты һәм батыр исемен алды. Ана үзенең сөекле улы, безнең якын дустыбыз, патриот язучыбыз Алиш турында «Габдуллаҗаным» дигән шигырь язды.

Үзем үләм димәгән, балам кала димәгән,
Дошман сүзенә алданып, туган илен бирмәгән.
Алар югалсалар да, исемнәре югалмас,
Безнең Совет хөкүмәтен бер дошман да җиңә алмас.

Әйе, Газизә апа, газиз ана дөрес әйтә: безнең илдә Муса һәм Алиш кебек геройларның исеме мәңге югалмаячак, халык аларны мәңге онытмаячак!..

Абдулла Әхмәт.



ӘКИЯТЛӘР

26 биткә



СЕРТОТМАС ҮРДӘК

Борын заманда башы бүрекле, аягы төкле бер үрдәк булган. Ул үзе сайрый белмәсә дә, күргән бер кошына, хайванына, ерткычына озак-озак итеп яңа хәбәрләр сөйләргә бик ярата икән. Тегеләр аның сүзләрен тыңлый-тыңлый арып бетәләр, я бөтенләй тыңламый ташлап китәләр икән. «Ишеттеңме бер яңа хәбәр? Сиңа гына сер итеп сөйлим»,— дип башлап китә торган булган ул сүзен.

Бердәнбер көнне йорт хуҗасы үзенең этен ияртеп, корыч балтасын биленә кыстырган да урманга киткән. Йортындагы һәрбер кош-кортына: «Өйдә юклыгымны берәүгә дә белдермәс булыгыз!»,— дигән.

«Нигә белдермәскә кушты икән?»— дип, үрдәк йөдәп чыккан, ләкин ни өчен икәнен һич төшенә алмаган.

Кош-кортлар хуҗаларыннан башка бер кич кунганнар, берни булмаган. «Икенче көнне дә кайтмас бу»,— дип, алар хуҗаны чакырып кайтырга берәрсен җибәрергә булганнар. «Син очасың да, син йөзәсең дә, син йөгерәсең дә, син бар!»— дигәннәр алар үрдәккә. «Ләкин берүк нишләп йөрүеңне берәүгә дә белгертәсе булма!» — дигәннәр. Үрдәк кунгән: «Ярар, сезнең хакыгыз өчен генә барсам барырмын инде»,— дигән.

Иртә торгач та үрдәк, уйлап-нитеп тормаган, тамагын туйдырган да юлга чыккан. Башта ул канатларын кагып очкан, оча-оча бер елгага барып төшкән. Ишкәкләре — тәпиләре үзендә булганга аптырамаган, йөзеп тә киткән. Елга буйлап озак йөзгәч, корыга чыгып тәпи-тәпи дә йөгергән...

Бара-бара куе бер урманга барып җиткән. Төрле тәмле җиләкләр, симез бөҗәкләр ашый-ашый, урманга кереп тә киткән.

Үрдәк күбәләк куып йөргәндә, аның каршысына бер керпе килеп чыккан һәм аңа сүз дә кушкан:

— Кая барасың болай?— дигән.

Үрдәккә инде шул гына кирәк тә икән. Юл буе берәү дә очрамаганга, берәү белән дә җәелеп сөйләшергә туры килмәгәнгә, аның бик эче пошкан булган, иптәшләренең әйткәннәрен дә оныткан, сүз артыннан сүзне тезәргә тотынган:

— Урманда утын кисүче хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез дә аңа ияреп киткән иде. Хәзер йорт-җирне саклаучы берәү дә юк. Аларны чакырып кайтырга иптәшләрем мине җибәрделәр,— дигән.

— Синең өең еракмы соң?— дигән керпе.— Анда симез тычканнар, усал еланнар юкмы?— дип сораган. Аның үз хәле хәл, бик нык ашыйсы килә икән.

— Менә шушы сукмак безнең өйгә туп-туры алып бара, бер кешегә дә әйтмә, кара!— дигән үрдәк. Өйләрендә еланнарның бөтенләй юклыгын, тычканнарга көн бирмәүче мәченең шуклыгын да сөйләп биргән.

Алар дус булышып аерылганда, эналe кием кигән булса да, керпе бик файдалы киңәш биргән:

— Мин инде андый усалларның берсе дә түгел, синең серләреңне белсәм дә, каян килүеңне күрсәм дә, сиңа зарарлы эш эшләмәм. Шулай да син саграк бул. Очраган берәүгә серләреңне сөйләмә. Сереңэчеңдә торса, йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр,— дигән. Керпенең бу акыллы киңәшенә үрдәк һич колак салмаган, ашыга-ашыга урман эченәрәк атлаган.

Бара-бара үрдәккә озын колаклы бер куян очраган һәм ул да аңардан сораган:

— Әй, бүрекле үрдәк, күзгә төсле матур, кыр төсле зур күл булганда, ни эшләп урманда буталып йөрисең?

— Хуҗабыз белән этебез урманга утын кисәргә киткәннәр иде, өебез ялгыз калды,— дигән үрдәк, керпегә сөйләгәнне моңа да сөйләп биргән. Куян эченнән генә: «Алай булгач хуҗаның алмагачларын кимерергә барырга бик җайлы вакыт икән»,— дигән. Үрдәктән өйләренең кайдалыгын сорашкан, теге юләр моңа да серен ачкан.

— Хуҗаңны күргәнем юк,— дигән дә куян куаклык эченә кереп югалган.

Үрдәк тагын алга киткән. Бара-бара бер аланлыкка барып җиткән. Анда бер зур соры аю мышный-мышный йоклап ята икән. Үрдәк аны да уяткан. Керпе белән куянга сөйләгән сүзне аңа да сөйләп биргән. Сүз ахырында аюдан сораган:

— Эт иярткән, кулына балта тоткан кешене күрмәдеңме?

Аю:

— Күрмәдем,— дип җавап биргән. Үрдәкнең кайгысын уртаклашкандай булып кыланган:— Урман эченәрәк керсәң, һичшиксез, табарсың, дип, юл өйрәтеп җибәргән. Ә үзе эченнән генә: «Хуҗаның умартасын ватып, бал ашап кайтырга бик җайлы вакыт икән»,— дип, ашыга-ашыга китеп тә барган.

Үрдәк һаман хуҗаны эзләвен дәвам иттергән. Аның

саен урманның эченәрәк керә барган. Бара торгач, аның каршына бүре килеп чыккан һәм аңа сүз кушкан:

— Әй бүрекле баш, шушындый куе урманда япа-ялгызың гына курыкмыйча батырланып ничек йөрисең?— дигән. Теге дә үзенең ник йөрүен сөйләп биргән. Хуҗаның өйдә юклыгын, этнең дә аның белән бергә ияреп китүен бүрегә дә әйткән. Усал бүре тешләрен шыкырдаткан, үз-үзенә: «Боларның сарыкларын барып ашап кайтырга бик җайлы чак икән»,— дигән, ә үрдәккә: «Андый кешене күргәнем юк!» — дигән дә үзе куаклар арасына кереп югалган.

Үрдәк һаман туктамаган. Хуҗасын эзләүне һаман дәвам иткән. Күргән бер коштан, төрле ерткычтан, хәтта нәни бөҗәкләрдән дә бу турыда сорашып бара икән.

Бара-бара аның каршысына көлтәдәй койрыклы бер төлке килеп чыккан. Теге дә ахмак бит, моңа да сүз кушкан:

— Багалмакай, матур апакай, минем хуҗамны күрмәдеңме?— дигән.— Янында эте, кулында балтасы бар иде,— дип өстәгән. Хуҗасыз һәм этсез өйдәге хайваннарның тынычсызлануларын, алардан башка куркуларын да сөйләп биргән.

— Чибәрләрнең чибәре, гәүһәрләрнең гәүһәре, күрдем мин аны!— дигән төлке.— Янында кәкре койрыклы эте дә, билендә корыч балтасы да бар иде,— дип өстәгән. Үрдәкне үзе белән ияртеп киткән. Алар бик озак барганнар һәм куак белән капланган елга буена килеп туктаганнар. Шунда төлкенең оясы буенда балалары уйнап йөриләр икән.

Алар:

— Әни, безгә азык алып кайттыңмы?— дип, аның тирә-юнен сырып алганнар, ә ул авызын ерган килеш, үрдәккә күрсәткән...

— Менә, бәбкәләрем, сезгә тәмле үрдәк ите,— дигән һәм шул минут үрдәкне буып, балаларына бүлеп тә биргән. «Үрдәк ите бигрәк тәмле була икән!» — дип, алар,

авызларын ялый-ялый, аны ашап та ташлаганнар, ләкин туймаганнар, аналарыннан тагын да сораганнар.

— Хәзер, бәбкәләрем, авылга барам, берьюлы берничә үрдәк алып кайтам,— дигән төлке. Балаларын калдырып авылга киткән.

Бер Сертотмас үрдәк аркасында бу хуҗалык тәмам туздырылган булыр иде, ләкин хуҗа уяу кеше булган, дошманнарына каршы һәр җирдә киртә куйган. Куян рәшәткә арасыннан үтә алмаган, кире борылган. Аю бәрәңге базына төшкән. Бүрегә дә сарыклар эләкмәгән, хуҗалык абзарына ул бөтенләй керә алмаган. Төлке хәйләкәр булса да, сыза алмый калган, үрдәк ите ашыйм дигәндә генә, капкынга эләккән, ә хуҗа кайткач инде, аның кирәген биргән... «Тагын берничәне тоткач, толып тектерермен»,— дигән һәм тиресен киптерергә амбарга элгән.

Хайваннар эшнең нидәлеген хуҗага сөйләп биргәннәр. Сертотмасны шундый зур эшкә кушуларына алар да бик нык үкенгәннәр.

КАПКОРСАК ПАТША

I

Әүвәл заманда, кәҗә команда, үгез адмирал, бүре генерал, саескан сотник, төлке шутник, үрдәк үрәтник булган заманнарда бер патша яшәгән, ди. Аты — Капкорсак, кушаматы — Бушборчак булган, ди, бу патшаның. Кеше төсле үзе, үгезнеке төсле күзе, бүренеке кебек тешләре, нәкъ ерткычныкы кебек булган, ди, кылган эшләре.

Ул үзе Канкояр патшаның зур улы иде, ди.

Канкояр патша үлгәч, аның урынына өлкән улы Капкорсак — Бушборчакны патша иттеләр, ди. Патша булам, башыма таҗ киям, тәхеткә менәм дигән көнне, Капкорсак патша барлык сарай хезмәткәрләрен җыеп, рәттән тезеп, дер селкетеп тиргәп алды, ди:

— Минем өчен дөньяда тиңе булмаган, әлегә кадәр бер патша да кимәгән, бер мәмләкәт тә белмәгән, бер патшаның да күзе күрмәгән, иң кыйммәтле, иң матур, иң яхшы таҗ ясагыз,— дип кушты, ди, ул министрларына.

— Сезгә ун тәүлек вакыт бирәм, шул вакытка таҗ өлгергән булсын. Әгәр дә мәгәр, мин әйткән вакытка таҗ өлермәсә, барыгызны да тончыктырачакмын,— дип әйтте, ди, Капкорсак патша.

Көн уйладылар, ди, министрлар, төн уйладылар, ди. Уйлый-уйлый башлары авыртты, татлы йокылары качты. Тамакларына аш үтмәде, эчләренә эчемлек җитмәде, ди.

Бер көн үтте, ике көн үтте, өч көн үтте, ди. Таҗ өл-

гертергә билгеләнгән көн якынлашканнан-якынлашты, ди. «Дөньяда тиңе булмаган, моңа кадәр бер патша да кимәгән, иң матур, иң зур, иң яхшы, иң кыйммәтле тажны нәрсәдән ясарга кирәк икән?»— дип уйладылар, ди, алар.

— Көмештән ясасак — андыйны министрлар да кия, мәрҗәннән эшләсәк — андыйларны бөтен дөнья белә, алтын тажны һәр патша да кия, дигән фикергә килделәр, ди. Алар уйлый тордылар, ә көннәр бер-бер артлы үттеләр дә үттеләр, ди.

Тажны вакытында өлгертмәгәч, Капкорсак патша буран куптарып, көзге җил күк әче сызгырып ачуланырга тотынды, ди. Хәлвә китерделәр — ашамый, ди, конфет-шоколадка карамый, ди. Тажны даулап кызып китте, ди, тәмам үләр чиккә җитте, ди.

— Минем тагын бер теләгем бар: монысын инде һич кичекми үтәргә, тирән елгалар кичәргә, барлык авырлыкларга чыдарга, минем илемне әйләнеп чыгарга һәм эзләргә шундый кешене,— дип әйтте, ди.— Кем дә кем минем атамның фәрманнарына каршы килгән, аңа булган дошманлыгын эчендә яшереп йөргән, тиеш булмаганны ишеткән, сөйләргә ярамаганны сөйләгән, күрергә кирәк түгелне күргән — әнә шундыйларны монда китерегез,— дип әйтте, ди.

Фәрман өстенә фәрман чыккач, аптырадылар-йөдәделәр, ди, патшаның министрлары. Уйлап-уйлап та эшләре алга китмәгәч, уйлау өчен үзләренең генә башлары җитмәгәч, алар күрше патшадагы данлыклы бер таҗ ясаучы останы чакырырга карар кылдылар, ди.

Хат барып җитмәслек күгелҗем диңгез артыннан, алтын кояшны күмгән таулар сыртыннан, кош очып җитмәслек илләрдән, кеше аягы басмаган җирләрдән, кара болытлар арасындагы шәһәрдән чакырттылар, ди, алар шул остаңы. Останың исеме — Биксирәк, кушаматы — Сакалы сирәк, андыйлар Капкорсак патшага бик кирәк иде, ди.

Ак болытлар астыннан, түбәләре зәңгәр күккә тигән таулар башыннан, югарыда янган йолдызларны күзәтеп,

түбәндәге күгелҗем диңгез өстеннән җилдәй үтеп, корычканат дигән кошка атланып очты, ди, Биксирәк Капкорсак патша җиренә. Көн очты, ди, төн очты, ди, ай дигәндә Капкорсак патша хөкем сөрә торган илгә килеп җитте, ди.

Биксирәк-Сакалы сирәк килгән көнне үк Капкорсак патшаны очратты да мондый сүзләрне әйтте, ди:

— Я, падишаһым-солтаным, иске чабата олтаным! Сезгә,— дип әйтте, ди,— ашаган тормау сырхавы эләккән икән,— дип әйтте, ди.— Мондый чүп-чарга карамый (карарга да ярамый), мин үземнең төп эшемә, сезнең фәрманыгызны вакытында үтәргә, юлдагы барлык киртәләрне сүтәргә, сез теләгән теләккә җитәргә юллар сызам,— дип әйтте, ди.

Шул минут эчендә ук Биксирәк-Сакалы сирәк ашапэчеп туеп, дөнья сүзен куеп, бил буып, кереште, ди, үз эшенә.

Үгез адмиралны, бүре генералны, саескан сотникны, төлке шутникны, үрдәк урәтникны — барысын да бергә җыеп, солдатлар кебек тезеп, болай дип әйтте, ди, баш министры Капкорсак патшаның:

— Кем дә кем патшага каршы барса, аңа зарар салса, теле белән патшага каршы сөйләсә, тиеш булмаганны күрсә, ишетергә ярамаганны ишетсә, барырга ярамаган җиргә барса, алырга ярамаганны алса, аларны монда китерегез,— дип әйтте, ди. «Барыгыз, бишегез дә хәзер үк юлга чыгып китегез!» — дип озатты, ди, ул Капкорсак патшаның министрларын.

Биш министр да бүленеп, барысы да начар киемнәр киенеп, үзләре белән унар солдат алып таралдылар, ди, илнең төрле ягына: кайсы алланып торган кояш чыгышына, кайсы давыллы кояш баешына, кайсы күгелҗем диңгез артына, кайсы җып-җылы мич башына юлга чыктылар, ди.

Капкорсак патша буран уйната, Биксирәкне дә аратирә тиргәп елата, ди. Калган министрлар эчләреннән аныр сулыйлар: «Ни булыр, ни булыр икән?» — дип, берберсеннән сорыйлар, төрлечә уйлыйлар, ди. Ә юлдагылары — озын яллы, стакан тояклы аргамакларын, тимердән үргән камчылар белән кыздырып, һаман алга таба чабалар да чабалар, ди...

II

Зәңгәр күккә башлары тигән таулар уң якта, шомлы кара урманнар сул якта, көмеш тавышлы чишмәләр юл буйлап елан төсле боргалана-боргалана, чылтыр-чылтыр агып калдылар, ди.

Бер заман карасалар, министр һәм солдатлар ни күрсеннәр, тап-такыр юлдан таза һәм матур, күрер күзгә батыр бер кеше бара, ди. Үзе җилкәсе аркылы боргаланып-боргаланып беткән бер быргы таккан, ди. Быргысына ул бер өрсә, әлегә беркайда да ишетелмәгән, әлегә беркем дә белмәгән моңлы һәм дәртле көйне уйнап җибәрә, ди. Агачлар башларын җиргә тидергәнче бөгеп тыңлыйлар, яфракларын селки-селки рәхмәт укыйлар, ди. Таулар да бу көйне яраталар, аның тавышын, радио кебек, җирнең бар почмагына да тараталар, ди. Батыр егет уйнаган көйне бер генә ишетсәң дә истә кала, ди, аны бер җырлау да күңелгә бетмәс-төкәнмәс көч сала, ди.

Батыр егет янына җитүгә, солдатлар атларыннан төшәләр, ди, ә министр, ат өстендә килеш, уйнаучыга сүз кушты, ди:

— Әй, егет, кая барасың, ул нинди уең коралы, син нинди көчле көй уйныйсың, Канкояр белән Капкорсак патшалардан зарлана торган сүзләрең юкмы? — дип сорады, ди.

— Дөньяда туры юл эзлим, җиңүемнән өмет өзмим, подвалларда яшәүчеләрнең, ашсызларның, җирсез-сусызларның йөрәк моңын җыеп шул көйне тудырдым. Ул без-

не рухландыра, канатландыра, шатландыра,— дип әйтте, ди, батыр егет.— Фабрика-заводларда кул көчемне бик арзан саттым. Минем кул көчем аркасында күп капкорсаклар туенып ятты. Менә бу канечкеч патшалар, безнең канны сөлек кебек суыручы байлар, бүре кебек ерткыч министрлар булмаса, сез дә, мин дә бу хәлгә калмас идек,— дип әйтте, ди, ул тегеләрнең киемнәренә карап.— Эшлидер идем заводта, чыдап ачлыкка, инде аннан да кудылар. Хәзер мин эшсез, йортсыз, киемсез, бары суксам тимер өзәрлек кул көчем генә бар,— дип, йодрыкларын зәңгәр һавада селекте, ди, батыр егет. Аның куллары корыч төсле нык, йодрыклары берсе-берсе бишәр потлы герләр хәтле иде, ди. Ул кулларын селкегәндә, министр һәм солдатлар: «Менә суга, менә суга!»— дип шүрләп тордылар, ди.

Батыр егет сүзен сузды, ди:

— Канечкечләргә: патшаларга, байларга, министрларга каршы көрәшергә, әйдәгез минем белән киңәшергә,— дип, биек бер тау янына алып китте, ди, тегеләрне.

Атларын үсеп утырган агачларга бәйләп, Капкорсак ялчылары батыр егет алып барган урынга киттеләр, ди.

Тау итәгенә килеп җиткәч, батыр егет җиргә утырды да тагын сүз башлады, ди:

— Карагыз әле, егетләр, тауга!— дип әйтте, ди.— Ул нинди текә һәм биек, ул нинди югары... Җиңүгә булган өметебез дә шушы таусыман, ул нинди югары, ул нинди биек, җанга рәхәт бирүче, йөрәккә көч кертүче ул җиңү өмете. Шул җиңү өчен барыбызга да берләшергә, безне буучы ерткычлар белән ныклап көрәшергә кирәк, — диде дә, ди, сүзен бетереп:— Кая, егетләр, дусларча бер көйрәтеп алыйк,— дип, тегеләрдән тәмәке сорады, ди. Министр һәм солдатлар бары да берьюлы кесәләренә тыгылдылар, ди. Кайсы алтын савытларга салынган сигара, кайсы көмеш тартмалардан бармак юанлыгы калын папирос, кайсы атлас янчыклардан мунчала төсле чәбәләнеп беткән тәмәке чыгарып суздылар, ди, батыр егеткә. Ул берсен

дә алмады, ди, тик тирән итеп, бик тирән итеп шикләнеп карады, ди... Үз юлына таба кинәт борылып киткән иде, ди, «һап» эләктереп алдылар, ди, аны министрның солдатлары...

III

Давылланып торган кояш баешына карап киткән министр һәм солдатлар алтыннан ясалган егерме көпчәкле атсыз арбада таш юлны ду китереп, тузан туздырып, һава бозып кайтучы байны туктаттылар, ди. Аларның сәләмә киемнәрен күреп, болар юлбасарлардыр дип белеп, үзенең җитмеш җиде тапкыр ата торган мылтыгын кулына тотып, сүзгә кереште, ди, бай:

— Әй, юлбасарлар, миннән сезгә ни кирәк? Алтын сорасагыз, теләгәнчә бирәм, көмеш дисәгез, күмелгәнче китерәм,— дигәч сүз башлады, ди, министр:

— Безгә алтының кирәкми — үзебезнеке дә күп. Көмешең дә хаҗәт түгел — анысы да җитәрлек. Тик менә син әйт: Канкояр белән Капкорсак патшадан берәр төрле зарар күрмәдеңме?— дип сорады, ди.

— Нинди зарар күрим? Капкорсак патшаның атасы миңа завод салырга җир бирде. Баеган өстенә баетты. Минем кесәмне калынайтты. Минем рәхмәтемне җиткерегез ул Капкорсак патшага,— дип сүзен бетерде, ди, бай. Үзе егерме көпчәкле атсыз арбага кырын ятып, министр һәм солдатлардан шүрләп, күзләрен уйнатып, алтын стаканнарга кып-кызыл эчемлекләр салып бирде, ди, аларга. Йотылып-йотылып эчтеләр дә, үзләренең кемлекләрен белдерделәр дә, алга чаптылар, ди, алар.

Көн киттеләр, төн киттеләр, ай киттеләр, ел киттеләр, ниә буе җир киттеләр, ди.

IV

Күгелҗем диңгез артына китүчеләр дә ике кешене очраттылар, ди. Боларның берсе — ятьмә белән күбәләк тотучы бер бай малае, икенчесе — сука артыннан бил бөгүче бабай иде, ди.

Күбәләк тотып йөрүче малай болай дип җавап кайтарды, ди, министрга:

— Падишабыз безнең җир-суыбызны да, урман-болыннарыбызны да мул итте, гомере дә озын булсын аның,— дип әйтте дә, ди, үзен карый торган асрау янына йөгерде, ди.

Министр һәм солдатлар: «Безгә кирәкле кеше түгел бу!» — дип, күп вакыт уздырмыйча, тузан туздырмыйча, салмак кына атлап, алга юл тоттылар, ди.

Бераз баргач, еракта-еракта, күләгә кебек кенә бөкре бер шәүләне шәйләделәр, ди, алар. Барып җитсәләр: ак сакалы тезенә җиткән, чәчләре көмешләнеп беткән, аркасы бөкрәйгән, куллары кәкрәйгән бер бабайны очраттылар, ди, алар.

— Үз эшләгәнең үзеңә булмагач, рәхәтләнеп икмәк белән суга да туймагач, шулмы инде тормыш! Безгә дигән шомырт күк кара туфраклы җирләрне, хуш исләр аңкытып чәчәк ата торган болыннарны, кара куе урманнарны Капкорсак патша үз кешеләренә өләшеп бетерде. Ашъяулык кадәрле шушы җиремдә, тәртсәм аварга тора торган атым белән, эчемдәге янган ачу белән, безне изүчеләргә каргыш-ләгънәтләр яудырам. Җир астында күмер чабучылар, тауларны актарып тимер табучылар, зур-зур йортлар салучылар, барысы бергә оешып, Капкорсак патшага каршы кузгалырга җыйналалар дип ишеттек, шуларга кушылырга сүз беркеттек,— дип әйтеп тә бетерә алмады, ди, бабай, аяк-кулларын бәйләп, үзләре белән алып киттеләр, ди, аны Капкорсак патшаның ялчылары.

V

Таң беленер-беленмәс вакытта, җиде юл чатында, ярлы гаиләнең җиденче улы — житез егетне очраттылар, ди, министр һәм солдатлар.

Җитез егет таңның матурлыгына, сандугачларның чут-чут сайравына исе китмичә, болын, кырларда бил бөгеп,

тир түгеп эшләүчеләр тыңласыннар, дип, җырлап йөри иде, ди. Аның җырының түбәндәге кисәген генә ишетеп кала алдылар, ди, теге явызлар:

Ал нурларын чәчеп,
таң туа,
Туганкайлар, сез дә
күрегез,
Давыл кубар, тиздән
көчле давыл,
Хакыгызны даулый
белегез.

Озын яллы, стакан тояклы аргамагын туктатты, ди, министр:

— Син нинди егет, таң беленер-беленмәс борын, нишләп болай җырлап йөрисең?— дип сорады, ди, җитез егеттән.

— Күз алмам — әтием доктор иде, ул үз гомерендә төрле-төрле дарулар ясады, күп кешеләрне үлемнән коткарды. Ләкин дөньядагы сугыш дигән чиргә каршы бертөрле дә дару таба алмады. Үзе дә, мескенем, шунда һәлак булды. Җанкисәгем — әнием ачлыктан үлде. Инде мин дә җиде ят кулына калып каңгырап йөргәнче дип шушы биек күпердән, шушы төпсез елгага ташланыйм дип барганда, бернәрсәгә төшендем мин,— дип әйтте, ди, җитез егет.

Министр белән солдатлар бар да берьюлы хор белән:

— Нәрсәгә төшендең?— дип сорадылар, ди.

Аларның сорауларын көтмичә үк, пуля артыннан пуля яудырган кебек, сүз артыннан сүзне яудырып торды, ди, җитез егет.

— Канкояр патша үлгән дигәч шатланган идек. Аның урынына өлкән улы Капкорсак патша булды. Патша урынына патша бетәме соң,— дип әйтте, ди, җитез егет.

Озын яллы аргамакларын хәтфә кебек болынлыкка жи-

бәреп, хәерче булып киенгән киемнәрен төзәтеп тыңладылар, ди, аны министр һәм солдатлар.

— Минем бу хәлгә калуыма патшалар, байлар, министрлар гаепле. Болай гына үлмәскә, алар белән көрәшергә кирәклеккә төшендем мин,— дип әйтте, ди, ул. Ләкин инде соңгы сүзләр министрның чыдамлыгын тәмам бетерде, ди. Ул инде: «Ни карап торасыз?»— дип әләктерергә кушты, ди, җитез егетне.

VI

Алланып торган кояш чыгышына карап китүчеләр дә бик озын юл үттеләр, ди, ничәмә-ничә диңгез төсле зур күлләрне, олы чүлләрне кичтеләр һәм ап-ак кар белән капланган җиргә җиткәч очраттылар, ди, бер юлчыны. «Кирәкле кешебезне таптык!»— дип шатланып, үзләренең уңганлыкларыннан мактанып, бу юлчыны туктаттылар да, ди, һәм сорадылар, ди:

— Әй юлчы, кайдан кайтасың? Капкорсак патшаның атасыннан яки үзеннән зарланмыйсыңмы?— дип әйттеләр, ди.

Артлы чанага кырын яткан, төлке толыпка кереп баткан юлчы ак кәгазьдәй агарынып китте, ди: «Болар юлбасарлардыр, никадәр малым, никадәр байлыгым әрәм була бит»,— дип уйлап башлады, ди, сүзен юлчы:

— Без дин кешеләрен җирдәге гади эшләр бер дә кызыксындырмый,— дип суфыйланган иде, ди, юлчы, «Ансын яхшы беләбез», дигәч, әй өлкән кешеләр, Капкорсак патшага нинди яктан тел тидерим, ничек аны артка чигерим! Патшалар барысы да диннең зур таянычы алар, Канкояр патша дин өчен онытылмаслык хезмәтләр калдырды, бик күп итеп чиркәүләр, мәчетләр салдырды. Шулай булгач, ничек аны яманлыйм сезгә? Капкорсак патшаның да атасы юлыннан баруын телибез,— дип сүзен бетерде, ди, ул.

Үзе: «Алай-болай итмәсеннәр, мине талап китмәсен-

нәр!»—дип, министр белән солдатларның кулларына хәергә килгән алтын акчалар сузды, ди. «Акчаң булса, төрле җәфалардан да котылып була!»—дип уйлап, үз юлына тизрәк сызды, ди. Министр һәм аның солдатлары рәхмәт әйтеп, баш иеп, «Безгә кирәкле кеше түгел бу!» — дип атларын искән җилдәй җилдереп алга чаптылар, ди.

Көн киттеләр, төн киттеләр, ай киттеләр, ел киттеләр, инә буе җир киттеләр, ди.

VII

Хәерчелеккә баткан, күз яшьләренә чыланган, аһ-зар белән тулган ил елый. Күз яшьләре елгалар булып ага. Капкорсак ялчылары аны күрмәмешкә салыналар. Аһ-зарлар йөрәкләрдән сөрем булып күтәрелә — алар күрмәгән булалар, телләр туктаусыз хәсрәт сүзләрен сөйлиләр — алар ишетмәгән булып кыланалар. Зәңгәр күктә янган йолдызлар да бу илгә тирән кайгыру белән карыйлар, офтаналар, офыктан күтәрелгән кара болытлар да яумыйча таралалар. Җил дә әкрен генә исми — давыл булып котыра; яңгыр да, яварга тотынса, бөтен җирне су белән тутыра.

Давыллы кояш баешыннан батыр егетне, күгелҗем диңгез артыннан бөкре бабайны, алланып торган кояш чыгышыннан җитез егетне китерделәр, ди, теге явызлар Капкорсак патшага.

Ишәк акырган кебек ямьсез тавыш белән, эчендә янган ачу белән, күзеннән төтен пыскытып, авызыннан төкерек чәчеп, башлады, ди, сүз Капкорсак-туймас күз:

— Кош очып җитмәслек иләрдән, кеше аягы басмаган җирләрдән, җиде диңгез үтеп, шарлавыклар кичеп, минем илемә — Капкорсак патша җиренә килгән осталар остасы Бикзирәк, минем сезгә сүзем бар әзрәк,— дип әйтте, ди, Капкорсак патша.

Шул сүзләрне әйтеп, буе матча чаклы Капкорсак патша идән буенча бер атлаган иде, идән сыгылды, ди, икен-

че атлаган иде, үз аягына үзе абынып егылды, ди. Шуннан авызы тыгылды, ди.

Йөгереп килделәр, ди, караучылары, суздылар, ди, кулларын, алып салдылар, ди, алар Капкорсак патшаны алтын тәхетенә.

Күп җилләр искәч, күктәге кара болытлар күчкәч, биялә кадәрле килбәтсез күз кабагын ачып, чүмеч кебек зур күзләреннән төтен пыскытып, чөгендер төсле кызыл борыныннан пар пошкырып, иләктәй зур авызы белән көзге җил күк сызгырып:

— Өлгерәме таҗ минем башка?— дип сорады, ди, Капкорсак патша.

Бикзирәк-Сакалы сирәк:

— Икенче фәрманыгыз кичекми үтәлде, гаепле кешеләр китерелде. Көтәләр, күрәмсез, нинди җәза бирәсез?— дип, сүзне икенчегә борып, таҗ турында дәшми торып, тәрәзәгә таба бармагы белән күрсәтте, ди.

Бик күп халык җыйналган мәйданга батыр егет һәм аның иптәшләре китерелгәннәр иде, ди. Алтын тәхете белән күтәреп алып чыктылар, ди, Капкорсак патшаны җәза көтүчеләр янына.

Кала уртасындагы зур мәйданга чыжлап торган тал чыбыгы ташый башладылар, ди. Капкорсак патшаның болыннарындагы читән үрергә яраклы барлык таллар бөтенләй киселеп беткәннәр иде, ди.

Капкорсак патшаның атасы Канкоярның шул таллардан чыжлап торган камчылар ясатып, үзенә каршы килүчеләрне шулар белән шыр-ялангач килеш кыйнатып, үчел ачу гадәте бар иде, ди. Капкорсак патшаның бу ерткычлыгын да атасыннан калган бер гадәт кенә дип карадылар, ди, кайберәүләр.

Мәйданның бер почмагында дегет төсле кара төтен зәңгәр һавага үрелеп, аның астында кызыл телләрен сузган ялкыннар күренеп тора, ди. Кеше күтәрә алмаслык зур кадакны шул ялкыннарда кып-кызыл иттереп кыздырырга тотындылар, ди, явыз кешеләр.

Давылга бай кояш баешыннан китерелгән батыр егетнең телен шул кыздырылган зур кадак белән юан баганага кадаклап куйдылар, ди. «Менә сиңа сөйләргә ярамаган сүзләрне сөйләвеңнең җәзасы!» — дип әйттеләр, ди, ерткыч кешеләр.

Алланып торган кояш чыгышыннан китерелгән җитез егетнең шомырт кебек кара күзләренә кылдан нечкә итеп очланган инәләр кададылар, ди. «Менә сиңа күрергә ярамаган әйберләрне күрүеңнең җәзасы!» — дип шаркылдадылар, ди, җәзалаучылар.

Күгелҗем диңгез артыннан китерелгән бөкре бабайның колак яфракларын кисеп ташладылар, ди. «Менә сиңа ишетергә ярамаган сүзләрне ишетүеңнең җәзасы!» — дип авыз ердылар, ди, явыз кешеләр.

Шушындый бер әрну вакытында батыр егет үзенең уен коралында уйнарга теләде, ди. Җитез егет җырларга сорады, ди. Бөкре бабай, моңлы итеп, бик моңлы итеп карап, башын чайкады, ди.

Көлеп караган кояш чыраен сытты, ди. Әкрен генә искән җилдән давыл купты, ди. Офыктан болытлар күтәрелделәр, ди. Яңгыр китте, ди, янган утны сүндереп үтте, ди.

— Аларга бу җәза гына аз! — дип, Капкорсак бу өч бәхетсезне дар агачына китерергә кушты, ди.

Үзе, алтын тәхетенә утырып, шул өч мескеннең дарга асылган килеш, тыпырчынып-тыпырчынып җан бирүләрен, рәхәтләнеп, эче катканчы көлеп карап торды, ди. Өчесенең дә кайнар йөрәк каннарын алтын стаканнарга салып эчте, ди.

Батыр егетнең иптәшләре мәйданның иң аргы читенә генә җыелганнар иде, ди. Алар, батыр егет башлаган эшне дәвам итәргә ант итеп, эчләреннән янып, бу мескеннәр өчен сызланып торсалар да, кузгала да алмадылар, ди. Ялангач кылычларын җилкәләренә салган гаскәрләре Капкорсак патшаны саклап тордылар, ди.

Канкояр патша җәзалап үтерткән кешеләрнең сөяк-

ләрен җыеп, бу өч бәхетсезнекен дә шуңа кушып үзенә торыр өчен сарай салдырды, ди, Капкорсак патша.

Алтын белән тоташтырып, кеше сөякләрен берләштереп, ука-ефәкләр, ахак-бриллиантлар белән бизәп бер таҗ эшләде, ди, Бикзирәк Капкорсак патшага.

Кош очып җитмәслек алсу кояш баешыннан, кеше аягы барып җитә алмаслык кояш чыгышыннан, куктән дә күгрәк күгелҗем диңгез артыннан искән җилләр бу сарай нигезендәге сөякләрнең моңын тараттылар, ди, бар илгә.

Җир тетрәгән, күк күкрәгән, диңгез ташыган кебек, көчле ташкын булып, бу илнең батыр егетләре, ярлылары, бил бөгүчеләре, җитез егетләре, уңган кызлары күтәрелделәр, ди, Капкорсак патшага каршы. Аларның барысын бергә җыеп, аңламаганнарын аңлатып, күрмәгәннәрен күрсәтеп, җитәкләде, ди, аларны акыллыларның иң акыллысы. Бер кулында шәһитләр канына буялган кызыл байрак, ди. Анда утлы сүзләр белән: «Илнең ярлылары, җирсезләре, сусызлары, хокуксызлары, изелүчеләре, интегүчеләре, капкорсакларга каршы ут ачыйк, ачыйк!» — дип язылган, ди. Икенче кулына ул корыч мылтыгын кысып тоткан, ди. Изелгән илнең барлык почмакларыннан күтәрелеп, корыч ташкын шикелле алга омтылып, килеп җиттеләр, ди, алар Капкорсак патша сараена:

— Сезме безнең энеләребезнең йөрәк итен кимерүче?

— Сезме безнең кардәшләребезнең йөрәк канын алтын стаканнарга салып эчүче?

— Сезме безнең туганнарыбызның асыл сөякләреннән үзегезгә сарайлар салдыручы?— дип барып ябыштылар, ди, алар Капкорсак патшаның һәм министрларның бугазына.

Капкорсак патшаның министрлары, сакчылары, солдатлары тукталып-тукталып, хәл җыеп, хәл җыеп сугышып караганнар иде дә, булдыра алмый, кайсы кая качып беттеләр, ди.

Капкорсак патшаны юк итеп аның барлык министр-

ларын куып, яңа ил төзи башлаганнар иде, ди, яңа хуҗалар.

Ләкин егерме көпчәкле автомобильдә йөрүче бай, шомырт төсле кара туфраклы җирләрне биләп торучы алпавыт, дин богауларын өләшүче козгын — барысы бергә җыелып, тагын баш булмакчылар иде, ди, бу яңа хуҗаларга.

Бөек көрәштә корбан булучыларның каннары буялган байракны җилфердәтеп алгы җиңүләргә өндәде, ди, яңа хуҗаларның зирәк юлбашчысы. Бер селкенделәр — богаулар коелды, ди. Көч җыеп икенче селкенделәр — дошманнар чигенделәр, ди. Егерме көпчәкле автомобильдә йөрүчене, берүзе җиде йөз җитмеш дисәтинә җир биләүчене, дин богавы өләшүчене, бишкә алганны унбишкә сатучыны — барчасын күгелҗем диңгезгә батырганчыга кадәр кудылар, ди, яңа хуҗалар.

Бикзирәк-Сакалы сирәкне исән-сау калдырдылар, ди:
— Таҗлар урынына безгә пөхтәләп зур машиналар ясарсың!— дигән бурыч тапшырдылар, ди, аңа.

Тынычланып калды, иркен сулыш алды, ди, бу ил. Бу илдә инде эшче канын имүче сөлекләр дә, сука артыннан бил бөгүчеләрне изүчеләр дә бөтенләй калмадылар, ди.

Хәзер заводлар, фабрикалар батыр егетнең балаларына бирелгән, алар шатланып, рәхәтләнеп үзләре өчен үзләре эшлиләр, ди. Кара туфраклы җирләр, чәчәк атып, хуш ис аңкып торган болыннар бил бөгүче бабайның малайларына тапшырылганнар, алар сөенә-сөенә ул җирләрдә иген игәләр, ди. Житез егетнең балалары да бу илне сөяләр, аңа үзләренең акыл көчләрен кызганмый биләләр, ди.

Бернинди дә патша юк, ди, алар илендә. Алар үз илләренә үзләре баш булып яшиләр, ди. Яшәгән саен яшисе килә, һәр кичнең иртәсен, һәр төннең таңын күргән саен күрәсе килә, ди, алар илендә. Гөлгә төренгән ил, дөньяда иң бәхетле, иң матур ил — алар иле, ди.

АЕРЫЛГАННЫ АЮ АШАР, БҮЛЕНГӘННЕ БҮРЕ АШАР

Күз күреме җитмәслек, очына-кырыена чыгып бетмәслек бик зур бер болында күкрәшеп үләннәр үскәннәр. Чалгы белән чабарлык булып өлгергәннәр. Төрле төстәге матур чәчәкләр анда хуш исләр таратканнар. Кош-кортлар үзләренең матур сайраулары белән болынны яңгыратканнар.

Менә шундый матур болында ат көтүе йөргән. Дугадай муенлы, стакан тояклы аргамаклар болын үләнен ашаганнар. Туйганчы салкын чишмә суын эчкәннәр.

Бу атларның көтүчеләре булмаган. Бары тик үз араларыннан иң сылу, иң йөгерек, иң җитез Җирән Кашка гына көтүче хезмәтен үти икән. Ул, муенындагы кыңгыравын шалтыратып, башкаларны үз артыннан ияртә, барысын бергә туплап йөртә икән.

Җирән Кашка бөркөнне бик арыган булган, кичен аның йокысы калган булган. Ул ятып бераз хәл җыйнарга, йоклап алырга уйлаган. Иптәшләренең барысын бергә җыйган да әйткән:

— Аерылсагыз, айга җитмәссез, бүленсәгез, бүген бетәрсез, бергә йөрсәгез, рәхәт көн итәрсез,— дигән.

Атлар башта гел бергә йөргәннәр. Рәхәт көн күргәннәр. Кичкә таба берничәсе бик начар иткән, көтүдән аерылып киткән. Алар Җирән Кашканың сүзләрен онытканнар. Аның файдалы киңәшен тотмаганнар.

Аерылып киткәннәре килбәтсез зур бер аюга очраган-

нар, куркуларыннан һушсыз була язганнар, бик тиз генә кайту юлына борылганнар. Ләкин аю алар артыннан калмаган. Әй куган, әй куган, хәер, тота алмаган. Әй йөгергәннәр, әй йөгергәннәр атлар, юлларында тау очраган — йөгереп менгәннәр, урман очраган — аша чыкканнар, чокырдан сикерергә уйлаганнар — булдыра алмаганнар. Тирән чокыр эченә егылганнар. Аякларын сындырганнар.

Тагын өчесе көтүдән бүленеп киткән булган. Күп үтмәгән, алар да Җирән Кашканың туры сүзләрен исләренә төшергәннәр, үзләренең бүленеп китүләренә үкенгәннәр, ләкин инде соң булган. Каршыларына тешләрен шыкырдатып, күзләрен акайтып бер соры бүре килеп чыккан. Алар бу явыз дошманны күргәч, каушап калганнар, үзләрен-үзләре белештерми, ярсып, кайсы кая таралганнар. Бүре шунда ук бер атның бугазына ябышкан, буып алган, егып та салган, авызын ялый-ялый ашый калган. Калганнары әй йөгергәннәр, әй йөгергәннәр. Йөгерә-йөгерә көтүне узып киткән булганнар. Җирән Кашка муенындагы кыңгыравының матур шалтыравын ишеткәннәр һәм туптуры шунда карап киткәннәр.

Барысы да Җирән Кашкага үз башларыннан үткән хәлләрне сөйләп биргәннәр, аның туры сүзен тотмауларына бик үкенгәннәр. Ә Җирән Кашка башын чайкаган, кыңгыравын көчле итеп бер шалтыраткан — көтү бергә җыелган, тагын бер шалтыраткан да сөйләргә тотынган:

— Күрдегезме сүземнең дөреслеген: аерылганнар аюдан өркеп һәлак булдылар, бүленгәннәр бүрегә очрадылар, — дигән дә кыңгыравын өченче мәртәбә шалтыраткан һәм барлык аргамакларын болынга тараткан.

НЕЧКӘБИЛ

I

Каршыгызда, менә күрәсезме, нәрсә соң ул, беләсезме?

Шашка шакмаклары төсле тезелеп киткән йортлар. Ул йортларда яшиләр кортлар.

Кортлар? Нинди кортлар?

Татлыдан-татлы бал җыялар, шәмгә яраклы балавыз коялар. Ерак-ерак җирләргә очып китәләр. Укларын кадасалар, еларлык итәләр.

Аларның йортларын мәк чәчәге кебек кызылга, үлән төсле яшелгә, комсыман сарыга, күк төсле зәңгәргә, төрле-төрле матур төсләргә буяганнар.

Әнә теге читтә, кайгыдан кара коелып, мескен генә булып, бер багана тора. Элекке вакытта умарта кортларының оялары шундый булган. Ә хәзер инде ул искелек күренеше булып калган.

Белмәгәннәр белсеннәр, чагыштырсыннар, күрсеннәр, рәхәтләнеп йөрсеннәр безнең колхоз умарталыгында.

Әнә, зәп-зәңгәр офык читеннән көлә-көлә алтын кояш та күтәрелә. Аның шаян нурлары, җиз уклары умарта өйләренең стеналарына тияләр дә:

— Торыгыз, торыгыз, эшкә тотыныгыз,— дияләр.

Башта сирәк-мирәк кенә, берәмләп кенә, бал кортлары ояларыннан чыгалар. Кояш югары менеп киткәч,

һава җылынып җиткәч, көтүләре белән бергәләшеп, җиң сызганып, күмәкләшеп эшкә ашыгалар.

Зың-зың... Еракка-еракка, бакчаларга, кырларга, урманнарга, болыннарга...

II

Менә бу зәңгәр ояның хуҗалары бик күп аның. Кулыңдагы бармакларыңны мең тапкыр санасаң, яки күктәге йолдызларның санын исәпләп карасаң, бәлки аларның очына чыгарсың.

Көннең көн буена армыйча, ялыкмыйча-талмыйча, кыздырып йөри кояш. Һәрбер тереклекне: бөҗәкне, җәнлекне, хайван-терлекне, кешеләрне хезмәткә чакыра... Аның чакыру тавышына зәңгәр өйнең хуҗалары да колак салалар.

Барысыннан да алдан торып, «соңга калам ахры» дип, бар көченә йөгереп, менә шушы зәңгәр йортның ишегеннән, сөйгән өе эченнән Нечкәбил тышкы якка чыкты.

Алмагач биеклеге күтәрелгәч тә, зәңгәр өйнең кайдалыгын билгеләде Нечкәбил: «Усаллар килеп өйне алмаштырмасыннар, Нечкәбилне саташтырмасыннар». Шуңа күрә ул өйнең төсен җентекләп карады. Өйнең төсе күк төсле зәңгәр. «Сау бул, өйкәем, матур гөлкәем»,— диде Нечкәбил, өе өстендә бер-ике мәртәбә әйләнде дә ук шикелле туп-туры очты да китте.

III

Озак, бик озак очты Нечкәбил.

Өлгергән арыш, үзенең башакларын селкеп аны сәламләп калды, чәчәкләргә төренгән кыр алкышлап каршы алды.

Нечкәбил, кечкенә очкыч моделе төсле әйләнә-әйләнә, чәчәккә килеп төште... Тирә-ягы тулы чәчәкләр: ап-аклар,

сап-сарылар, зәп-зәңгәрләр, кып-кызыллар. Йомшак кына искән җил белән селкенәләр, йөрәкне җилкендерәләр. Тирә-якка хуш ис чәчәләр, әйтерсең, ислемай сөрткәннәр.

Бер чәчәктән икенчесенә, икенчесеннән өченчесенә күчә Нечкәбил.

Бер чәчәктән икенчесенә куна-куна, чәчәк тузанына буялып бетә. Ул тузанны бер чәчәктән алып, икенчесенә калдырып китә. Шулай итеп уңышны күтәрүдә ярдәм итә.

IV

Чәчәктән чәчәккә күчкәндә, аларның татлы суларын эчкәндә, Нечкәбилгә бер саранча очрый.

Җитмәсә: «Әй йонтач!» — дип, Нечкәбилгә эндәшә.

— Минем исемем Нечкәбил, сүзең булса, якын кил,— ди Нечкәбил.

Саранча, якынрак килә дә, Нечкәбилнең ни эшләп йөрүен сораша, аннан үзе турында да сүз ача:

«Минем бабаларым бу илгә ачлык елны Иран якларыннан очып килгәннәр. Күрәсең, монда тормыш шәбрәк, дип белгәннәр. Ләкин кешеләр аларны агулап үтергәннәр, канаулар казып күмеп бетергәннәр. Шомырт түшле сыерчыкларга кадәр безне берәмләп чүпләгәннәр».

Нечкәбил каршы җавап кайтара. Җавапны тыңлаган саранчаның күзләре акая.

— Үзләренә файда китерсәң, кешеләр агулап та үтермиләр, күмеп тә бетермиләр. Җылы өй ясап үрчетәләр, тәмле ширбәт эчертеп үстерәләр. Игеннәрнең башларын коеп йөргәч, нигә үтермәсеннәр,— дип, Нечкәбил сүзен бетерә. Нәкъ шул вакыт һавада сыерчыклар көтүе күренә. Арадан берсе, артык тересе, чем-кара түшлесе, теге саранчаны тота да йота.

Саранча турында сүз дә шуның белән бетә.

Ә безнең Нечкәбил алга таба очып китә.

V

Чәчәктән чәчәккә күчкәндә, баллы сулар эчкәндә. Нечкәбилгә тагын кемдер эндәшә, үзе янына дәшә:

— Чага торган кортчык, минем яныма килеп чык,— ди.

Нечкәбилнең исе китми, аның янына бармый-китми:

— Минем исемем Нечкәбил, булса сүзең, үзең кил,— ди.

Бусы да кешеләрдән, хайваннардан зарлана: «Кайсы кулы белән бәреп үтерә, кайсы койрыгы белән сыпырып бетерә,— ди.— Кояш нурларыннан куркам, шуңа күрә яфрак астында посып утырам, ауга да көндезен сирәк чыгам»,— ди.

Нечкәбил саранчага биргән сабакны, аңа әйткән туры җавапны моңа да әйтә:

— Кан эчәбез дип кеше борчыйсыз, бизгәк авыруы таратып йөрисез!

Кичтән ач калган озынборын Нечкәбилнең үткен сүзләрен тыңламый-нитми, чүп утаучыга таба: «Җизни, җизни, күңелем синнән бизми!»— дип безелди-безелди кан эчәргә оча. Утаучы да аның килеп кунганын гына көтә, озынборынны шунда ук юк итә.

Аның турында да сүз шуның белән бетә.

Ә безнең Нечкәбил башка чәчәккә күчә.

VI

Чәчәктән чәчәккә очканда, мәк чәчәгендә бал суырып ятканда, калын тавыш белән тагын кемдер эндәшә:

— Бал корты, бал корты!— ди.

— Минем исемем Нечкәбил, сүзең булса, монда кил!

Үлән арасыннан выжылдау ишетелә, ике канатлы, алты аяклы, яшел башлы, күгелҗем кашлы кигәвен килә. Кигәвен Нечкәбил янына килеп җитә. Аннан үзара исәнлек-саулык сорашу башланып китә.

Кигәвен Нечкәбил янына чәчәк урындыкка утыра да елларның «авырлыгыннан» зарланырга тотына:

— Печән чабу вакытын без өзелеп көтәбез, хәер, аннан соң үзебез дә үлеп бетәбез. Шул вакыт безнең өчен азык күп була. Атлар, тайлар, кешеләр белән бөтен болын тула. Ә бу елларда атлар, печән чабучылар урынынаниндидер машина килә. Үзенә тагылган машинасы — чалгысы белән бер-ике көндә бөтен болынны чабып та китә. Ул машина үзе һаман пошкыра, тирә-юньне бик тәмсез ис белән тутыра. Шул машинаның сыртына да кунасың, үзеңчә татлы итеп тешләгән дә буласың, һич тә рәт чыкмый.

Нечкәбил авызын ерып көлә дә, бер-бер артлы тезеп, сөйләп тә китә:

— Ул болыннар элек алпавыт болыны иде. Хәзер аны совхоз болыны диләр. Тәмсез ис чыгара торган машинаны трактор дип атыйлар. Аңа керәчин ягалар, ә артына чабу машинасы тагалар.

Нечкәбил аңа үзенчә аңлаткан була, җиренә җиткереп сөйләп тора, ә ул, явыз, тир исен сизә дә сыза, Нечкәбилнең кәефен боза.

Нечкәбил артына әйләнеп караса: такыр гына юлдан атын куа-куа юлчы бара.

Нечкәбил аның дугасына күзен сала, теге, хәерсез, кигәвен шул дугага кунып бара, аннан ат ботына куна һәм ат аны койрыгы белән җиргә бәреп төшерә.

Кигәвен турында да сүз шуның белән бетә.

Ә безнең Нечкәбил исән-сау очып китә.

VII

Үз эше белән мавыгып йөргәндә, бик матур гына бер чәчәк күргәндә, Нечкәбилгә тагын кемдер эндәшә:

— Әй, бал корты — Нечкәбил, минем янга очып кил,— ди. Нечкәбилне үзе янына дәшә.

Нечкәбил борылып караса: ни күзе белән күрсен, алдында озын билле энә карагы. Дүрт канатлы, симез аяк-

лы, яшел төймә төсле башлы. Үзе пыр-пыр итеп оча, чәчәкләргә куна, ул да, мескенчәгем, чәчәк балын авыз иткән була.

— Гомеремдә минем энә түгел шырпы да урлаганым юк, нигә мине карак диләр?— дип зарланырга тотына...

Кояш инде төшлектән узган. Нечкәбилнең тамагы да туйган, эче дә тулган, өенә кайтырга кирәк. Шуңа күрә ул энә карагының зарлануын тыңламый-нитми:

— Сау бул,— ди дә китә.

Энә карагы турында сүз дә шуның белән бетә.

VIII

Оча-оча шактый кителгән, ун километр ераклыктагы урман артына барып җителгән. Өенә кайтырга чыккач, Нечкәбилне дулап искән җил каршы ала. Җитмәсә, көньягыннан күк күкрәп болыт та кузгала. Җил котырып исә, очучы чыпчыкларны да, кечкенә кошчыкларны да үзе белән ияртеп алып китә. Җил бит ул менә нинди тиле, Нечкәбилне дә әллә кая алып китәргә тели. Нечкәбил карыша, җил белән тартыша.

Мескен Нечкәбил бик арыган була, җитмәсә, кайтып җитәм дигәндә генә, яңгыр астында кала.

— Инде нишләргә?

Нечкәбил аптырамый, ул шунда ук таба яхшы юл — әрекмән яфрагы астына керә, шулай итеп яңгырдан яшеренә.

Үкереп искән җил болытларны куа... Бераздан яңгыр да тына, ялтырап кояш та чыга. Аннан Нечкәбил дә кайтырга чыга.

IX

Алып кайткан балын, ашый торган азыгын кәрәз күзәнәгенә салыйм дисә, ни күрсен Нечкәбил: ятьмәдән эшләнгән битлек кигән бабай, шундый ук битлекле бер малай Нечкәбилләр өенә тәтен өрдерәләр, ә умарта кортла-

ры, төтеннән куркып, тышка йөгерәләр. Карышучыларны һәм рамда калучыларны йомшак канат белән себерәләр. Бал тулы рамнарны бал суыртучыларга илтеп бирәләр.

Әнә анда ак калайдан эшләнгән бал суырту машинасы әйләнә. Күзәнәкләрдәге сыек бал, суырту көченә каршы тора алмыйча, машина стенасына сибәли.

Аннан соң татлы бал такта чиләккә су кебек агып төшә. Тирә-якка бал исе сибелә, сизгер бал кортына гына түгел, бу ис безгә дә сизелә.

Ә нигә соң бал кортлары килмиләр. Савыт тирәли выжылдап очып, йөдәтеп йөрмиләр. Чөнки моннан башка чәчәкләрдә дә бал күп, барлык умарта кортлары да тук. Ә менә син, табыш беткәч бал исе чыгарып кара, ничек чыдарсың, бичара! Умарта кортлары савытыңны сырып алырлар, кайсылары балга батып, чыга алмый да калырлар. Булышырга шөпшәләр дә килеп җитәр, чиләк эчендәге балың минут эчендә бетәр.

Әлегә җан тыныч, һич юк куркыныч. Агач чиләккә бал ага, кәрәз күзәнәкләре бушап кала.

X

Ә аннан соң тагын кызу эш башлана. Күмәк хезмәтчеләр барысы да кәрәзгә ташлана. Кәрәзнең күзәнәкләрен төзәтергә, яшь балаларны тәрбияләп, күзәтергә, күзәнәктә төренеп яткан бал кортларын җылытырга, өй эчен чиста тотарга...

Балавыз төсле соры, озынча гәүдәле, кыска канатлы, бөтен ояда бердәнбер булган ана корт кәрәз күзәнәге саен йомырка салып йөри.

Юан сорыкортлар симереп, эшче кортлар ташыган балны ашап, кикереп яталар.

Бөтен эш эшче кортлар җилкәсендә: алар бал җыялар, балавыз сузалар, бала тәрбиялиләр, йорт эшен дә эшли-

ләр. Үзләре бик көчле булалар, дошманга каршы да торалар.

Безнең Нечкәбил дә эшче корт, аның да җилкәсендә зәңгәр йорт.

XI

Көннәрнең берендә калынаеп кына, авыраеп кына Нечкәбил эштән кайтса, хәйранга кала. Зәп-зәңгәр өйләренең ишегеннән бал кортлары бертуктаусыз атылып чыгып торалар, көтүләре белән очалар, сорыкортлар выжылдыйлар.

Очалар да очалар кортлар, ояларына кире кайтмыйлар, кояшны кечкенә генә болыт кебек каплыйлар.

— Ни булган?

— Кем тия?

— Нигә болай бал кортлары тузгыйлар?

Бал суырткан бабай белән әлеге малай шатланып йөриләр:

— Умарта аера,— диләр.

Алмагач ботагына беренче булып ана корт куна. Шул урынга ук эшче кортлар да куналар, бары да бергә җыйналалар, күп булалар. Йон йомгагы төсле булып, корт иле алмагач ботагын сара.

Әлеге бабай белән шаян малай илнең сарып бетүен генә көтәләр, кабыктан эшләнгән тубал алып киләләр. Һәйбәтләп аңа лимон мае сөртәләр. Бабай туз кашык белән җайлап кына кортларны тубалга соса башлый. Бик күп сандагы башка кортлар белән бергә таныш булган Нечкәбилне дә тубал эченә ташлый.

Тубал эчендә җулау башлангач, яртысыннан артык ил тубалга тупланган, бал кортлары үзләре үк тубалга керә башлыйлар.

Бал кортлары кереп беткәч, бабай тубалның авызын бәйләп куя. «Тубалны, улым, син салкынча урынга куй»,— дип, аны малайга тапшыра. Үзе яңа семья өчен яңа йорт хәзерләргә керешә.

XII

Эш шулай булган да булыр иде. Лэкин бабай белэн теге шаян малай аны көтеп тормадылар, хәйләлерәк юлны сайладылар. (Мин генә сезгә шулай язып үттем, сезне дә әз генә алдалап киттем.) Зәңгәр өй урынына шуның төсле үк өйне китереп куйдылар, ә тегесен күздән җуйдылар. Умарталыкның теге башына илттеләр дә, үзләре тыныч кына кайтып киттеләр.

Берни булмаган төсле эшче кортлар бал эчәргә ашыгып очтылар, тик инде төп йортка кайтмадылар, шикләнсәләр дә яңа куелган өйгә кереп тулдылар. Төп йорт зәгыйфьләнебрәк калды, яңа йорт үсә башлады. Ятим иделәр, ана чакырдылар, менә дигән итеп тора башладылар.

XIII

Лэкин яңа өйдә әле ярлылык.

Рамнарның әле тирән күзәнәкле кәрәзләре юк. Яңа өйдә әле бер тамчы да бал юк. Ясалма кәрәзләрне бал салырга яраклы итеп, тартып-сузып эшлисе бар.

Һичнигә карамый яңа хуҗалар үзләренчә җан-фәрман тырышкан булалар: бал ташыйлар, кәрәз ясыйлар.

Зур дәрт белән эшләгәч, көчеңне кызганмагач, яңа йорт та аякка баса.

Лэкин...

Кышка бал хәзерләнеп җитте, инде баштан кайгы китте дигәндә генә, әлеге бабай белән теге шаян малай килеп, баллы кәрәзләрне кистеләр дә алып киттеләр. Суырылган балны кешеләргә — колхозчыларга бирделәр.

XIV

Менә кортлар өчен күңелсез көз дә җитте. Кырда, болыннарда чәчәкләр күптән бетте. Суык җилләр исә башлады. Нечкәбил дә хәзер бал алып кайтмады.

Көннәрнең дә яме китте, кышка җыенырга вакыт җитте.

Сорыкортлар үзләре бал җыймыйлар, бик юашлар, чага да белмиләр, ә бит менә кышка дигән азыкны ашап йөриләр. Семьядагы шулкадәр сорыкортны кышлатсаң, азык күп китә, эшчеләрнең азыклары үзләренә генә җитә, шуңа күрә сорыкортларны бүгеннән үк үлем көтә.

Сорыкортларга — әрәм тамакларга каршы сугыш башлана. Нечкәбил бер симез сорыкортның җилкәсенә менеп атлана. Сугыша-сугыша очып барышлый, әрәм тамакның билен кыеп ташлый.

XV

Нечкәбил бүген ишек янында, бернинди корал юк кулында, ләкин үзе сакта тора. Җәй көне бер корт та сакламады ишекне, өй эченә кертә торган тишекне, ә көз булгач, саклау нигә кирәк? Кайсыгыз зирәк? Әйтегез әле тизрәк.

— Әнә, күрәсезме, кара гына, шома гына бер эшче корт өй тирәсендә әйләнә: өйгә керергә исәбе, белә ул кая яшерелгән бал кисмәге. Балны урлап ашарга да, җәһәт кенә качарга...

Умартачы бабай зәңгәр йортның ишеген кыса төшкән, моның белән Нечкәбилгә бик зур ярдәм иткән. Саклау өчен эш җиңелләшкән. Шуңа күрә ул постында нык тора, килгән каракларның барысын да кире бора.

XVI

Беркөнне умартачы бабай белән әлеге малай умарталарны кышлыкка хәзерләп йөриләр иде.

Яңа семья йортының эчке катын бөтенләй алып ташладылар. Җылырак булсын өчен, аскы катны да кыса башладылар.

Болай актарынуга Нечкәбил иптәшенең бик ачуы килде. «Ахры, соңгы балыбызны да алырга килгәннәр»,— ди-

де дә әлеге шаян малайның борын очына гына үзенең угын кадады.

Малай үрле-кырлы сикерде, түзә алмагач, елап ук җибәрде.

Ак сакаллы бабай җитди төс алып:

— Әйттем бит мин сиңа көз көне бал кортлары ачулы булалар, дидем, ә син битлек кимәдең, карыштың,— дип малайны орышты.

Бал кортының агулы угы малайның борынында утырып калган иде. Угы белән бергә аның эчәгеләре дә чыкты. Ул башта очып киткән булды, ләкин озак оча алмады, үлде.

XVII

Яфраклар коелып беткәч, кошлар җылы якка киткәч, бал кортларының ояларын җылы урынга кышларга күчерделәр.

Нечкәбилнең зәп-зәңгәр өен башка бик күп өйләр белән кышларга керттеләр.

Әкият тә шуның белән бетте.

КЕМ КӨЧЛЕ?

Кышын да үзенең яшеллеген җуймый торган нарат агачы астында түмгәксыман бер өй калкып тора. Беләсезме сез, аның эчендә берничә йөз мең халык тора. Өйләренең ишекләрен алар көндезләрен ачык тоталар, ә төннәрен биклиләр, карак керүдән шикләнәләр, кичке салкын керүдән шүрлиләр. Төне буе чүп-чар җылысында җылынып яталар да, кояш елмаеп карауга, ишекләрен тагын тутырып ачалар.

Бүген алар яңа өйгә күчену көнен шатланып бәйрәм итәләр. Кичә уздыралар, дус-ишләрен сыйлыйлар, тәмле-тәмле ашамлыклар ашыйлар, балдан баллы эчемлекләр эчәләр, ду килеп биләр.

Зур өстәл тирәли кунаклар тезелешеп утырганнар. Һәрбер кунакка үзе яраткан сый хәзерләнгән, өстәл өсте аллы-гөлле чәчәкләр белән бизәлгән.

Чикерткә кунакның кәефе бик килгән, аңа урынның менә дигәне тигән. Әнә, ничек ул озын мыекларын болгап утыра, күп тә үтми, оста җыры белән хуҗалар һәм кунакларның күңелләрен тапмакчы була.

Суалчан-оялчан да тик кенә утырмый, оста биюче төсле, боргалана да сыргалана, хуҗалар һәм кунакларга ошарга тырышып кылана.

Чебен дә канатларын кага, үзенчә, бу күңел ачу кичәсен алкышлап кул чаба.

Агач иясе-яфрак көясе дә кукраеп утыра, күп тә үтми, кичәдәгеләрнең карашын үзенә таба бора. Һәрберсе үзе-

нең һөнәрен күрсәтә башлаган, ул да, түзми, йонлач гәүдәсе белән өстәлгә менеп бии. Хуҗалар һәм кунакларның кәефе килсен дип, кичә күңелле үтсен дип, бертуктамый сикерә дә сикерә, кайбер кунакларның эчемлекләрен дә түгеп бетерә.

Күбәләк-түгәрәк бу кичәгә бөтенләй чакырылмаган да булган, янган ут яктысын еракта күргән дә, тиз генә очкан да килгән. Әрсез кунак, канатларын җилпеп, җил туздыра, мәҗлестәгеләргә яраурак булсын өчен тырыша.

Сезгә таныш булган Нечкәбил дә мондый зур кичәдән калмаган, тырыш бал корты түргә менеп утырып алган да эшләпәсен кыңгыр салган.

Үрмәкүч тә үрмәләп килеп җиткән: «Мондый күңелле кичә бездән башка гына үтмәсен әле»,— дигән.

Менә хуҗаларның берсе күтәрелде һәм кичәне ачык дип белдерде:

— Кадерле кунаклар,— диде ул.— Сез бүген кырмыскалар өендә, безнең яңа өйгә күчү хөрмәтенә үткәрелә торган кичәдә утырасыз,— диде. Без бу йортны күп айлар буе төзедек һәм үзебезнең теләгебезгә ирештек. Тир түгүләребез бушка китмәде, уңышлар җиңел генә бирелмәде,— дип сөйләп китте ул.

Бу сүзләр кунакларга нык тәэсир итте, суалчан-оялчанның хәтта йөрәгенә үк барып җитте. Ул инде чыдап кала алмады, хуҗаларының уңганлыкларын, булдыклылыкларын мактады. Башкалар да аңа кушылдылар, хуҗаларны котлап «урра» кычкырдылар, кул чаптылар, алкышладылар.

Кичәнең бу өлешен шуның белән туктатып тордылар, чүп-чарлардан, яфрак-үләннәрдән, чыбык-чабыклардан төзелгән өйне карарга тотындылар. Борылмалы-сырылмалы юлларны үттеләр һәм сырлы-сырлы баскычлар аша түбәнге катка төшеп киттеләр.

Төшсәләр, ни күрсеннәр, бу катта кырмыскалар бөтенләй диярлек күренмиләр, монда тик теләләр генә үрмәләп

йөриләр. Моны күреп, кунаклар бары да хәйран калдылар, берьюлы сорау бирделәр:

— Болар соң сезгә кемнәр? Нишләп монда буталып йөриләр?

Хуҗаларның берсе кунакларга эшне төшендерде. Ләкин җавап кайтарганчы бал корты Нечкәбилгә бер сорау бирде:

— Нечкәбил, сез татлы гына бал ашадыгызмы? — диде ул.

Бал корты башын иде дә менә болай диде:

— Гаҗәп тәмле булды балыгыз, инде үзегез кунак булып безгә барыгыз.

— Менә шул теләләр, безгә ул балны бирәләр. Без аларны савым сыеры итеп тотабыз, салкын көннәрне аларны ояларыбызда җылытабыз. Кояшлы көннәрне һавага чыгарып йөртәбез, кич белән кире өебезгә куып кертәбез. Алар чәчәкләр балын бик яратып суыралар, кытыклый башласаң, эчләрендәге шул балны безгә бирәләр алар,— ди кырмыска.

Кунаклар башларын селкеп хәйран калдылар. Сүз беткәч, кузгалдылар, борылмалы-сырылмалы юллар белән алга таба атладылар.

Өченче катта инде алар ап-ак йомыркаларны очраттылар, нәрсә икәнен белгәнгә сорап тормадылар, алга юл тоттылар.

Кырмыскалар йортын кунаклар җентекләп йөреп чыктылар, аның һәр почмагы белән таныштылар. Моннан соң тагын өскә күтәрелделәр, баягыдан да күңеллерәк итеп, кичәне дәвам иттерделәр, күп тә үтмәде, кунаклар инде яхшы ук кызып җиттеләр, бер-берсе белән кызу-кызу сөйләшеп киттеләр. Күбесенең авызы сөйләгәнен колагы ишетми башлады, сүзләре чуала, фикерләре бутала, телләре бәйләнә, башлары әйләнә башлады. Шул чак баягы кырмыска тагын күтәрелде ахры, үзләре турында кунаклардан мактау сүзләре ишетәсе килде, шул теләк белән, ул аларга шушы сорауны бирде:

— Куе урманнардан, киң кырлардан, яшел болыннардан, тирән сулардан килгән кадерле кунаклар, әйтегез әле, көчледән-көчле кемнәр алар?— диде ул. Билгеле, аның: «һичшиксез кырмыскалар, дөньяда тиңе булмаган батырлар алар»,— дигән җавапны ишетәсе килде.

Нәкъ шул чак нидер бик каты шап итте, өй эче тетрәп китте. Сүзчән кырмыска каядыр югалды, кунаклар кайсы кая таралды.

— Кадерле кунаклар, каушамагыз, таралмагыз. Кичәнең ямен бозучы, кунакларның кәефен бозучы дошман тотылды,— диде әлеге кырмыска, ләкин кунаклар аның сүзен тыңламадылар, ничек булса да бу өйдән тизрәк сызу ягын карадылар... Бары берьюлы тышка йөгерделәр һәм өйнең тышкы ягында коточкыч хәлне күрделәр. Зур башлы, кызыл билле кырмыскалар нәрсәнедер сырып алганнар, үзләренең үткен келәшчәләрен аңа батырганнар. Канатлы кырмыскалар: «Бирегез шул явызның кирәген!» — дип кычкырып торалар, әйтерсең, тегеләрнең көчләрен арттыралар.

Шундый каты көрәшне күргән чебен таңга калды, суалчан шуышуыннан тукталды, яфрак көясе тынын да көчкә генә алды. Бал корты, очып китәргә дип, канатларын җайлады, чикерткә сикерергә дип, җайлы урын сайлады.

Үлән арасыннан мыштым гына, берәүгә дә сиздерми, тын гына үрмәли торган кара елан үрле-кырлы сикерде. Зәһәрле телен чыгарып, агуын чәчеп карады, кырмыскаларны чагарга уйлады. Кырмыскалар еланны аның саен катырак тешләделәр, үзләрендәге кислотаны елан тәненә җибәрделәр.

Елан, булдыра алмагач, каршы торуын ташлады һәм мескен тавыш белән генә ялвара башлады:

— Зинһар, тимәгез, зинһар, җибәрегез. Үзегезгә түгел, кунакларыгызга да тимәм, өй янызыдан да үтмәм. Бер юлга инде кичерегез, азапламагыз, котылдырыгыз.

Ул шундый йомшак сүзләр белән кырмыскаларның

күңелен йомшартмакчы, бераз гына хәл җыймакчы һәм аннан тагын көрәшне башламакчы иде. Тегеләр дә бик сизгерләр, хәйләне тиз сизделәр, җәзалауларын дәвам иттерделәр:

— Нигә өебез аша үтеп йөрисең, монда кырмыскалар торганны әллә күрмисең? Менә дигән кичәбезнең ямен китәрдең, кадерле кунакларыбызның кәефен җибәрдең. Шуңа күрә сине җибәрмәячәкбез, хәзер үк итеңне ашап бетерәчәкбез,— диделәр.

— Мин бит агач башына гына менгән идем,— диде елан.— Шуннан ялгыш кына егылып төштем,— диде елан. Ялвару да файдасызга булды, елау да бушка чыкты. Кырмыскалар аның итен бик тиз ашап бетерделәр. Кунаклар бар да, таңга калып, шул хәлне күзәтеп тордылар. Кырмыскаларның батырлыкларын мактадылар:

— Нинди усал дошманны да менә нишләттеләр, көчлелекләрен эш белән күрсәттеләр,— диделәр.

Батыр кырмыскалар еланны юк иткәч, кунаклар тагын бер җиргә җыелдылар, урманның саф һавасында, агач ышыгында тагы бераз күңел ачмакчы булдылар.

Ләкин баягы кырмыска үзенең соравын тагын кабатлады, җавап көтеп кунакларга карады:

— Куе урманнардан, киң кырлардан, яшел болыннардан, тирән сулардан килүче кадерле кунаклар, безнең арабызда көчле бөҗәкләр кемнәр алар?— диде ул.

Елан белән оста көрәшүләрен дә күргәч, шундый матур өй төзүләрен дә белгәч, ул кунаклардан шушы бер генә җавапны көтте:

— Билгеле, кырмыскалар, дөньяда тиңе юк батырлар алар!

Ләкин кунаклар җавап бирергә ашыкмадылар. Һәркайсы үзләренең һөнәрләрен һәм үз батырлыклары турында сөйләргә тотындылар.

Чикерткә-микерткә җиләк яфрагына менеп утырды, озын аякларын җайларга тотынды. Бөтен кунаклар аңа

карадылар, нишли инде бу? — дип көтеп тордылар. Ул озын аяклары белән бер кечкенә яфракны этте, очкыч шикелле очып та китте. Кунаклар аның һөнәрен бик мактадылар, шулкадәрле ерак сикерә алуына таңга калдылар. Чикерткә сикерүне шунда туктатты һәм кунакларны тагын үзенә тартты. Яфрак өстенә баскан килеш кычкырып сөйләп китте. Кунакларның барысына да ишетелерлек итте: чикерткәләр, имештер, әле җырга да бик оста булалар, сайраулары белән, имеш, сандугачларны уздыралар, ә сикерсәләр инде, уктай атылалар. Имештер, чикерткә инде иң көчле бөҗәк, бер метрга сикерү өчен, беләмсез, никадәр көч кирәк? Дөрес, ул чикерткәләрнең кырмыскалардан күп җәфа күрүен, күпләрнең алар тарафыннан үтерелүен дә сөйләмәкче иде. Ләкин шунда ук ул кырмыскаларда кунакта булуын хәтерләде, мондый сүзләр өчен үзен юк итәрләр дип шүрләде, шуңа күрә бу хакта ләм-мим дәшмәде.

Күп тә үтмәде, икенче кунак кузгалды: суалчан-оялчан боргаланды да сыргаланды, ул да суалчаннарның зур хезмәте турында сөйләргә уйлады. Берәүгә дә күренмичә шуышып килде һәм үлән сабагына үрмәләп менде.

— Без, суалчаннар, җир балалары,— диде суалчан.— Көнебезне һәм төнебезне хезмәт белән үткәрәбез, сабан төсле, туфракны күтәрәбез, өске катын аска төшерәбез, аскы катын өскә мендерәбез. Яңгыр соңыннан җирдәге менә вак тишекләргә һәм нәни өемнәргә күзегезне салыгыз, бер генә минутка карап алыгыз. Болар бары да безнең хезмәтләр.

Әнә шул тишекләр аркылы туфрак эченә һава үтә ала. Ул һава белән үсемлекләрнең тамырлары сулу ала. Без туфракның уңыш бирүчәнлеген күтәрәбез, без агротехника чараларын үткәрергә кешеләргә ярдәм итәбез. Әгәр без булмасак, җир өстендәге үсемлекләр хәзергедәй гөрләп тормаслар иде. Һәм уңышны да хәзергедәй мул бирмәсләр иде. Ә инде ул вакыт Нечкәбил белән чикерткәсенә, шулай ук яфрак көясенә, күбәләгенә һәм кырмыс-

калар армиясенә хәзерге төсле яхшы булмас иде,— диде ул.

Кунаклар аны тыныч кына тыңладылар, һәр сүзе дөрес икәнлеген белсәләр дә, кул чапмадылар. Берсенең дә суалчанны иң көчле итәсе килмәде. Суалчан туктамады, сүзне сүзгә ялгады:

— Безнең төсле, үсемлекләр өчен кайсыгыз тагы зур файда китерә? Тагы кайсыгызның кулыннан шундый эш килә, шушындый файдалы эшне кайсыгыз тагы башкара ала? Суалчанның иң көчле бөҗәк икәнен хәзер инде аңлагансыздыр, аларның тиңсез хезмәтләрен үзегезнеке белән чагыштырып карагансыздыр.

Билгеле, аның әле бик күп сөйли торган сүзләрә калды, ни өчендер, ул суалчан ашаучы кошлардан, сукыр тычканнардан, энәле керпедән, төрле коңгызлардан, кармак очына куючы шаян балыкчылардан бер дә зарланмады; кырмыскаларга да кагылып үтмәде.

Ул туктагач, бераз гына тын алгач, агач башыннан бер тавыш ишетелде, кемдер: «Яфрак көясеннән дә файдалы бөҗәк бармы икән?»— дигән сорауны бирде. Барысы да әйләнеп агач башына карадылар, яшел яфрак өстендәге йонлач көяне күреп алдылар. Көя пәрвез сузарга да, үрмәләргә дә — барысына да житеште, ямьяшел матур яфракларны минут эчендә тиште. Ләкин кунаклар аның мондый оятсызлыгына түзеп кала алмадылар, төрле яклап кычкырына башладылар:

— Нигә ялганлыйсың?

— Тузга язмаганны сөйлисең!

— Күзгә карап алдалыйсың!

— Яфрак көясеннән дә файдалы бөҗәк бармы икән дисең, кемнең кем икәнен безне әллә белми дисең? — диештеләр. Кунаклар бераз тынычлангач, яфрак көясе тагы дәвам итте, ялганын тезеп китте.

Имештер, әй кыен эш соң калын яфракларны кимерү, ихтимал, җиңелрәктер тау-ташларны җимерү. Яфракларны үтәли кисү — күп көч сорый торган эш, шулай бул-

гач, билгеледер инде кемдә күп көч. Имештер, бернәрсәгә дә зарар китермибез, бернәрсәгә дә тимибез.

Күбәләк-түгәрәк аның сүзләренә чыдамады, чәчәк урындыгыннан кузгалды. Пыр-пыр итте дә агач башыннан очып килеп җитте.

— Ничек инде зарар китермисез?—диде ул. Якындагы бер агачка күрсәтте һәм өстәп әйтте:— Сез яшәгән агачлар әнә ничек шыр-ялангач булып, яфраксыз калалар, агачлар, үсемлекләр бары да сездән зарланалар. Яшел яфракны әрәм итәргә, матур үсемлекләрнең ямен бетерергә күпме көч кирәк, әйтегез әле тизрәк? Ялганлыйсың, йөзеңне дә чытмыйсың, шушы каләр бөҗәкләр алдында берәүгә дә зарар китермибез, дисең.

Яфрак көясе елмаеп кына күбәләкнең сүзләрен тыңлап торды. Сүз ахырында һөҗүмен күбәләкләргә таба да борды:

— Син, күбәләк-түгәрәк, үз туганыңа каршы чыгасың, әллә шуның белән яхшы ат казанасыңмы? Сез бит күбәләк булганчы башта үзегез дә көя булгансыз, яфрак ашап симереп «курчак»ка әйләнәсез, аннан гына күбәләк төсенә керәсез, хәзер чәчәк иснәп йөргәч кенә бик акыллы баш булгансыз, үткәндәге эшләрегезне бөтенләй оныткансыз.

Күбәләкнең авызын каплагач, көя агач башыннан җиргә төште. Кунакларның аны юньләп тыңламауларын: «Бу ярык барабан сүзен кайчан бетерер икән?»—дип торганнарын сизенде. Аның әле байтак сөйлисе сүзләре калды, ул тут агачы яфрагын ашап ефәк бирүче көяләргә бер дә тукталмады. Аларның файдалы хезмәтләрен, кешегә ярдәм итүләрен, ефәк бирүләрен әйтмәде. Яңгырның көяләрне агач ботагыннан юып төшерүләрен, кошларның аларны чүпләп бетерүләрен, кырмыскаларның җәзалап үтерүләрен сөйләмәде, хуҗаларның кәефен җибәрергә теләмәде. Чәчәктән чәчәккә сикергәләп, очып килеп җитте күбәләк. Ул чәчәкләрнең хуш исле булуларын, күбәләк-

ләрнең чәчәк сөюләрен, көне буе туктамый очып йөрүләрен, табигатьне матур итеп бизәүләрен сөйләде.

Тукранбаш чәчәгендә нидер тавышланды. Кунаклар шунда борылдылар һәм чәчәктән бал суырып ятучы Нечкәбилне күрделәр. Ул кунакларның аңа таба борылуларын гына көтте, вакыттан файдаланып сөйләп тә китте:

— Чәчәкләрдәге бал, без булмасак, әрәм булыр иде, без булмасак, уңыш та түбән булыр иде. Чәчәк эченә яшеренгән балны суыруның никадәр көч сораганын, балавыз сугуга күпме көч түгелгәнен беләсез, әгәр шуларны сез үзегез эшләсәгез, бал кортлары иң көчле бөҗәкләр, дияр идегез,— диде ул. Ләкин кунаклар юньләп тыңламагач, аңа дошманнарына да тукталып калырга мөмкинлек булмады.

Ерак та түгел, корган яфраклар кыштырдады, чыбык-чабыклар шартлады, җирне тетрәтеп кемдер атлады. Кайсыдыр бөҗәк:— Кеше килә!— дип кычкырды. Кунаклар сафында буталыш башланды: чикерткә бер читкә сикерде, суалчан җиргә сеңде, бал корты чәчәккә яшеренде, күбәләк һавага күтәрелде, яфрак көясе яфракка сыенды, чебеннең коты очты, кая да кузгала алмады, ә үрмәкүч бу хәлдән нык файдаланды.

Урмандагы барлык агачларның, андагы усал ерткычларның хуҗасы атлады. Ерткычларның көчлесе арслан да аңа баш иде, кошларның иң үткене кара кош та аны сәламләп калды, бөҗәкләр дә аны олыладылар — бары да үзләренчә сайрарга тотындылар. Ташкын елгаларны авызлыклаучы, киң болыннарны, куе урманнарны үз эшенә файдаланучы, бөтен табигатьне үзенә баш идерүче кеше һаман атлый бирде.

Күп тә үтмәде, урманны яңгыратып пычкы чыжылдады, җирне тетрәтеп, зур агач ауды...

Шулай итеп чебен белән үрмәкүч сөйли алмый калдылар. Алар качучы кунаклар белән бергә кузгалдылар. Эх, әрәм калды бит, әрәм калды. Үрмәкүч үзенең сүзләрен күңеленнән ятлаган иде, кунакка барыр алдыннан гы-

на көзге алдына басып, берничә тапкыр кабатлаган да иде. Эх, сөйләргә булмады бит, сөйләргә булмады. Әгәр ул сөйләгән булса, үрмәкүчтән дә көчле бөҗәк юк икәнне кунаклар белеп киткән булырлар иде һәм үрмәкүчләрне мәңге олыларлар иде.

Чебен дә сөйли алмый калуына бик көрсенде, ашыгыч булса да, баягы сүзчән кырмысканы күрде, кичә әгәр яңадан җыйналса, беренче итеп аңа сүз бирүен үтенде.

Урман тынгач, бөҗәкләр яңадан урыннарыннан тордылар, барысы да бергә җыйналдылар, күп булдылар. Чебен белән үрмәкүч кенә күренмәде, кунакларның кайберләре ишеттеләр: кайдадыр нидер безелдәде. Эзләргә тотынгач таптылар, күреп шаккаттылар. Кунаклар качып торган арада, үрмәкүч пәрәвезен сузган, чебенне шунда эләктереп алган һәм канын эчәргә тотынган. Теге, мескен, безелдәп ярдәм сораган, берәү дә ишетүче булмаган. Бу эше өчен үрмәкүчне бик каты тиргәделәр, чебенне пәрәвез богаулардан азат иттеләр. Чебен Шакшиевның шакшылык дусты икәнлеген күпләр беләләр, үрмәкүчнең дә кемлеген инде сизенәләр. Пәрәвездән тукып оялар коручы, кайда өй җыештырылмый — шуның почмакларында торучы...

Барлык кунаклар инде зур дәрт белән соңгы бөҗәкне тыңларга җыйналалар. «Батырларның-батыры, көчлеләрнең-көчлесе, билгеле, алар!» — диеп үзара пышылдадылар. Әрекмән яфрагына таба канатлы кырмыска якыная, бары да йотылып карыйлар аңа. Култыгына иләмсез зур портфель кыстырган, портфеленә сыймаган кәгазьләрне зур башлы сакчы кырмыскага тоттырган, баягы сүзчән кырмыска тагы сөйләп китте:

— Хәзер кырмыскалар иленең аналарыннан берсе сөйләячәк, бөтен сөйләгән сүзләргә бәя бирәчәк һәм арасында кемнең көчле һәм иң файдалы икәнен күрсәтәчәк, — диде.

Әгәр кырмыскалар анасы сөйләгән булса иде, кунак-

лар аны тыңлый-тыңлый арырлар, я татлы йокыга талырлар, я кичәне ташлап таралырлар иде. Әгәр сөйләнгән булса, ул речь бик озын иде. Анда кырмыскаларның үзе кадәр әйберне күтәрә алуы да, ата кырмыскаларның зур походларга баруы да, канлы сугышларда катнашучылар да, урман корткычларына каршы көрәшүләре дә, шуның белән үсемлекләргә ярдәм итүләре дә — бар да бар иде.

Кызганычка каршы, ул речь сөйләнмәде. Ана кырмыска, авызын ачкан килеш, катып калды, колакларны ярырлык булып урман эче тетрәп калды. Агачлар шаулашырга, үләннәр үкерешергә тотындылар. Урман эчен караңгылык басты. Бөҗәкләр булачак хәлне алдан ук сизенделәр. Шуңа күрә кайсы кая посарга дип йөгерделәр. Караңгы урманны ялтыратып яшен уйнады. Һәм кинәт кенә көчле яңгыр да коя башлады. Шуның аркасында «Кем көчле?» дигән бәхәс бетмичә калды. Сез, бәлкем, аны үзегез бетерерсез, кем көчле икәнен әйтеп бирерсез!

КОЙРЫКЛАР

(Африка әкияте)

Борын-борын заманда юаш хайваннарның, ерткыч җанварларның койрыклары бөтенләй булмаган. Кешнәүче ат та, мөгрәүче сыер да койрыгы белән чебен кумаган. Шаян тиен дә, чикләвекләр ашап, ботактан ботакка сикереп уйнамаган.

Хәйләкәррәк ерткычлар җыелганнар барысы да бергә, койрык алып калу турында киңәшергә. Ак түшле саесканнарны чакырганнар, аларга да зур йомыш тапшырганнар.

— Сез, ак түшле саесканнар, туры юлдан адашканнар, очыгыз да китегез, еракларга җитегез: биек-биек тауларга, шаулап торган урманнарга, ямь-яшел болыннарга, җырлап аккан суларга безнең сүзне илтегез,— дигәннәр. — Юаш хайваннарны, ерткыч җанварларны чакырыгыз: үткәргәч караңгы төнне, менә фәлән көнне, томан беткәч тә, кояш күтәрелгәч тә, карт имән янында өләшәчәкләр диегез койрык, менә сезгә шул безнең боерык,— дигәннәр.

Саесканнар төрлесе-төрле якка карап очканнар. Үзләре белән зур-зур быргыларны кычкыртып барганнар:

— Әй, сез, куе урманнарда, киң кырларда, яшел болыннарда, диңгез-океаннарда яшәүче ерткычлар,— дигәннәр алар. — Томан беткәч тә, кояш күтәрелгәч тә, бөтене-

гез дә карт имән янына барыгыз, койрык өләшәчәкләр, килеп алыгыз,— дигәннәр.

Усал ерткычлар, бишәү-унау, яудырганнар берьюлы сорау:

— Бу нинди боерык? Нәрсә соң ул койрык? Ул нигә кирәк? Әйтегез әле тизрәк?— дигәннәр.

Хәйләкәр төлке (серне белгәч, аңа көлке):

— Өләшәләр икән — барып алыйк, яраклылармы икән — үлчәп карыйк, нәрсәгә кирәк икәнен соңыннан белербез, бәлки, күбебез сөенербез,— дигән.

Үткәргәч караңгы төнне, шул билгеләнгән беркөнне ерткычлар койрык алырга карт имән янына барырга юлга чыкканнар, кайсы үрмәләгән, кайсы йөгергән, кайсы чапкан.

Кыр куяны үзенең тунын чистарткан, тәпиләре белән битен юган, ул да карт имән янына барырга җыенган. Чыгам дип, оясының ишеген ачкан, ләкин көчле яуган яңгырга чыдамаган, кире оясына кереп качкан.

Оясында озак утырмаган зур колак куян, дөп тә дөп басып килгән аяк тавышын ишеткән, карамыйча яңгырга, йөгереп тышка чыккан. Агач куышына кереп утырган да ерактан килүчене карарга тотынган.

Агачлар куркышып чатнаганнар. Үләннәр үкерешеп шаулаганнар.

«Кулына тотып таяк, киләдер теге кәкре аяк»,— дип уйлаган куян: чыннан да шулай булып чыккан.

Куян килүчегә сүз кушкан:

— Аю бабай, башкалардан артка калмыйсыңдыр, үзеңә койрык сайлыйсыңдыр, шунда миңа да, нинди генә булса да, бер койрык алып кайта алмассыңмы икән?— дигән.

— Әгәр дә онытмасам, алып кайтырмын, авыр эшмени ул,— дигән аю.

— Ярарын ярар, шулай да аңа ышанып булмый,— дигән куян. — Аю бабай инде картайган, зиһене дә таралган. Онытыр вәгъдәсен, аннан табар хәйләсен, тагы кем-

нән дә булса башка берәүдән үтенергә кирәк,— дигән куян.

Тагы тып-тып бер тавыш килә, вак чыбыкларны чыжылдатып, кем соң ул йөгерә? Ә, бүре килә.

— Бүре бабай, карт имән янына барасыңдыр, үзеңә койрык аласыңдыр, шунда миңа да, нинди дә булса берәр койрык алып кайта алмассыңмы икән?— ди куян.

— Барысына да җитәрлек булса, берәрсе артып та калса, алып кайтырмын,— дип, бүре үтеп китә.

— Юкка әрәм иттем моңа сүз, бүре бит ул туймас күз, сайлап бетерерләр, берәү дә калмас, артып калса да, ул алмас, миңа бирмәс, бозар вәгъдәсен, табар хәйләсен. Кемне дә булса тугрыракны, бу эш өчен хубракны табарга кирәк,— ди куян.

Тагы кемдер дөп тә дөп итеп басып килә. Үлән әз генә селкенә, төлке йөгереп килә.

— Бу эш түгел көлке, апакаем төлке, үзем бара алмадым, ахры инде койрыксыз калдым. Карт имәнгә барасыңдыр, үзеңә койрык аласыңдыр. Сиңа бу зур үтенечем, боерык дип уйлама, алып кайтмассыңмы икән миңа бер койрык.

— Ярый, ярый, һич хафаланма, берәүгә дә зарланма. Куян дусым сорады диярмен, койрыкның менә дигәнен алып кайтып бүләк итәрмен. Тупың белән бертөсле булыр, әллә кайдан ук күренеп торыр.

Төлке барысыннан да соң юлга чыкса да, куян янында шактый тукталып торса да, иң туры юллар табып, бар көченә чабып, карт имән янына иң алдан барып җитә.

Койрыклар белән карт имәннең ботаклары тулган, һәр ботак саен бер койрык асылынган: йонлач озыннары да, йонсыз ялангачлары да, җеп шикеллеләре дә, алтын йон белән капланганнары да, кара һәм аклары да, кәкреләре дә, турылары да,— бар да бар. Җыелган ерткычлар аларны күреп хәйранга калалар, башларын кыңгыр салалар, көтмичә бернинди боерыкны, беренче булып төлке сайлый койрыкны:

— Миңа менә шушысын, мамыклысын, йонлысын,—ди.

Башкалар йоклап кала, ә ул үзенә менә дигән бер койрыкны сайлап ала. Төлке әйләнә дә тулгана, койрыгы да бергә болгана.

Стакан тояклары белән тыпыр-тыпыр басып, үзен үзе белештерми ярсып, ат килеп тә җитә, себерке шикелле кыл койрыкны алып та китә. Үзе айкала да чайкала, кыл койрыгы белән мактана:

— Борыныма кадәр барып җитә, димәк, чебеннәргә моннан соң көн бетә,— ди.

Сыерның да койрыгы яхшы, бүренең дә начар түгел. Тиен дә койрыктан унган, сикерсә, пружинадай булган, йокласа — юрган. Фил һаман бер урында тапталып йөргән, күпләрнең тәпиләрен изгән. Ул селкенгәнче, килеп җиткәнче, иң кыска койрыклар гына калган булган. Фил үз язмышына үзе үпкәләгән, борынын түбән салган. Шуннан бирле аның борыны салынкы булып калган.

Аю юлда умарталыкка очраган, туйганчы бал ашаган, шуңа күрә койрык алырга да соңга калган, шулай да бернәрсә тапкан, тире кисәген койрык итеп таккан.

Койрык өләшеп бетергәч, таралырга вакыт җиткәч:

— Барыгыз да койрыклымы инде?— дип бер-берсеннән сорашалар ерткычлар.

— Юк әле, юк, туктап торыгыз, мин алмый калдым,— дип мыгырдый дуңгыз.

— Сазда аунаганнар, кояшта кызынганнар, пычрак ерганнар, шуңа күрә койрык алырга да соңга калганнар.

Барып җиткәч сорасалар, күз төшереп карасалар, бары тик бармак буйлыгы койрыклар гына калган булган. Дуңгызның балалары уникесе уникe яктан чинарга тотынганнар:

— Кирәкми, андый койрыкны алмыйбыз, хурланмыйча аны койрык итеп тагып та йөрмибез,— дигәннәр. Ләкин сайларлык башка койрык булмаган, ана дуңгыз бик аптыраган, шул койрыкны тагып алган да кәкрәйтеп салган.

Шул көннән алып барлык дуңгызларның да койрыклары ыргакланып калган.

Кыр куяны койрык алып кайтучыларны көткән, оясында ятып та аптырап беткән, ахыр чиктә түзмәгән, кайсын булса да берсен очратырмын диеп, юлга чыгып киткән.

Әнә еракта алпан-тилпән кайтучы аю күренгән. Куян шатланып, әйтерсең канатланып, аюга каршы йөгергән.

— Аю бабай, онытмадыңмы? Минә дигәнен алып кайттыңмы?— дигән.

— Кит әле моннан, ялкау куян! Үзең бармагач, армагач-талмагач, кыршылмагач, сугышмагач, тик утырып кына койрыклы булып буламы соң, юләр, мин менә йөгерә-йөгерә барып та, үлә язганчы арып та, менә шушындый кыска койрык кына эләктерә алдым,— дигән аю куянга.

Аю мескен куянны тиргәгән дә киткән, ә куян башкаларны көткән.

Күп тә үтмәгән, бүре күренгән, куян аңа каршы йөгергән.

— Бүре абый, бүре абый, миңа дигән, минә дигән койрыкны бир, абый, — дигән.

— Кая әле сиңа дигән койрык, үземә дә көчкә генә берне эләктердем,— дигән бүре.

Бүре шулай дигән дә киткән, ә куян төлкене өзелеп көткән.

«Төлке апакай, багалмакай, ул гына алдамаса алдамас, әгәр койрык алып кайтса, китереп алдыма салса, бүләк итәм бер каз»,— дип уйлаган куян. Тау битенә ныклабрак күз салса, төлке килә ләбаса. Куян, чакырганны көтмәгән-нитмәгән, аның каршысына барып баскан:

— Апакаем, багалмакаем, миңа дигән койрыкны биреп калдыр, мине шатландыр,— дигән.

— Син генә идең минем башымда, әллә нинди җайсызлыклар чыкты каршыма. Син менә күз сал әле, кызыгып кал әле: йомшак кына, мамык кына, үземә менә дигәнне эләктердем, хәер, шуның аркасында күп мал бетердем,— дигән төлке.

Шул сүзләрне әйтеп, күз уйнатып, куян борыны янында койрыгын болгап төлке көлеп торган.

Куян койрык көтеп бик зарыккан булган. Мескеннең күңеле тулган. «Миңа кирәк булса, туганнар, барысы да мине онытканнар»,— дип елап ук җибәргән.

Күңелсезләнеп утырганда, тирә-ягын күз яше белән тутырганда, ишеткән куян: «Вау да вау, мырау да мырау». Борылып карый, карый да: «Менә монысы ярый». Эт белән мәче дау килеп сугышалар икән.

Эт: «Минем койрык иң яхшы!»— дигән. Мәче аркылы төшкән: «Минеке ише дөньяда да юк!»— дигән. Тартышканнар да тартышканнар. Әүмәкләнә торгач, сугышның очы чыга... Мәченең койрык очы өзелеп чыга. Мескенем куркуыннан агач башына ук менеп китә. Өзелгән койрыкны җил, тәгәрәтеп, куян оясына илтә. Куян аны үзенә койрык итә. Шул көннән башлап мәче белән эт арасындагы бу ызгыш мәңгелеккә китә.

Әкият тә шуның белән бетә.

ЭТ ҮЗЕНӘ НИЧЕК ХУҖА ЭЗЛӘГӘН

(Мингрел халык әкияте)

Элек заманда этнең хуҗасы булмаган, берәү дә аның тормышы өчен кайгырмаган. Ул ялгызы гына яшәгән, берәү дә аңа: «Минем этем син!»— дип дәшмәгән. Торабара эт болай яшәүнең җайсыз икәнлегенә төшенгән, үзүзенә: «Дөньяда иң көчле берәүгә хезмәт итәргә кирәк!»— дигән. Үзенә хуҗа эзләргә керешкән, шул теләк белән юлга чыгып киткән.

Ай киткән, ел киткән, бара-бара бер куе урманга барып җиткән. Урманда аңа көрән бүре очраган. Үзен берәүгә дә җәберләргә ирек бирмәүче усал бүре эттән сораган:

— Кая барасың болай?— дигән.

— Менә, үземә хуҗа эзлим, рөхсәт итсәң, синең хезмәтчең булыйм,— дигән эт.

Бүре риза булган. Бергәләп алар алга таба киткәннәр. Бара торгач, бүре кинәт туктаган, тын калган, борынын күтәреп иснәнергә тотынган. Йонлач койрыгын аяклары арасына кыстырган да аланлыкны читләтеп кенә качарга тотынган.

— Хуҗам, нәрсәдән болай курыктың син?— дип сораган эт.

— Аланлык уртасында кемнеңдер бал ашап утырганын әллә күрмисеңме? Аның кем икәнен дә әллә белмисең-

ме? Аю бабаң тотса, икебезне дә хур итсә! Әйдә, сызыйк моннан, ул безнең өчен бик хәтәр,— дигән бүре.

— Ә, алай икән, аю синнән көчлерәк икән. Алай булгач, сау бул, усал бүре, син миңа хуҗа түгел, мин сиңа хезмәтче түгел,— дигән дә эт үз юлына киткән, аларның дуслыклары шуның белән беткән.

Аю янына барган да эт үзен хезмәтче итеп алуын үтенгән, аю күнгән:

— Ярый, мин синең хуҗаң булырмын, син минем хезмәтчем булырсың!— дигән,— тик хәзер минем бик ашыйсым килә, әйдә, икәүләп умарталыкка барыйк, рәхәтләнеп бер туйганчы бал ашыйк!— дигән, этне үзе белән ияртеп киткән.

Алар бара-бара бер көтүгә очраганнар, ләкин ниндидер тавыш ишеткәннәр дә туктаганнар, шул тавышны тыңлап тыңларга керешкәннәр, көтү тузгыган: сыерлар мөгриләр, атлар кешниләр, барысы да койрыкларын чәнчеп чабып йөриләр. Ләкин аю агач артына гына посып караган да кире урманга таба борылган, ә эткә бу хәл гаҗәбрәк булып тоелган, ул түзмәгән, карт аюдан сорап куйган:

— Хуҗам, нәрсәдән курыктың син?— дигән.

— Күрмисеңмени, анда арслан хуҗалык итә, ишетмисеңмени, ничек бөтен дөньяны дер селкетә,— дигән аю.

— Ә кем соң ул арслан?— дип сораган эт.

— Аннан да көчле, аннан да куркынычлы ерткыч бөтен дөньяда да юк,— дигән аю.

— Алайса сау бул, син миңа хуҗа түгел, мин сиңа хезмәтче түгел,— дигән дә эт аюны ташлап киткән, аларның дуслыклары шуның белән беткән. Эт арслан янына килгән, аңа үзенең йомышын сөйләп биргән. Арслан да аны якты чырай белән кабул иткән, этнең әйткәне белән килешкән.

Эт арсланга күп еллар буе хезмәт иткән. Аңардан көчле берәүне дә күрмәгән, арслан этне берәүгә дә рәнҗетергә ирек бирмәгән. Бер дә беркөнне алар бергәләп

ауга чыкканнар. Күп көч куймыйча, бик шәпләп туйганнар. Кайтырга чыккач кына арслан кинәт туктаган, коточкыч көчле итеп үкереп җибәргән: таулар дер селкенеп киткәннәр, һавадагы кошлар җиргә төшкәннәр, башка ерткычлар кайсы кая качып беткәннәр. Арслан тырнагы белән җирне тырный-тырный арып беткән, аннан кире борылып киткән.

— Хуҗам, нәрсәдән болай курыктың?— дигән эт.

— Әнә, күрмисеңмени, зур адымнар белән атлап кеше килә. Аңардан да көчле дөньяда берәү дә юк, безгә тизрәк моннан китәргә кирәк,— дигән арслан.

— Ә алай икән, синнән дә көчлеләр бар икән, мин шуны белми йөрим икән. Алайса, сау бул, бүгеннән син миңа хуҗа түгел, мин сиңа хезмәтче түгел,— дигән дә эт киткән, алар арасында дуслык менә шулай беткән.

Шул көннән башлап, эт кешенең хезмәтчесе булып киткән, ул аңа инде күптән, бик күптән бирле туры хезмәт иткән, дөньяда кешедән дә көчлерәкне әле дә булса күргәне юк икән.

ИЛ ГИЗҮЧЕЛӘР БЕЛӘН ХӘЙЛӘ СӨЮЧЕЛӘР

(Украин язучысы Н. Забила экияте)

Әтәч белән тавык күптәннән гомер кичерделәр, бик тату яшәделәр, һичбер вакытта да бер-берсенә каршы сүз әйтешмәделәр. Көннәре дә, төннәре дә матур гына акты, таң алдыннан әтәч канатларын какты, шыңгырдатып кычкырырга яратты. Ашау-эчүләре дә мул иде, һәрвакыт алларыннан калды.

Тавык та бик уңган иде, йомырканы күп салды.

Шулай да алар гел бертөсле тормыштан туйдылар, дөнья күрергә, ил гизәргә дип юлга чыктылар.

Бара-бара яшел урманга барып җиттеләр, бернигә карамый, батырланып, куе урман эченә кереп тә киттеләр. Әнә ничек, җилгә баш бөгеп, ботаклар селкенәләр, алар арасыннан кызыл мәрҗәннәр төсле булып җимешләр күренәләр.

Тавык, туктатып кадерле әтәчен, авыз итмәкче була урман күчтәнәчен:

— Әтәчкәем, бәгырькәем, бер ботак сындыр, мине куандыр, яшел яфрак та булсын, кызыл җимешләре дә булсын...

Тавыкның теләген үтәмичә ярамый, әтәч, бернигә карамый, ботак сындырырга тотына. Шул вакыт яфрак астындагы оясыннан куян чыга да әтәч каршына килеп утыра:

— Кем ул, кем ул минем урманыма баш булмакчы

була, сорамый-нитми торып, агачларымны сындыра, бик кирәк икән, рөхсәт сора,— ди.

Әтәч курка башлый, тавыкка әйтеп ташлый:

— Сызыйк без моннан, сындырырбыз соңыннан. Алгарак китсәк, юлыбыз уңар, бу нәрсәнең дә күңеле булыр. Монда дөньяда тиңе булмаган ерткычлар яшиләр икән, киемнәре соры, колаклары ярты метр икән, болар, мөгаен, бик усал ерткычлардыр, безнең өчен куркынычлардыр, кош ите ашаучылардыр.

Әтәч белән тавык бик тиз генә киңәштеләр дә яшел урман эченнән алга таба киттеләр.

Җил искән саен ботаклар селкенәләр, ботаклар селкенгәч, яшел яфраклар тирбәләләр, алар арасындагы тәмле чикләвекләр күренәләр.

Тавык бик талчыккан, җитмәсә, яхшы ук ачыккан. Ул тагы әтәчне йөдәтә, ашыйсы килүе турында әйтә:

— Әтәчкәем, бәгырькәем... Кыткы-так, кыткы-так, сындырып бирче бер ботак, яшел яфраклысын, чикләвеклесен, куесын,— ди.

Әтәч: «Сындырам!»— дип, ботакка килеп кенә тотына, ныклабрак караса, ботакта зур койрыклы тиен чикләвек ашап утыра. Һәм ул усал тавыш белән кычкырышырга да тотына:

— Әй, кем ул, кем урманда йөри, кем ул минем чикләвек агачымны сындырырга тели?— ди.

Әтәч тагын каушый, тавыкка әйтеп ташлый:

— Тизрәк сызыйк без моннан, сындырырбыз соңыннан, күрәсеңме, нинди усал ерткычлар бар, безгә ахры бу зур урман булыр тар. Колагын күрәсеңме, утыртып тора, йонлач койрыгын селеккәләп куя. Кара әле, кара, ничек утыра, хәтәр, шәт хәзер үк ул безгә һөҗүм дә итәр.

Әтәч белән тавык бик тиз генә киңәш итешәләр дә алга таба атлап китәләр.

Җил каты итеп исә, кай ара ботаклар белән шаяра. Агач төбендә үләннәр котырып үскәннәр, алмагачтагы әче

алмалар кызарып пешкәннәр. Тавык инде түзә алмый, әтәчтән тагы ялынып сорый:

— Әтәчкәем, бәгырькәем, ничек тә булса кара, икеәч кенә алмалы нәни ботак булса да ярар.

Әтәч батырланып сындырырга тотына, алмалы ботак шартлап сына. Шул вакыт оясыннан төлке чыга. Һәм килеп баса әтәч каршына. Көлтәдәй койрыгын болгап тора, елмайган килеш, татлы сүзләрен яудырырга тотына.

— Хуш килдегез, рәхим итегез, өемә керегез, түремә узыгыз, кунагым булырсыз. Аякларыгыз арыгандыр, безнең урман зур бит, сусагансыздыр, талчыккансыздыр, көн бик кызу бит. Мин сезне күптәннән көттем, сезгә күчтәнәчләр хәзерләгәндәй иттем. Сый җитештердем, бик күп пешердем. Урманнан иң кызыл алмалар сайладым, сезнең өчен генә саргаеп өлгергән чикләвекләр җыя алдым, бәхетегез шул икән, ризыгыгыз мул икән.

Әтәч белән тавык мондый җылы сүзләргә бик шатланалар, төлке өенә кереп ял итәргә булалар.

— Кара әле, монда ерткычлар нинди яхшылар икән,— диләр алар.

Хәйләкәр төлкенең эшләре бик шәп көйләнә, шатлыгыннан ул үз-үзенә сөйләнә:

— Миңа дигән тәмле ашлар... Менә юләр башлар, үзләре килеп керделәр,— ди.

Төлке кунакларны өенә алып керә, аларга тәмле-тәмле күчтәнәчләр бирә, ә үзе: «Мин күршегә генә кереп чыгам»,— дип, күршесе бүре янына йөгерә.

Бүрене кунакка чакырмакчы, тавык шулпасы белән сыйламакчы була.

Тавык белән әтәч бик тәмләп әчәләр, ашыйлар, тамаклары туйгач, кәефләнә дә башлыйлар. Әтәч бигрәк тә кыза, хәтта җыр да суза. Төлке өе яныннан узучы шәфкатьле куян моны ишетә һәм ярдәм итмәкче була ничек тә, якын килеп ишеккә, сүз башлый куян:

— Син, әтәч әфәнде, артыграк батырланасың, берни белмичә кыланасың, төлкенең кем икәнлеген соңгарак бе-

ЯЛКАУЛЫК — ХУРЛЫК, ТЫРЫШЛЫК — ЗУРЛЫК

Чәчәкләр башлыгы бик зур ярыш үткәрергә булган. Шул турыда төрле якка хәбәр дә салган:

— Кем дә кем бал салырга яхшы савыт хәзерләсә, ул савытта бал бер дә бозылмаса, әчемәсә, барлык чәчәктәге балны шуңа бирәчәкмен,— дигән.

Бөҗәкләр көнне-төнне белмәгәннәр. Бар да тырышып савыт эшләгәннәр.

Күп тә үтмәгән, бөҗәкләр төрле яклап очып килгәннәр. Бар да үзләре эшләгән савытларны чәчәк башлыгына китергәннәр.

— Менә дигән савыт, балны кара салып,— дигәннәр.

Чәчәкләр башлыгы барысын да борып җибәргән:

— Ашыккансыз, ашыккансыз, бик начар ясагансыз. Мондый савытлар миңа кирәкми. Шуңа күрә бал да сезгә эләкми,— дигән.

Шөпшә белән бал корты иң соңгылар булып эшкә керешкәннәр, беренчелекне алырга өмет иткәннәр.

Бал корты көне буе бертуктамый эшли дә эшли икән: ерак-ерак җирләргә очып бара, аллы-гөлле чәчәкләрдән бал суырып ала, аны алып кайтып үзе хәзерләгән матур күзәнәкләргә сала икән.

Шөпшә дә чәчәкләрдән бал җыйган. Ләкин ул бик-бик ялкау булган. Иртән әзрәк кенә эшли икән дә, кояш кыздыра башлагач, оясына кереп йоклый икән.

Көннәрнең берендә шөпшә бал кортына очраган һәм аны өзелеп-өзелеп кунакка чакырган:

— Кил әле, кил, мин әзерләгән бал савытын да күреп китәрсең, кайбер җирләрен төзәткәлисе бардыр, бераз ярдәм дә итәрсең,— дигән.

— Ярый,— дигән бал корты,— барсам барырмын, ләкин бүген миңа кереп чыгыйк, бераз күңел ачып утырыйк,— дип, шөпшәне үз өенә алып киткән һәм бик шәпләп кунак иткән.

Шөпшә бал корты эшләгән савытны кат-кат караган һәм аны бик-бик мактаган:

— Осталарның да остасы икәнсең, мондый шәп савытны ничек ясый алдың?— дигән.

— Серемне әйтсәм әйтим, дус кеше бит, сиңа белгертим инде,— дигән бал корты,— көне-төне тырышып эшләгәч, бүгенгә эш торып торсын, ял итим әле димәгәч, бар авырлыкларны да җиңеп була икән,— дигән.

Көннәр үткән дә үткән. Бал кортының шөпшәгә кунакка барыр вакыты да килеп җиткән.

Эштән кайтышлый бал корты шөпшәнең өенә кергән, дустының хәлен белгән:

— Исәнме, шөпшә дус, эштән соң ятып, бераз ял итәсеңме? Әллә юкса авырып торасыңмы? Бал савытларын илтер көн дә җитә бит, бик тырышып әзерләпик,— дигән.

Шөпшә чалкан яткан, күзләрен акайткан. Аякларын югары сузган, мыекларын түбән салындырган. Ул:

— Сәламеңне дә алыр хәлем юк, дустым,— ди икән. Кунакны сыйларлык түгел, туйганчы үзе ашарлык та балы юк икән. Ярты көн бал җыйса, шунда ук аны ашап бетерә дә барган. Башын шундый ялкаулыкка салган. Шуңа күрә бал савытын да эшли алмаган.

Ярыш көне килеп җиткән.

Бал корты балавыздан эшләнгән матур күзәнәкле бал савытын күтәреп очып киткән. Шөпшә дә үзенең аппанмоннан эшләнгән кәрәзен алып килгән.

Чәчәкләр башлыгы кәрәзләргә бал салып караган. Шөпшә кәрәзендә бал тормаган, ә бал кортының кәрәзе акмаган.

— Тырышканнар күп көч куйганнар, менә дигән кәрәз эшләп чыгарганнар. Шуңа күрә теләсә нинди чәчәктән, теләсә никадәр бал җыярга бал кортларына рөхсәт бирәм,— дигән чәчәкләр башлыгы.

Шул көннән башлап бал кортлары чәчәкләрдән бал ташый башлаганнар, ә шөпшәләр ялкаулыклары аркасында хурлыкка калганнар.

ПЕСИЛӘР ҺӘМ КҮСЕЛӘР

Үзе кечкенә генә, шаян гына, күрер күзгә матур, карап торырга батыр бер песи баласы булган. Ул әнисе тирәсендә сырпалана, иркәләнә, ә кичләрен аның куенына кереп йоклый икән.

Әнисе ауга киткәндә:

— Матурым-матурым, гайрәтле батырым, ялгызың гына калырга курыкмыйсыңмы?— дип сорый икән.

Ә теге:

— Юк, энекәем, юк! Дөньяда берәүдән дә курыкмыйм, бик тыныч йоклыйм,— ди икән.

Көннәрнең берендә песинең анасы ауга чыгып киткән. Песи баласы аны көтә-көтә арып беткән. Йокысы килгәч, ул йомшак урынына кереп йокларга гына җыенган икән, шул вакыт нидер кыштырдый башлаган. Бу кыштырдау песи баласының йокысын качырган.

Идәндә нәни-нәни тычкан балалары йөргерешеп йөргәннәр; «Әләли-әләли, безне тота алмыйсың, көне-төне йоклыйсың да йоклыйсың»,— дип песи баласыннан көлгәннәр. Ә песи баласы яткан урыныннан идәнгә сикереп төшүгә, кайсы кая төшеп өлгерәләр икән.

Ул тәмам аптырап беткән, аларның берсен дә тота алмаган, шуңа күрә дә бик хурланган. «Әни генә кайтсын, бөтенегезне тоттырып бетертәм»,— ди икән.

Әнисе кайткач, ул бөтен хәлне сөйләп биргән. Әнисе аңа бик файдалы киңәшләр, хәйләле юллар өйрәткән дә икенче көнне тагын да ауга киткән.

Тычкан балалары идән астыннан тагын чыкканнар, йөгерешеп йөреп, песи баласын котыртканнар. Ул бу юлы аларны бик кызык иткән: сикереп төшкән дә почмактагы тишекне бикләп куйган. Тегеләр кая качарга урын тапмаганнар, тәмам аптыраганнар, песи баласы аларның берсен эләктереп тә алган, буып та салган. Өченче көнне дә әнисе ауга киткән. Песи баласы аны көтә-көтә арып беткән. Бу юлы тычканнар да чыгып шаярмаганнар, каядыр югалганнар.

Менә кинәт нидер бик каты кыштырдаган. Песи баласы: «Әни кайтты, ахры»,— дип уйлаган. Ни күзе белән күрсен: идәндә зур-зур күселәр йөгерешеп йөриләр икән.

Песи баласы алардан да куркып тормаган, сикереп төшкән дә күселәрнең юлын бикләргә теләгән. Мескенем, әз генә үзе ул тишеккә егылып төшмәгән: тишек шундый зур икән.

Күселәр аны куа-куа алҗытып бетергәннәр, куып тотканнар, җәфаларга тотынганнар. Ул көч-хәл белән качып котылган.

Әнисе кайткач, барысын да баштанаяк сөйләп биргән. «Үтерә яздылар бит, әни!» — дигән.

— Матурым-матурым, курыкмас батырым, дошманнарның төрлесе була, төрлечә һөҗүм кыла. Шуңа күрә аларга каршы да төрле юллар белән көрәшергә кирәк,— дигән.

Нәни песи хәзер инде барлык дошманнарны да танырга өйрәнгән: аларны көч белән, тапкырлык белән, кыюлык һәм батырлык белән җиңә икән.

МАКТАНЧЫК ЧЫПЧЫК БЕЛӘН ТЫЙНАК СЫЕРЧЫК

Тәрәзәгә каршы бер озын колга сузылган, ул колгага нарат такталардан эшләнгән оя куелган. Әле кичә генә балалар ул ояны ашыга-ашыга эшләп бетерделәр, ә бүген инде анда яз кунаклары — сыерчыклар килделәр. Оянын эчен-тышын җентекләп карадылар, бик ошаттылар. Аны ясаучыларга рәхмәт укыдылар, бик матур итеп сайрап куйдылар.

Сыерчык оясына каршы тәрәзә башында бер карт чыпчык утыра, ничә еллардан бирле инде ул шунда тора. Салам-соламнарны, йон-мамыкларны җыеп оя ясаган, салкыннар килгәч тә җылы якларга очмаган, шул ояда кышлаган ул чыпчык.

Яңа кунакларны чыпчык, ничектер, бик кәефсез каршы алды, «күңелсез иде, күршеләр булды»,— дип үзе эченнән бераз шатланды. «Сайраулары белән колакны тондырып бетерерләр, рәхәтләнеп йокларга да ирек бирмәсләр, туктагыз дисәң дә туктамаслар, күрше димәсләр»,— дип уйланды.

Чыннан да шулай булып чыкты. Сыерчыклар монда чыпчык абзый яши дип тормадылар. Көне буе өзелеп-өзелеп сайрадылар. Чыпчыкның моңа бик ачуы килде, ямьсез тавыш белән күршеләренә җикеренде:

— Бөтен тынычлыгымны боздыгыз, сайраган булып колагымны тондырдыгыз. Ичмасам, чыпчыклар төсле сайрый алсагыз икән, алардан уздырсагыз икән... Безнең

жырны бар тавыклар да хәйран калып тыңлый, безнең хуҗа да бик зурлый...

Сыерчыклар мактанчыкның бу сүзләрен ишетеп аптырап калдылар, «бу әллә юләрме икән?» — дип уйлап алдылар.

Җае килгән саен чыпчык мактана бирде, әй мактады чыпчыкларны, әй мактады — күкләргә чөерде. Имештер, дөньяда алардан батыррак бар микән, имештер, хәтта сандугач та аларның җырларына хәйран кала, имештер, аларның өйләрен берәү дә җимерә алачак түгел. Көчле давыл гына булсын, имеш, сыерчыклар оясы беркетелгән колга сыначак, оя йөзтүбән капланачак.

Сыерчыклар мактанчык күршенең сүзләрен тыныч кына тыңладылар. Каты җавап кайтармадылар, «күрербез әле ничек булганын, кем отылганын», — дип калдылар.

Беркөнне чыпчык үз өенә атылган уктай кайтып керде, аның артыннан күктә, биектә карчыга күренде.

Батыр чыпчыкның кемнән куркуын сыерчыклар бик яхшы белделәр. «Батырның тавышы-тыны юк, өенә бикләнде ахры», — дип көлделәр.

Бераз яткач, чыпчык оясыннан башын чыгарды, күршеләренә сүз салды:

— Күрмәдегезме карчыга белән минем ничек сугышканны? Әй бирдем дә соң үзенә, утлар күренгәндер күзенә! — дип сөйләнде.

Сыерчыклар бер сүз әйтмәделәр, мактанчыкның кәефен җибәрмәделәр.

Беркөнне алар үз күзләре белән менә нәрсәне күрделәр һәм мактанчыкка ярдәмгә килделәр. Чыпчык бер ялгызы өендә утыра иде, әлеге дә баягы шул мактанып тора иде:

— Хуҗа мәчесенең күзен чукыдым, әй кирәген бирдем...

Сыерчыклар аның сүзен тыңлагандай иттеләр, ләкин соңыннан әйттеләр:

БИК ЯХШЫ САБАК АЛДЫ ЯБАЛАК

Зәп-зәңгәр күк итәгенә барып тоташкан, очы-кырые күренмәгән бер кара урман бар. Ул урманда яшел киемле агачлар гөрләп үсәләр, тәмле-тәмле җиләкләр кызарып пешәләр. Анда ерткыч бүреләр, хәйләкәр төлкеләр, куркак куяннар, агулы еланнар яшиләр.

Усал ерткычлар, сайраучы кошлар белән бергә бу урманда ике ябалак та тора. Төскә алар тавык төсле чуар, ә башлары аларның песи башына бик охшый, күзләре коточкыч зур булсалар да, көндезләрен күрмиләр, шуңа күрә алар ауга да төннәрен генә йөриләр.

Кичләрен кошлар сайраудан тынгач, ерткычлар йоклагач, урман эчен мәче мыраулаган, бала елаган тавышлар каплап ала. Бу тавышка кошлар томшыкларын, ерткычлар борыннарын күтәреп йокыдан уяналар: «Рәхәтләнеп йокларга да ирек бирмиләр!» — дип, ябалаклардан зарланалар.

Бер төнне шулай ябалаклар балаларын ияртеп ауга киткәннәр. Ана ябалак балаларына шушы сүзләрне әйткән:

— Улларым-кызларым, берүк сүземне тыңлагыз. Бер-берегездән аерыласы булмагыз, көндезгә калмагыз! — дигән.

Балаларның арасында бик шуГы: «Тукта әле, әни сүзен тыңламасам ни булыр икән?» — дигән, туганнарыннан

аерылып, бер якка карап очып киткән, ә тегеләр моны югалтканнар, аның өчен бик кайгырышканнар. Эзли-эзли йөдәп беткәннәр, таң тугач, өйләренә кайтып киткәннәр. Кайтсалар, теге шаян өйләрендә дә юк икән. «Улым харап булды, улым харап булды»,— дип, ана ябалак мескен өзгәләнә икән. Бала ябалаклар да бик кайгырышканнар, елашканнар.

Ә теге шаян бу вакыт аяк бармаклары белән агач ботагына нык ябышып, кая барырга белми, аптырап тик утыра икән.

Беренче булып аны тиен күргән:

— Минем агачымда нишләп болай кукраеп утырасың?— дигән.

— Тиенкәй-изгекәй, зинһар мине кума инде, бик азга булса да чыда инде, кич булуга китәрмен, сиңа мең-мең рәхмәтләр әйтермен,— дигән бала ябалак.

Ләкин тиен аның сүзләрен тыңламаган, ялваруларына колак салмаган:

— Әниең сүзен тыңламагансың, менә шушы хәлгә калгансың, үзеңә үпкәлә, андыйларга минем агачта кунак булырга рөхсәт юк,— дип, ябалак кунаклаган ботакны селкеткән. Мескен ябалак, ботакларны кабалап-кабалап, башка агачка күчкән. Ләкин кошлар аны бу агачтан да куганнар, хәзер үк күзләреннән югалырга кушканнар. Кайгысыннан ябалак онытылып киткән. Төн дип белеп очып киткән, канатларын ботакларга бәреп бетергән һәм җиргә килеп төшкән. Ә хәйләкәр төлкегә шул гына кирәк тә булган, ул аны байтактан бирле сагалап йөри икән.

Төлке аны әз генә эләктермәгән, теге шаян очып өлгергән, ләкин агач ботагына бик каты килеп бәрелгән. Төлкенең авызында каурыйлар гына калган.

Ябалак ничек кирәк алай көнне уздырган. Менә зарыгып көткән кич тә җиткән. Әнисенең әйткән сүзләре шаян ябалакның исенә төшкән, ул, мескен, елый-елый арып беткән.

Әнисе белән әтисе шук баланы эзләп тапканнар. Әздашкан ябалак баласы өйгә кайтып керүенә, шатлыгыннан елап җибәргән: «Инде һәрвакыт әти-әни сүзен тынларммын»,— дигән.

Менә шулай, шук ябалак алган бик яхшы сабак.

БИКБАТЫР БЕЛӘН БИККУРКАК

Бер баланың ап-ак куяны белән бик матур песие булган. Алар үзара бик тату яшәгәннәр. Куян кетер-кетер итеп агач кайрысы кимергән, песи чепер-чепер итеп сөт эчкән. Песи бернәрсәдән дә курыкмый икән, аңа теге бала Бикбатыр дип исем кушкан, куян дер-дер килеп бар әйбердән дә шүрли икән, аны ул Биккуркак дип атаган.

Биккуркак беркөнне стенада коточкыч әйбер күргән: колаклары бик озын, мыеклары селкенеп тора, ә үзе бик килбәтсез икән. Куркуыннан куян нишләргә дә белмәгән, баскан урыныннан кузгала да алмаган. Ярый әле Бикбатыр килеп җиткән һәм Биккуркакка бераз көч биргән: «Әй юләр, юләр,— дигән,— үз шәүләңнән үзең куркып торасың ич»,— дигән. Биккуркактан бик көлгән. «Ярый әле син килдең, Бикбатыр, куркуымнан мин үлгән булыр идем»,— дигән куян.

Икенче бервакытны куян тагын куркуга төшкән, йөрәге аның дөп-дөп итеп типкән, нәрсәдер бик нык кыштырдый икән. «Хәзер идән астыннан чыга да инде кыштырдаучы нәрсә мине кабып йота»,— дип уйлый икән куян. Песи дә колакларын торгызган, ул да курка ахры, дип уйлаган куян. Шул чак нидер шап итеп дөбердәп киткән. Куян һушсыз була язган. Ә песи, авызына нәрсәдер кабып, куян янына килгән. Килгән дә: «Менә сине куркытучы нәрсә шушы инде»,— дигән, бер кечкенә генә кара әйберне куянга күрсәткән. «Шушы кечкенә генә фетнә шулка-

дәр тавыш чыгара аламы?» — дип, тычканны куян гаҗәпләнеп караган.

Өченче бер тапкыр ачык ишектән өйгә бер эт килеп кергән һәм каты итеп өрергә керешкән. Куян кровать астына кереп качкан. Ә Бикбатыр идән уртасына чыгып баскан, зур күренергә тырышып, сыртын кабарткан, эт һөҗүм итсә, аның битләрен тырнарга җыенган. Билгеле, эт аңар кагылмаган, ишектән әкрен генә чыгып сызган. Ә Бикбатыр үзенең батырлыгы аркасында бу бәладән дә бик оста котылган.

БОЗЛАР — ЯВЫЗЛАР

I

Бердәнбер бәхетлеләр иленең, шатлык жиренең башкаласы нурга күмелгән. Көндез дияр иден — кояш юк, зәңгәр күктә йолдызлар күп, ай көлеп тора. Үзебез кабызган йолдызлар — Ильич лампалары балкый.

Көндезен хезмәт белән гөрләгән башкала шактый тынган, башын түшәккә куйган, татлы йокыга чумган.

Күз күрмәсен өчен тартылган пәрдәсыман, шәһәрне каплаган томан. Күктән сирәк-сирәк кенә мамык кисәкләре коела, кар яву шулай булып тоела.

Шундый төннәрнең берсендә академик Отто да башкалар төсле йокларга ятып карады, ләкин йоклый алмады. Ул көнне Отто партия Үзәк Комитетында булды. Аңа зур эш тапшырылды: «Төньяк диңгез юлын тормышка ашыр!» — диелде. Зур галим әнә шул бурычны үтәү теләге белән янды. Партиянең бу зур эшне аңа тапшыруына ул бик шатланды. Үзен бәхетлеләрнең дә иң бәхетлесе итеп санады.

Башындагы чиксез уйларының чигенә чыгардай булып, «кышкы салкын белән йөрәк ярсуын басармын» дип, академик Отто урамга чыкты.

Кремльнең биек манарасындагы сәгать төнге уникене сукты. Көн буе сөйләп торган радиолар халыкка тыныч йокы теләп тынып калдылар.

Куе соры күзле, җылы һәм үткен сүзле, тирән акыллы, көрәк сакаллы галим елгага таба юл тотты.

Боз юрганын ябынган елга, карамыйча зәһәр салкынга, һаман чылтыр-чылтыр ага бирә иде.

— Көндезен дә, кичен дә, бары егерме тәүлек эчендә мин Архангельскидан Владивостокта булырга, «Сибиряков» үткән юлны кабатлап карарга, хөкүмәт куйган бурычны үтәп чыгарга тиешмен,— диде зур галим.

Шушылар иде инде аны йоклатмаган уйлар, шушылар аны йомшак түшәгеннән елга буена кудылар.

Бераз йөргәч ул тынычлангандай булды, кайтырга дип кире борылды, ләкин шул вакыт әче итеп нидер сызгырды:

— Үтмәс, галим, синең уй, хыялыңны ташла, куй!

Академик артына әйләнеп караса, кечкенә генә боз кисәге сөйли ләбаса.

Калын кашларын түбән иеп, соры күзләрендә ачу уйнатып, озын гәүдәсен бөгеп:

— Булыр!— диде Отто.

— Булмас, булмас,— диде боз,— яхшы чакта сыз.

«Моның белән озак сөйләшеп мин кадерле вакытымны бушка уздырмыйм»,— дип, Отто яр кырыендагы бозга аягы белән басты:

— Менә сиңа күпне сөйләсәң. Тик кенә тора белмәсәң!

Боз аның саен теленә салышты, академикны үртәргә үк керешге:

— Юкка гына көчәнеп карыйсың, барыбер вата алмыйсың, бик тиз арырсың, хәлдән таерсың да көлтә хәтле сакалыңны җилкәңә салырсың,— диде.

— Син дә бит сөйләгән буласың, яз килерен ахры онытасың. Елга кырыена ярау яфрагы алырга, яз килгәч эреп югалырга, сине соң монда кем чыгарды шушы урынга?— диде академик.

— Кешесен кеше... диде дә боз, кызып сөйләп китте, он булып уалыр чиккә җитте:

— Мин Ак диңгезнең суларында тамчы булып уйнап

йөрдем, парга әйләндем, һавага күтәрелдем, болыт булдым, шул яклардан сезгә килдем. Минем анда туганнарым калды. Алар да туңдылар, корычтай боз булдылар. Минем белән сөйләшкәнче, син алар белән барып сөйләш минем белән көрәшкәнче, син алар белән барып көрәш. Күрмәгәнеңне күрерсең, югалырсың, үләрсең,— ди боз кисәге.

— Мин инде синең туган илеңдә берничә тапкыр булдым, тиздән тагын барам, хөкүмәт тапшырган зур бурычны үтәп кайтам. Төньяк диңгез юлын яулап алам,— ди Отто.

Боз кисәге туктарга уйламый, бер-бер артлы сүзгә-сүзне ялгый.

— Бик күп галимнәр анда үзләренә кабер таптылар, боз юрганын ябынып бер дә уянмаска йокларга яттылар. Батырларның батыры Роальд Амундсен да шунда һәлак булды, кеше коткарам дип очкан җиреннән үк юк булды. Син дә һичшиксез кире кайтмаячаксың, шунда үлеп калачаксың.

— Көрәш корбансыз булмый, андый зур эшләр җиңел генә бирелми. Кеше кулы далаларда калалар сала, ил бәхете өчен нинди кыен крепостьны да сугышып ала,— ди Отто.— Сиңа килеп сөйләрмен, теге вакыт көлгән идең диярмен, ләкин беркая китмә, эреп тә бетмә!— дип академик сүзен бетерә.

Башка сүз булмый. Боз урынында кала, күпне белүче зур галим әкрен генә шәһәр урамына кереп югала.

II

Иксез-чиксез олы илебезнең татлы җимеш-җиләкләр, күп файда бирүче үсемлекләр үстерүе уңган җиребезнең буеннан-буена яшеннән дә тизрәк, җитезрәк хәбәр тарала.

Җитез радиолар, өлгер телеграфлар, хатлар аша бу хәбәр белән бар халык таныша.

Хәбәрне тыңлаган саен тыңлыйсы килә. Анда болай диелә:

— Хөкүмәтебезнең булышлыгы, галимнәребезнең тырышлыгы белән дөньядагы иң зур экспедиция оештырыла. Бөек Төньяк диңгез юлы турындагы уйлар хыялда гына калмый, тормышка да ашырыла. Одессадан Владивостокка чаклы араны әлегә кадәр корабларыбыз илле тәүлектә үттеләр. Ә хәзер алар Архангельскидан Владивостокка егерме биш тәүлектә барып җитәргә тиешләр. Бу зур экспедициянең башында академик Отто тора, хәзерге көндә ул экспедициясе өчен белгечләр җыя...

Бу хәбәрне тыңлаган һәрбер кешенең, зурысының, кечесенең, башында бер үк уй кабатлана, телләрендә бер үк сүз ятлана:

— Көчле икәнмен — әйдә көрәшкә, ил бәхете өчен ник көрәшмәскә!

Бик күпләр экспедициядә катнашырга телиләр, шул уй белән алар академик Оттюга киләләр:

— Мин үземне бозлар-явызлар белән көрәшер өчен көчле дип сизәм, өстәвенә аларның телләрен дә яхшы беләм, мине үзегез белән алмассызмы икән?

— Алырмын үзем белән, бар, иптәш, юлга көйлән.

— Мин, котырган давылларда корабны батырмыйча, туры юлыннан тайпылдырмыйча, теләгән җиренә алып баручы капитан, корабыгызны җитәкләүне миңа тапшырмассызмы икән?

— Диңгез котыруларына күнеккән булсаң, бозлар-явызларга каршы нык торсаң, алырмын сине үзем белән, хәзер үк, иптәш, юлга да көйлән.

— Мин теләгән җиремә хәбәр җибәрәм, теләгән ил белән чыбыксыз-нисез сөйләшәм. Минем сүзләремне тау-тау бозлар белән капланган океан да йота алмый; минем сүзләремне шул океандагы боз тауларын куып йөрүче көчле җилләр дә тота алмый.

— Бар, иптәш, юлга көйлән, алырмын сине үзем белән.

— Мин, җилләр-җитезләр телен беләм, күп еллардан бирле аларның исү серләрен күзәтеп киләм, алыгызчы мине үзегез белән!

— Алырмын сезне үзем белән — бар, иптәш, походка көйлән.

— Отто бабай, алсагызчы мине үзегез белән, һәр эшне дә эшли беләм,— дип бер пионер да килә. Академик Отто дусларча елмаеп пионерның аркасыннан сөя һәм болай дия:

— Синең әле зур үсәсең, күп нәрсәләрне укып беләсең бар. Син бу эшкә яшьрәк, үскәч килерсең, тырышып укысаң зур галим булырсың, бөтен дөньяны гизеп йөрерсең,— ди.

Пионер үз сүзеннән үзе бик нык ояла, аның йөзе галстугы төсле кызара һәм ул йөгереп халык төркеме эченә кереп югала.

Төрле-төрле кешеләр иртән дә килделәр, кичен дә килделәр, академикны «йөдәтеп» бетерделәр. Ул алдынгыларның алдынгысын йөз дә уникe кешене сайлап алды. башкаларның теләкләре үтәлмичә калды, чөнки кораб өчен кешеләр шуннан артык кирәк түгел иде.

— Хезмәт бездә дан эше, кайда гына эшләсәгез дә, хезмәт бездә мактау эше, илебезнең кайсы почмагында гына яшәсәгез дә, барыгыз да бер теләк белән янасыз, илгә күбрәк хезмәт күрсәтергә ашкынасыз. Бер корабка барыгызны да сыйдыра алмыйм, менә шуңа күрә генә калганнарыгызны борып кайтарам мин!— диде академик Отто аларга.

III

Ерак-ерак диңгез эчендә, зур сынау эшенә китәргә җыйналган экспедиция кешеләрен илнең атаклылары, хезмәт батырлары, дуслары, туганнары озата килгәннәр.

Менә озак та үтмәде, пар быргысы өзеп-өзеп өч мәртәбә кычкыртты, дөнья тетрәгәндәй булды. Су өсте дулкынланды, зур кораб акрын гына юлга кузгалды. Яулыклар

байрактай болганды, кепкалар чөелде, «Сау булыгыз, исән йөрегез, җиңеп кайтыгыз»,— дигән теләкләр ишетелде.

Киттеләр.

Ленин шәһәре дә күздән югалды, тирә-якны су чолгап алды. Тарихта беренче буларак, зур экспедиция, диңгезнең көчле дулкыннарын ера-ера, еракка, Арктикага юл алды.

Көндезге аштан соң, корабтагы йөз дә уникe кеше барысы да бергә җыйналдылар, бер гаиләдәй булдылар, чебен очканы да ишетелерлек тынлык эчендә аталары Оттоның ягымлы сүзләрен тыңладылар:

— 1912 нче елны ук Франс-Иосиф җире Россиянең котып тикшерүчесе Седовны үзенә тарта, ул котыпка барып җитү теләге белән яна. Җыенып шундый мәшәкатьле юлга да чыга, ләкин аның бу юлы уңышсыз булып чыга. Седовның «Фока» исемле корабын бозлар кысалар, бер ел буе беркая җибәрми, бер урында гына тоталар. Седов аларга буйсынып калмый, киртәләргә карап тукталмый. Сигез эт җигеп, азыкларын өч чанага сала, ике матрос белән котыпка барырга кузгала. Ләкин күп тә үтми, Седовның сәламәтлеге какшый, ул зәңгелә авыруы белән авырый башлый. Авыруы көчәя бара, вакыт-вакыт ул һушыннан да яза. Иптәшләре алдамасыннар, кайту юлына таба кире борылмасыннар өчен, ул компасны гел алдында тота. Арып-талып туктыйлар бер ара, теге бичара палаткага дүрт аякланып кына бара. Бераздан коточкыч буран кузгала...

Седов авыруына чыдый алмый үлә. Йөрәкләре белән сыкрый-сыкрый иптәшләре аны күмәләр. Седовның котыпка кадалачак байрагын аның баш очына кадыйлар. Берәр җирдән ярдәм килмәсме, дип офык читенә өметләнеп карыйлар. Патша һәм министрлар бу коточкыч һәлакәт турындагы хәбәрне бик игътибарсыз гына тыңлыйлар, «шуларны коткарырга дип акча түгеп торыйкмы без!»— диләр. Диңгез министры барыннан да уздыра: «Кызганыч, кире кайтмады, судка бирер идем мин аны»,— дип куя.

Билгеле, ярдәм беркаян да килми, экспедициянең язмышын да озак еллар беркем дә белми... Ул вакыттагы күп экспедицияләрнең язмышы менә шулай бетә.

Ә еллар бер-бер артлы үтә...

Чагыштыруны сезнең үзегезгә калдырам... Шушы экспедицияләрне күз алдыгыздан үткәрегез, агачтан эшләнгән «Фока» белән корычка өртелгән «Челюскин»ны тиңләштерегез. Безнең ерактан торып сөйләшә алуыбыз, безнең ерак җирләргә очып баруыбыз, алга куелган бурычларыбыз, безгә һәрвакыт ярдәм итәргә торучы иптәшләр турында уйланыгыз...

Кораб, тау-тау дулкыннарны ерып, алга бара. Сөекле туган ил артта кала, очсыз-кырыйсыз диңгез җәелә алда.

IV

Диңгезне каплап алган боз өстендә ак аюлар уйный, симез тюленьнәр шаяра, озын тешле моржлар ял итә. Ләкин аларның тынычлыгы күпкә бармый, төтен бөркеп, офык читеннән нидер үрмәли. Диңгез җәнлекләре моны күреп хәйранга калалар, шул әйбер килгән якка таба бары да борылалар. Беренче сүзне симез тюлень башлый, җыен тузга язмаганны әйтеп ташлый:

— Нәрсә ул безгә таба килә? Усал ерткычтыр ахры, бик каты үкерә.

Ак аю тюленьнең фикерен ачыкландыра, җылы сүзләр белән дусларын тынычландыра:

— Исегез китте юк нәрсәгә, аның шикелле тере үләксәгә. Ул бит кит балыгы, ә сез шуңардан курка калдыгыз. Әнә ничек,— ди аю төтенне күрсәтә,— кит балыгы диңгез суын тышка пошкыра, аның тын алуы шулай була.

Карт морж аюга әйтеп бетерергә ирек бирми, үзенекен сөйли:

— Син, аю әфәнде, күзең күрмәсә инде башкаларны тынычландырма, ерактан күрмисең икән, доктордан күзлек сора. Минем үз гомеремдә мондый әйберне бер генә

тапкыр күргәнем бар. Аңа кораб диләр. Яхшы сакланыгыз, якын бармагыз, юкса барыбыз харап булырбыз, кешеләр тарафыннан тотылырбыз,— ди.

Барысы да куркуга кала, тик аю гына курыкмый, һаман алга бара, үзе кораб борынына таба күзен сала:

«Челюскин» дигән язуын укып, ак аю кинәт туктала.

Бозлар-явызлар аңа берьюлы кычкыралар:

— Кире борыл, аю, тизрәк кач, юкса үләсең!— диләр.

Ул нишләргә белмичә аптырап кала, ләкин шул арада нидер һаваны көчле итеп яңгыратып ала һәм аңгыра аю боз өстенә йөзтүбән ава. Бозлар да кычкыруларыннан тыналар, моржлар һәм тюленьнәр барысы да берьюлы суга чумалар. Аюны корабның бортына алалар, тунын салдырырга тотыналар.

Көчле дингезне ерып кораб һаман алга бара, ачулы дулкыннар үкерешә-үкерешә артта кала.

Башта корабка вак кына бозлар очрадылар, алар да корабтагыларга ачу белән кычкырып калдылар. Үзләре кечкенә булганга, тавышлары көчле чыкмады, шуңа аларның барлыгын да сизүче булмады.

Тора-бара өй зурлыгы бозлар да очрый башлады, кораб аларны аралап кына алга барды. Болары инде көчлерәк тавыш белән кычкырып калдылар, үзләренең тавышларын да ишеттерә алдылар. Ике яктан корабны кысрыкладылар, бик пыклап көрәшергә тотындылар:

— Безнең мәңгелек тынычлыгыбызны бозасыз, нишләп болай шаярасыз, җибәрмибез, кире борылыгыз, кайдан килдегез, шунда китегез,— диделәр.

Корабтагылар юл бирмәгән бозларны шартлатып, ватып уздылар, кайсыларын тирәләй әйләнеп чыктылар, бертуктамый алга бардылар.

Капитан рульне нык тоткан, селкенми, корабка уңга-сулга борылырга һич ирек бирми. Ерактан хәбәр бирүче туган илгә җаваплар җибәрә бара, корабтагыларның хәле турында сөйли аларга. Аның сүзләрен бозлар-явызлар

да тота алмыйлар. Житез җилләр дә куып җитә алмыйлар.

Академик Отто корабтагыларның төрлесен-төрле эшкә кушкан, төрлесенә-төрле эш тапшырган. Кайсы диңгез суын тикшерә, анда яшәүчеләрнең тормышын җентекләп өйрәнә. Кайсы котырып искән җилләрне өйрәнә, кайсы һава торышын күзәтә. Берәү дә тик тормый, бары да эшкә чумган, бары да үз эшенә алдан план корган. Яңадан-яңа әйберләр табыла, кызыклы-кызыклы серләр ачыла.

V

— Һаман алга бара да алга бара бит бу, безнең мәңгелек тынычлыгыбызга кул сала бит бу,— дип, бозлар-явызлар үзара шаулаштылар.

Үкереп искән җилләр аларга ерак Москвадагы ерак нәни боз кисәгеннән сәлам китерде, сәлам белән бергә менә шушы хәбәрне дә җиткерде:

— Мин монда бер галим белән сөйләшкән идем, безнең илгә аяк баса алмассың, баскан хәлдә дә югалып калырсың,— дигән идем. Өлкән туганнар, сез минем сүземне ничек тә дөрескә чыгарыгыз. Анда Отто дигән галим күренсә, сезнең тынычлыгыгызны бозып йөрсә, аның корабын ничек тә кире борып җибәрегез.

Бу хәбәрне ишеткән бозлар-явызлар искиткеч кыздылар, күк күкрәгән тавышлар чыгардылар, ерткычтай үкереп кораб өстенә ташландылар.

Бер ташландылар — бер эш чыгара алмадылар, икенче ташландылар — монысында да уңмадылар, өченче ташланганнар иде, корабны шытырдата башладылар.

Күз ачырмаска тырышып буран котырды, үткен камчысы белән батырларның йөзенә сыптырды, аларны аяктан екмакчы булып үз эшенә тотынды. Бозларны очыртырдай булып җил ярсыды, кешеләрне үзе белән ияртеп, каядыр алып китмәкче булды. Кешеләр: «корабыбыз бата бит инде», дип аптырап калмадылар, курыкмадылар, каушама-

дылар, батыр тордылар, тиз генә бирешмәделәр, алдан уйланган планнарын эшкә ашырырга — җир өстенә күчкән кебек, боз өстенә күченә башладылар. Авыр-авыр мичкәләрне тәгәрәттеләр, зур-зур ящикларны берәм-берәм күтәреп киттеләр. Кызыл кирпечләрне, зур фанераларны ташыдылар, бер әйберне дә су кочагына бирмәскә тырыштылар.

Туган илдәй якын кораб әкрен генә аска сеңә бара, әнә инде аның «Челюскин» дигән исеме дә югала. Бозлар-явызлар аның саен корабка ыргылалар, аны ничек тә тизрәк күздән югалтырга омтылалар.

Эшкә чумган кешеләр арасында корыч Отто да күренә, ул үткен һәм кискен приказлар бирә. Ерактан хәбәр бирүче соңгы минутка кадәр сүзен дәвам иттерә, илгә кайнар сәламнәрен җибәрә.

Кораб һаман батуында дәвам итә, әкренләп кенә су төбенә китә. Бу куркынычлы хәл ике сәгать ун минутка сузыла, шуннан соң инде кораб юк була. «Ишетегез, ишетегез, корабтан төшегез!» — дигән сигнал бирелә. Иң соңгылар булып корабтан Отто белән капитан төшәләр, шул вакытта ук боздагыларга булышырга керешәләр.

Комсомолец Могилевич төшәргә сигнал бирелгәч тә, корабтан сикерми, корабтагы әйберләрнең берсен дә су төбенә җибәрәсе килми, барысын да коткарып калырга тырыша, ашыга-ашыга, әле берсен, әле икенчесен боз өстенә ыргыта. Ләкин инде корабның соңгы секунды якынлашкан була, минут эчендә ул юк була. Могилевич боз өстенә сикерә алмый кала, кораб белән бергә ул да күздән югала.

Бу тоткынлык озаккамы соң дәвам итәчәк? Котырып искән җилләр алар урнашкан зур бозны диңгезнең кай җиренә илтәчәк? Бу боз ватылыпмы, эрепме бетәчәк?

Йөз дә дүрт кеше[1] арасында корыч кебек чыныккан-

---

[1] Сигез кеше кораб батканга кадәр материкка җибәрелгән булалар.

мары күбрәк, руда кебек эшләнмәгәннәре бик сирәк. Әнә шундыйлардан берәү өметсезләнә башлый, әкрен генә әйтеп тә ташлый:

— Сөйгән корабыбыз, «Челюскин»ыбыз су төбенә китте, димәк, безнең экспедициябез шуның белән бетте,— ди.

Моны Отто ишетеп ала, ул тегеңә үгет бирә һәм ачык итеп төшендерә:

— «Челюскин» гына батты — без батмадык, боз өстендә дә без тик ятмабыз, фәнни эшләребезне алып барырбыз, илебез өчен кирәкле мәгълүматларны алып кайтырбыз,— ди.

Беркөнне «инде нишләргә?» дигән мәсьәлә тикшерелә. Алда ике генә юл бар, кайсын сайларга: җәяүләп юлга чыгаргамы? Ярдәм көтеп боз өстендә калыргамы?

Яр кырые да ерак түгел, такыр юл булса бу араны өчдүрт көндә үтеп булыр иде, ләкин боз тауларын җәяү үтү бик куркынычлы эш. Шуңа күрә ярдәм көтәргә булалар, фәнни эшләрне туктатмаска карар кылалар.

VI

Бозлар-явызлар үзара киңәшәләр. «Корабларын батырдык, үзләрен генә юк итәсе калды»,— диләр. Белмиләр бозлар батырларның кораб түгел, кешеләр икәнен.

Боз өстендә дә безнең батырлар аптырап калмадылар, яңа шартларда яңача тора башладылар.

Брезентлардан палаткалар кордылар, кирпечләрдән кухня салдылар, фанералардан барак эшләделәр, боз таулары арасында һәм диңгез уртасында менә дигән бер кечкенә «шәһәр» төзеделәр.

Яңа тормыш башланды, ә фәнни эшләр һаман әйбәт кенә барды, һәркем билгеләнгән эшен сәгать күк төгәл башкарды: диңгезне һәм андагы җәнлекләрне өйрәнү дәвам итте, һаваны күзәтү алып барылды, эшләнгән эшләр турында радио көн дә илгә хәбәрләр тапшырды, эшләр корабтагы күк гөрләп торды.

Туган илдән килгән хәбәрләр батырларны шатландыралар, йөрәктәге ышанычны арттыралар, әйтеп бетерә алмаслык зур сөенеч тудыралар.

Тиздән, тиздән бу җиргә корыч кошлар очып килерләр, алар боз лагере өстендә әйләнгәләп йөрерләр, «кайда соң безгә төшәр өчен уңайлы урын?» — диерләр. Менә шуңа күрә алар өчен җайлы урын эшләргә кирәк. Боз тауларын тигезләргә кирәк. Менә шуның өчен безнең батырларның кулларында лом, кирка, көрәк...

Көндезен дә, кичен дә күп көч куеп тырышкач, корыч кошларны кабул итәр урын әзер була. Менә хәзер инде ерактан очып килгән корыч кошлар аптырап калмаслар, бозга куну өчен җайлы урынны минут эчендә сайларлар. Күктән — биектән боз лагерен күрмәсәләр, вышкага эленгән флагны карарлар. Җырлый-җырлый килеп төшәрләр дә тоткындагы батырларны алып та китәрләр.

Шундый өмет белән яшәгәндә, аэродром эшләнеп тәмам булганда бозлар-явызлар тагын сикеренделәр, күк күкрәгәндәй үкеренделәр, ярылып-ярылып киттеләр, берсенең өстенә берсе менделәр, батырларның әллә ничә көн көч түгүләрен минут эчендә әрәм иттеләр. Ә батырлар моны күреп аптырап калмадылар. Аның саен зуррак көч белән үзләренең эшләрен үти башладылар.

Бозлар тешләрен ыржайтып, авызларын ералар. «Йөз дә дүрт большевик дөмекте бит»,— дип шатланалар. Ярдәм килгәнен көтмәскә чакыралар, хәзер үк җәяү генә юлга чыгарга кушалар.

Зур җирдән — бозга, башкаладан боз лагерена хәбәр артыннан хәбәр килә, аларның һәрберсе сөенеч артыннан сөенеч китерә:

«Сез, туганнар, тыныч булыгыз, фәнни эшләрегезне элеккедәй дәвам иттерегез. Без тиздән сезгә барып җитәрбез һәм бөтенегезне дә алып китәрбез».

Боз лагере шатлана, шунда ук җавап та кайтара: «Эшебезне һаман дәвам итәбез, без әзер, сезне көтәбез!»

VII

Моторлар җыры һавада яңгырый. 170 миллион халык берьюлы күккә карый. Кошлар сайрамыйлар — моторлар җырлый, 170 миллион халык алар җырын тыңлый.

— Нәрсә булыр? Кем җиңелер?

Безнең илнең явыз дошманнары да уйга калганнар, зәһәрле еланнар да нигәдер тынганнар.

— Нәрсә булыр? Кем җиңелер?

Ә үзләре төрлечә әйтәләр:

— Корыч кошларның канатлары бозланып ката, боз лагерена барып җитә алмаслар, түбәнгә кадалырлар,— диләр алар.

Дошманнар-еланнар, юкка гына авызыгызны ерасыз, җилләр-тиләләр, сез дә юкка гына шаярасыз, корыч кошларны сез кире бора алмассыз. Алар куян түгел — дошманнан куркырга. Алар чыпчык түгел — давылдан качарга. Алар охшыйлар зур лачыннарга; маташмагыз, комачауламагыз, комачауламагыз сез корыч кошларга!

Боз лагере көндезгәчә эшкә чумган, тынлык онытылган.

Уртадагы иң җылы палаткадан елаган тавыш ишетелә. Кем елый? Ник елый? Кайсыгыз белә?

— Һавага чыгарыгыз, йөрисем килә, боз диңгезен күрәсем килә,— ди.

Аңа каршы төшәләр:

Тышта кырык градус салкын, өшерсең, яңа гына һава алып кердең бит,— диләр.

Карский диңгезендә туган Карина шулай назлана, ә бердәнбер кечкенә иптәше Алло үгет биргән була аңа:

— Син, Карина, карышма, зурлар белән тартышма.

Шул чак иң җылы палатканың ишеге ачыла, Карина каршына Отто кереп баса.

— Я, балалар, ни хәлләр бар? Авырмыйсызмы? Еламыйсызмы? Ул тезенә Карина белән Аллоны утырта да зур сакалын селки-селки сөйләргә тотына:

— Син, Алло, корабта гына йөрергә өйрәндең, синең әле юк җир өстенә басып йөргәнең. Кораб белән боздан башка ямь-яшел агачлар үскән, көмеш кебек сулар агып торган җир дә бар. Менә тиздән корыч кошлар килерләр, икегезне дә, сезне дә, безне дә алып китәрләр, шул җирне сезгә дә күрсәтерләр.

Нәкъ менә шул чагында офык читендә бер кара нокта күренде, тора-бара бу нокта зур булды, һаман алга үрелде. Берничә минут үтәр-үтмәс боз диңгезе мотор җырына күмелде.

Кемдер: «Иптәшләр, самолет!» — дип кычкырды. Академик Отто да балаларны тезеннән төшерде: «Әнә, безне алырга килделәр дә»,— дип чыгып йөгерде.

Зәңгәр күктә үзенең көмеш канатлары белән корыч кош ялтырый, боз таулары белән капланган диңгез өстендә мотор тавышы яңгырый.

Салкынга карамастан, бүрекләр һавага чөелә, «урра!» тавышы яңгырап җәелә.

Әнә, бүреген кулына тоткан Отто да аэродромга таба йөгерә, ә очкыч һаман түбән төшә бирә.

Бер әйләнә, бозга шактый якын килә, «инде төшәм» дигәндә генә кире күтәрелә. Икенче кат әйләнеп, кунарга урын сайлый, канатларын җәйлый. Тәмам бозга якын килә, канатына боз тиярлек булгач, кире күтәрелә. Өченче кат әйләнергә тотына, монысында инде бик җайлап боз өстенә төшеп утыра.

Боз дерелдәп киткән кебек була. Җил исүеннән тына.

Боз батырлары очучыны күтәреп алдылар, иркәләп, сөеп һавага чөяргә тотындылар. Һәр йөрәктә шатлык, чиксез сөенеч, зур рәхмәт уты балкый.

Батыр очучы озак тормады. Ул хатын-кызны, Аллоны, Каринаны үзе белән алды, һәм юлга кузгалды. Мотор тавышы тагын һаваны яңгыратты, боз лагере аны кул чабып, биеп, шатланып озатты.

VIII

Иртәгесен очкычлар килер дигәндә генә коточкыч буранлы давыл кузгалды. Бозлар-явызларның да котырулары кузгалды. Суык та көчәйгәннән-көчәя барды.

Очкычларны кабул итәр өчен хәзерләнгән аэродромны кар күмеп китте. Баракларга да чират җитте. Бозлар чатнап-чатнап ярылдылар, баракны урталайга аердылар.

Буранның дулавына, җилнең улавына, бозларның ярылуларына карамыйча боз лагере эшен дәвам итте, кар көрәргә дә вакытлары җитте.

Кораб баткач, андагылар боз өстенә чыккач, бозлар-явызлар бик шатландылар, боз өстендәгеләрне барысын да берьюлы юк итмәкче булдылар, бу хакта төрлечә план кордылар.

Илнең корыч кошлары, совет очучылары, аларның бу планнарын җимерделәр, боз тоткыннарын коткарырга очып килделәр.

Берничә батырны алып киткән беренче очкыч килеп китүгә шактый вакыт үтте, ә буран һаман туктамый, ә давыл һаман тынычланмый иде.

Отто галимнең сәламәтлеге шактый какшады. Ул нык кына авырый башлады. Тешләрен кысып, иптәшләреннән авыруын бер көн яшерде, иптәшләре сизмәделәр, икенче көн түзде, тегеләр һаман белмәделәр, өченче көн инде иптәшләре сизделәр: «Сез бит авырыйсыз, иптәш академик!» — диделәр. Ә ул: «Әһәмият бирмәгез, авырый димәгез, болай гына, бераз кәефем генә юк»,— диде. Өч көн буе авыру белән тартышты. Бу көрәштә авыру өстен булып чыкты, Оттоны аяктан екты. Моны күргән бозлар-явызлар шаркылдап котырындылар, галим Оттоның тынычлыгын боздылар, колакларны ярырлык итеп үкерергә тотындылар.

Һәлакәт булганда экспедиция башлыгы иң соңгы булып котыла, бу — гадәт, закон булып тотыла.

Оттоның да бу законны җимерәсе килмәде. Авыруына карамастан, боз лагерен ташларга теләмәде. Ләкин радист бу хәбәрне башкалага ишеттерде. Аннан шул көнне үк хәбәр дә килде: «Беренче килгән очкычта, һичбер тоткарсыз, экспедиция башлыгы Оттоны коткарыгыз»,— диелгән иде.

Өч-дүрт көннән буран басылды, давыл тынды, көн яктырып киткәндәй булды. Җил генә һаман тынычланмады, салкын һаман тукталмады.

Батыр очучылар аңа карамадылар, корыч кошларына утырдылар да боз лагерена таба юл тоттылар.

Ерак очу юлы боз таулары аркылы, диңгезләр аша салкын котыпка барып тоташа. Бу юл һичкайчан да өйрәнелмәгән, үз гомерендә моңар кадәр очкыч күрмәгән. Куе томаннар адаштырырга гына тырышалар, очкычка сырышып боз булырга торалар.

Бу юлы бозга килеп төшүе кыен булды. Очкыч килеп төшкәндә боз җимерелгәндәй тоелды. Батыр очучылар аптырап калмадылар, утыру урынын бик җайлы сайладылар.

Тагын «урра!» тавышы яңгырады, язып-әйтеп бетерә алмаслык шатландылар, ләкин башканы уйлап, башларын түбән иделәр,— кайгырдылар. Бүген алар якын дусларыннан, житәкчеләреннән, аталары академик Оттодан аерылдылар.

Әнә Оттоны чанага салып тартып алып килделәр. Очкыч янына килеп туктадылар, сүзсез калдылар, башларын түбән иделәр. Авыр иде аерылу минутлары, йөрәкләрне телгәләде кайгы утлары. Хәлсез башын Отто күтәрә төште, әзеп-әзеп кенә соңгы сүзен сөйләргә керешге:

— Дуслар, хушыгыз. Совет кешеләре икәнегезне онытмагыз, ныклык байрагын югары тотыгыз, сынатмагыз!— диде.

Моторлар тавышы башланды. Җылы сүзләр колакларда яңгырый калды. Очкычлар кузгалды.

IX

Менә инде боз лагеренда алты кеше, сигез эт кенә калды. Башкалар бары да коткарылды.

Күп җәфалар чигеп батыр очучылар тагын очып килделәр; кешеләрне, этләрне, фәнни материалларны төяделәр. Шулар белән һавага күтәрелделәр.

Боз лагеренда батырлар кабызган ут яна калды, биек мачтага беркетелгән кызыл байрак көчле җилфердәде. Ә алар үз юлларын тоттылар, иптәшләре янына ашыктылар.

Ягез инде, дошманнар, ерган авызларыгызны йомыгыз; дуслар, якын дуслар, безнең белән бергә шатланыгыз. Совет кешеләре боз тоткынлыгында искиткеч нык тордылар. Совет очучылары бөтен дөнья алдында беренчелеккә имтихан тоттылар.

— Ә сез, бозлар-явызлар, «Кораб батты» дисезме?

— Әйе, батты.

— Ә сез, җилләр-җитезләр, безнең корыч кошлар белән узышып карадыгызмы?

— Әйе, карадык.

— Барыбер куып җитә алмадыгызмы?

— Җитә алмадык.

— Тапшырылган эш тулысынча үтәлдеме?

— Әйе, үтәлде.

— Кирәкми хәзергә бүтәне.

— Әйе, бүтәне...

— Алай булса алга карагыз.

Әнә анда тау буйлап сузылган корыч тасмалар буенча бер поезд ашыга, тизрәк-тизрәк башкалага җитим, дип ул ашкына.

Поезд тукталган арада, аны тирәли чорнап алалар, утырып баручыларны шәһәрләр, колхозлар, совхозлар, завод-фабрикалар кунакка чакыралар. Үзләренең шатлыкларын сөйлиләр. «Әйдәгез безгә кунакка!» — диләр.

* * *

Башкалада зур тантана.

Бүген ул үзенең батыр улларын каршы ала.

Урамнар байраклар белән бизәлгәннәр, матур-матур чәчәкләргә күмелгәннәр. Урам буйлап шат халыклар агыла. Оркестрлар җиңү маршын яңгыраталар.

Поезд үзенең килеп җитүен белдерде, матур итеп кенә кычкыртып җибәрде. Җирне тетрәтеп, һаваны яңгыратып «урра!» яңгырады.

Чәчәкләр яуды батырлар өстенә, мактаулар яуды алар исеменә. Һичбер вакыт таныш булмаганнар да кулларын кысыштылар, тәбрикләштеләр.

Әнә, совет халкы академик Оттоны кулларында тирбәлдереп трибунага китерәләр, аның сөйләвен үтенәләр.

Ә ул зур сакалын тоткан килеш сүзен башлый алмый аптырап кала, ләкин бик тиз үзен кулга ала.

Зур галим Бөек Төньяк диңгез юлын бер навигациядә үтеп булуын сөйли: «Безнең ил зур бозваткычлар төзәчәк, төньякны көннән-көн яхшырак үзләштерәчәк»,— ди.

Җиңелеп түгел, җиңеп кайтты Отто бабай. Батырларның могҗизасы бөтен дөньяны таңга калдырды, безнең йөрәкләрне шатландырды, безне дә җиңүләргә ашкындырды.

БАЙ БЕЛӘН ЯЛЧЫ

(Төркмән әкияте)

Мрали үзенең атасын күрмәгән, ул ятим булып үскән. Аның бары тик бик картайган анасы гына булган. Ул кешеләргә җеп эрли, ямау ямый, кер юа, шулай итеп улын туйдыра икән. Ә улы зур булып үсеп җиткәнче һаман шар сугып йөргән, берниндн дә файдалы эш эшләмәгән.

Беркөнне әнисе аңар әйткән:

— Улым минем, без болай икмәк таба алмабыз. Сине туйдырыр өчен әтиең дә теге дөньядан кайтмас. Карт анаңның да инде эшкә көче житәрлек түгел. Үз-үзеңне туйдырырлык нинди дә булса берәр эш тап инде,— дигән.

Шуннан соң Мрали эш эзләп чыгып киткән. Тегендә, монда барган, ниһаять, бер байга ялчы булып ялланган. Ул бай берничә көн буена Мралидан берниндн дә эш эшләтмәгән. Бу хәл аңа гаҗәбрәк булып тоелган.

Озак та үтмәгән, бай бер үгез суеп, аның тиресен тунаткан. Ике дөя җитәклэп, дүрт капчык һәм әлеге үгез тиресен дә алып, тауга таба юнәлгән. Мралига да үз артыннан барырга кушкан. Тау итәгенә барып житкәч, бай дөяләрен туктаткан да алар өстендәге капчыкларны һәм үгез тиресен алган.

Бай үзенең ялчысына әлеге үгез тиресе эченә кереп ятырга кушкан. Аннан ул аны нык итеп бәйләгән дә ташлап киткән. Бераз вакыт үткәч, кыргый кошлар очып

килгәннәр дә авызларына кабып, аны күтәреп очып киткәннәр. Тау башына менеп житкәч, алар чукып-чукып тирене ертканнар: аның эчендә кеше барлыгын күргәч, үгез тиресен эләктереп бик тиз очып киткәннәр.

Тау итәгеннән, түбәннән бай кычкырган:

— Улым, тау башындагы кыйммәтле ташларны миңа ыргыт әле,— дигән.

Тау башында төрле-төрле кыйммәтле ташлар: зөбәржәтләр, якутлар, ахаклар һәм башка эре-эре матур ташлар бик күп икән. Ялчы шуларны түбәнгә ыргыткан, ә бай аларны җыеп капчыгына тутыра барган.

— Бай әфәнде, мин соң моннан ничек төшермен?— ди икән мескен Мрали.

— Хәзергә ташларны күбрәк итеп җый, төшү юлын соңыннан үзем өйрәтермен,— дигән бай. Ялчы аның сүзенә ышанган һәм кыйммәтле ташларны түбәнгә таба ташлый да ташлый икән.

Ике капчыкны тутыргач, бай аларны дөяләренең өркәчләренә урнаштырган да үзе көлеп:

— Улым минем! Син ничек булса да өеңә кайтырсың дип уйлыйм. Ялчыларыбызны без менә шундый эшкә кушабыз,— дигән һәм киткән дә барган.

Тау башында ялгыз калган Мрали төшәр өчен җайлы урын эзләгән. Ләкин тапмаган. Тирә-якта кеше сөякләре аунап ята икән, Мрали куркып киткән.

Арттан гына бер кыргый кош килгән дә аны кинәт күтәреп тә киткән. Мрали ике кулы белән аның аякларына ябышкан. Кош үзе теләсә-теләмәсә дә җиргә төшәргә мәҗбүр булган. Шулай итеп Мрали һәлак булудан котылган.

Күп тә үтмәгән, ул тагын да шул ук байга ялчы булып ялланган. Бай инде ялчысының исән калуы турында башына да китермәгән. Мралины да бөтенләй башка кеше дип уйлаган.

Менә бай тагын ике дөя, дүрт капчык һәм үгез тиресе алып, ялчысына:

— Әйдә, киттек,— дигән.

Алар шул ук тау буена килеп туктаганнар. Бай бу юлы да теге вакыттагы кебек үк, Мралига тире эченә кереп ятырга кушкан. Мрали әйткән:

— Ничек ятырга кирәклекне үзең күрсәт әле: мин никтер аңлый алмыйм,— дигән.

Бай: «Менә шулай ит!»— дип, тире эченә кереп яткач, Мрали аны тирегә төреп, бәйләгән дә куйган. Күп тә үтмәгән элеге кыргый кошлар килеп җиткәннәр дә тирене күтәреп очып киткәннәр һәм тау башына алып менгәннәр. Тирене чукырга тотынганнар. Эчендә кеше барлыгын белгәч, аны ташлап киткәннәр.

— Бай әфәнде, мин сиңа кыйммәтле ташлар ыргыткан кебек, син дә миңа аларны ташла әле,— дигән Мрали.

Бай шул чакта гына аны таныган. Куркуыннан һәм ачуыннан дерелди-дерелди кычкырган:

— Теге вакытта син каян төшкән идең? Ишетәсеңме, тизрәк җавап бир!

— Күбрәк таш ташлавыңны гына бел, эшеңне бетергәч, ничек төшәргә кирәклеген мин үзем өйрәтермен,— дигән Мрали көлеп.

Бай ташларны ыргыткан да ыргыткан.

Мрали байга кычкырган:

— Бай әфәнде! Син дә ничек булса да төшәрсең дип ышанам. Тирә-ягыңа күз сал әле: синең шәфкатең аркасында шунда калып үлүчеләрнең сөякләре аунап ята. Син дә шулардан яхшылап сораш, ә мин ул вакыт эчендә өемә кайтып китәрмен,— дигән...

Мрали ташларны, капчыкларны һәм дөяләрне — барысын да базарда саткан, күп еллар буена җитәрлек акча хәзерләп, ул инде бер дә күрешә алмабыз дип уйлаган әнкәсе янына кайтып киткән.

СТАРОСТА БЕЛӘН ШАЙТАН

(Латыш әкияте)

Староста үзенең йортыннан алпавыт ишек алдына габа бара икән, юлда аңа шайтан очраган. Менә алар бергәләп, сөйләшә-сөйләшә барганнар һәм юл буенда дуңгызлар көтүче бер малайны күргәннәр. Аның бер зур дуңгызы бәрәңге кырына кергән булган. Малай старостаны күрүгә, дуңгыз артыннан кырга ташланган:

— Әй сине, шайтан алгыры! Бигрәк тә кабахәт дуңгызсың!— дигән.

Староста моны ишеткәч, шайтанга төртеп куйган:

— Ишетәсеңме, сиңа дуңгыз бирмәкче булалар, ә син алмыйсың. Мин булсам, хәзер үк барып алыр идем,— дигән.

Шайтан аңа болай дип җавап биргән:

— Дуңгыз калсын, тимик! Көтүче малай ул бер ятим бала, әгәр мин аның дуңгызын алсам, хуҗа ул малайны кыйнар. Малайның яклаучысы юк. Бу сүзләрне ул малай чын күңеленнән әйтмәде бит.

Староста сүзсез калган. Менә алар тагын алга киткәннәр, һәм бер баланың кызганыч тавыш белән елавын ишеткәннәр. Анасы арыш ура, ә баланы юатырга аның вакыты юк икән. Ачуланып ул баласына әйтеп ташлаган:

— Әй, сине, шайтан алгыры, әтиең бай кырында эш-

ли. Менә монда арышыбыз коела, урыр кешебез юк, ә син миңа тынычлап эшләргә дә ирек бирмисең!

Староста моны ишеткәч, шайтанга төртеп куйган:

— Ишетәсеңме, синңа әнә бер бала бирмәкче булалар; мин аны хәзер үк алыр идем,— дигән.

Шайтан болай дип җавап биргән:

— Ул бала бу ананың бердәнбер кызы, мин тагын инде аны да алыйм диме? Ана бу сүзләрне чын күңеленнән әйтмәде, юри генә әйтте бит.

Староста сүзсез калган. Алар тагын алгарак киткәннәр. Алпавыт кырында крестьяннар эшлиләр икән. Алар старостаны күрүгә төкеренергә, аны ачуланырга тотынганнар.

— Тагын теге әшәке палач — староста килә, шайтан алгыры! Күр дә тор, тагын кемнең дә булса аркасына таяк белән менеп төшәр!— дигәннәр алар. Шайтан моны ишеткәч, старостага әйткән:

— Ишеттеңме? Менә болар инде моны чын күңелләреннән әйтәләр.

— Алар кем соң?— дигән ачуланып староста,— алар бит эт халык; тыңламыйлар, эшләмиләр!

— Синеңчә, алар андый-мондый халык булсалар да, алар хаклыкны сөйлиләр һәм чын күңелләреннән әйтәләр, менә шуңа күрә син хәзер минеке!— дигән шайтан.

Шайтан шушыларны әйткән дә старостаны эләктереп тә алган. Муенын сындырган, гәүдәсен боргалый-боргалый тәкә мөгезе хәленә китергән дә, күн капчыгына салып, коточкыч өермә, давыл куптарып, старостаны туп-туры тәмугка алып киткән.

ҚАЗ БЕЛӘН АККОШ

Очы-кырые күренмәгән болын уртасында зур бер күл булган. Тирәләре аның яшел кыяклар, шаулап торган камышлар белән капланган икән.

Бу күл буена кеше аягы бер дә басмаган, ул тирәләрдә аучыларның мылтыклары да шартламаган.

Шул тыныч күлдә аккош белән каз яшәгәннәр. Балык ашаганнар, су эчкәннәр, йомырка салганнар, бала чыгарганнар.

Җәйнең матур бер көнендә бу ике күрше үзләренең балалары турында сөйләшкәннәр. Киек каз әйткән:

— Улым ашны аз ашый, суны гына күп эчә!— дигән. Аккош әйткән:

— Минем балам бик яхшы ашый, зур үсә,— дигән. Каз үзенең бәбкәсен төрлечә сыйлап карый икән: тәмле-тәмле балыклар, яшел бакалар, татлы кыскычлар тотып китерә икән. Баласы үзе зур булса да кулына кашык тотып ашамаган, әнисенең ашатуын көткән. Ашау аңа бик зур эш булган. Ашарга, эчәргә тотынса, ул тәмам йөдәп беткән. Ә дуга муен-аккош баласы кыстатып та тормый, кашыкны үзе тотып, азыкны кат-кат чәйнәп, тәмле итеп ашый икән. Вакытында йоклый, вакытында һавага чыга, уйный, шуңа күрә алма кебек кызарып, матур булып үсә икән.

Көннәрдән беркөнне киек каз белән аккошның балалары әниләренә килгәннәр дә:

— Әни, безгә велосипед алыйкчы!— дип үтенгәннәр.

— Ярый, барсак барыйк, алсак алыйк,— дигәннәр

әниләре. Улларын ияртканнәр дә, велосипед сатыла торган магазинга киткәннәр. Анда барып кергәннәр дә әниләре:

— Иптәшләр, безнең сөекле улларыбызга велосипед бирсәгезче!— дигәннәр. Шунда сатучылар йөгереп килгәннәр дә:

— Рәхим итегез, рәхим итегез!— дип көмеш төсле ялтырап торган, ике тәгәрмәче әйләнеп торган велосипедлар китереп биргәннәр. Шунда аккошның улына:

— Теләгәнеңне сайлап ал, акыллым!— дигәннәр.

Аккош бәбкәсе велосипедка менеп атланган да, йөгерткән дә киткән. Аңа карап сатучылар:

— Менә егет икән бу малай, тамагына шәп ашый ахры,— дигәннәр, ә аккош үз баласының булдыклылыгын күреп, елмаеп, кәефләнеп карап тора икән, ә малай велосипедны йөгертә дә йөгертә икән.

Киек каз бәбкәсенә дә чират җиткән. Ул аккош бәбкәсе белән бер яшьтә булса да, аңа караганда бик ябык, буйга да бик кечкенә икән.

Аңа да велосипедның көмеш төслесен биргәннәр:

— Я әле, акыллы, син дә йөгереп кара!— дигәннәр. Каз бәбкәсе бер атланып караган — булдыра алмаган, икенче атланырга уйлаган — егыла язган, өченче тапкыр атланырга теләгән икән — егылып ук киткән, әйләндермәгәч, велосипед та китмәгән. Магазинда эшләүче абыйлар шунда ук йөгереп килеп җиткәннәр, киек каз бәбкәсенә менә шушы сүзләрне әйткәннәр:

— Син, акыллы, ашны аз ашыйсың, вакытында йокламыйсың, һавада уйнамыйсың, ахры, шуңа күрә син ябык, буең да кечкенә, шуңа күрә велосипедка аягың да җитми, хәзергә өеңә кайтып тор, зур үскәч килерсең,— дигәннәр һәм велосипедны да алып киткәннәр.

Каз бәбкәсе бик күңелсезләнеп кайтып киткән, ә аккош бәбкәсе велосипедына атланып җилдергән.

Хәзер инде, «велосипедка аягым җитсен»— дип, каз бәбкәсе азыкны да күп ашый, вакытында йоклый да, саф һавада да уйный икән.

ҚУЯН ҚЫЗЫ

Бер соры куянның үзе төсле зур колаклы, бик иркә, бик кадерле бер кызы булган. Ул аны бик-бик ярата икән.

Көннәрдән беркөнне куян иркә кызына өр-яңа киез итекләр алып кайтып биргән.

— Мә, бәбкәм, аякларың туңмасын, сызламасын,— дигән.

Қызы бу бүләкне бик шатланып алган. Әнисенә рәхмәтләр укыган. Хәзер инде ул яңа киез итекләрне киеп, рәхәтләнеп йөри икән. Ләкин куян кызы җылы итекләргә өйрәнмәгән булган, ул алардан бик тиз туйган, салып ташлаган. Әнием тапмасын дип, аларны яшереп куйган. Әнисе аларны эзләп табып баласына кигезә, ә ул салып ташлый икән. Әнисе кигезсә, ул салган, әнисе тагын кигезгән, ә ул тагын салып ташлаган.

Қар өстеннән дә, боз өстеннән дә яланаяк йөгерә икән. Бер көн буе шулай йөгергән, икенче көнне дә шулай яланаяк йөргән, өченче көнне инде аксый-аксый әнисе янына килгән.

— Әни, әни, минем аягым бик авырта!— дигән. Әнисе аның аякларына караган да аптырап калган.

— Қызым, кызым, якты йолдызым, синең аягың шешкән ич,— дигән.

«Инде ни эшләргә?»— дип уйга баткан куян. «Бу баланы кая алып барырга, ничек дәваларга?»— дип кайгырган.

Шул вакыт нәрсәдер кычкырган. Куян, агач башына күтәрелеп караган икән, тиенне күргән. Ул куянга болай дигән:

— Кайгырма, туганкай, йомшак куянкай, кызыңның аягын бик тиз төзәтеп була. Моның өчен «доктор Айболитка» барырга, аңардан киңәш сорарга кирәк,— дигән.

Куянга чын-чынлап булышырга тотынган, «доктор Айболит»ның өенә үзе илтергә булган.

Куян кызын күтәргән дә «Айболит докторга» киткән, тиен, агачтан-агачка сикереп, аңа юл өйрәткән.

Барып җитсәләр, «доктор Айболитның» эше бик күп икән, аңа урманның төрле ерткычлары дәваланырга килгәннәр икән. «Балаларны чиратсыз карыйм мин»,— дигән «доктор Айболит». Куян кызын доктор бүлмәсенә алып кергәннәр, нәрсә белән авыруын сөйләп биргәннәр. «Доктор Айболит» куян кызының аягына дарулар сөрткән һәм шул вакытта куян кызына әйткән:

— Аягың төзәлгәч, киез итекләрне инде салкын көннәрдә бер дә салма, сүзне тыңла, тагын начар хәлгә калма,— дигән.

«Доктор Айболитка» алар бик зур рәхмәтләр әйткәннәр, саубуллашып өйләренә кайтып киткәннәр. Өч көн дигәндә, куян баласының аягы төзәлгән. Ул инде хәзер киез итеген бер дә салмый киеп йөри икән.

ЧУКМАР БЕЛӘН ТУКМАР

Бер әбинең ике әтәче булган. Бу әтәчләрнең берсе ак, берсе кара икән. Ул аларның икесен дә бертигез ярата икән. Әтәчләр күп вакытларын сугышып үткәрәләр, сугышырга тотынсалар, канга батып бетәләр икән.

Ак әтәчне әби Чукмар дип кушкан, карасын Тукмар дип атаган. Чукмар чукырга бик оста, ә Тукмар бик оста тукый икән.

Әби ашатырга тотынса: «Җимне миңа әзрәк бирдең», «Ник минем өлешемә кердең?»— дип кычкырыша башлыйлар икән әтәчләр. Әйтешеп-әйтешеп кенә калмыйлар икән, шунда ук сугыша да башлыйлар икән. Чукмары канга батырганчы чукырга, Тукмары күгәрткәнче тукмарга тотына икән.

Бердәнбер көнне бу әтәчләр шулай бик каты кычкырышканнар һәм канга батканчы сугышканнар. Әбинең моны күреп бик ачуы килгән. «Боларны ни эшләтим икән»,— дигән. Тегеләрне бик каты орышкан, сугышмаска кушкан. Тегеләр әби алдында бераз тынычланып торганнар, әби аларның күзләреннән югалгач, тагын сугышырга тотынганнар.

Әби килеп җитсә, Чукмар исемле ак әтәч йөгереп килеп:

— Әби, әби, кара әле, Тукмарың тукмый-тукмый башымны күгәртеп бетерде,— дип әләкли икән. Тукмар исемле кара әтәч тә энесеннән калышмый:

— Башымны кара әле, әби, Чукмарың чукый-чукый канатып бетерде,— ди икән.

Әби аларның әләкләүләреннән дә туйган. Ул бер сүз дә әйтмәгән, Тукмарны култыгына кыстырган да каядыр күтәреп киткән. «Суярга алып китә ахры мине»,— дип курыккан Тукмар. Ләкин әби аны күршеләргә генә кертеп торган. Ул әтәч шунда өч кич кунган.

Ялгыз калгач, Чукмарга бик күңелсез булган, аның күңеле тулган. Юньләп ашый да, эчә дә алмаган. Әбигә ул: «Тукмарны алып кайтсана, инде бер дә сугышмас идек»,— ди икән. «Ярый,— дигән әби,— алып кайтсам кайтыйм, әгәр тагын сугыша торган булсагыз, ул вакыт тотам да берегезне бөтенләй юк итәм»,— дип куркытып куйган һәм күршедәге Тукмарны алып кайткан.

Тукмар да Чукмарны бик сагынган булган, алар, күптәннән бирле күрешмәгән туганнар төсле, кочакланышып исәнләшкәннәр һәм киләчәктә бер дә сугышмаска сүз бирешкәннәр.

Хәзер инде алар бик тату яшиләр икән, тик аларга кушылган исемнәр генә аларның электәге шуклыкларын күрсәтеп, исләренә төшереп тора икән.



Хикәяләр



ТЕРМОМЕТР

Чистай комсомол оешмасына багышлана бу хикәя.

Аргаш басуыннан искән җил, үзе белән бергә, Ташлыяр авылына төтен исен дә алып килә. Тау кырыена утырган Ташлыяр авылын менә шул зәңгәр төтен каплаган. Көмеш ай яктысында зәңгәр төтенгә чорналган авыл күренә. Әйтерсең, ул зәңгәр диңгез уртасында башын калкыткан атау; төтен эченнән авыл шулай күренә.

Хәзергә әле бөреле агач ботаклары гына бер-берсе белән чәбәләшеп шаяралар. Актай суында кабыргалы дулкыннар төркеме юк. Очарга җыенган кошсыман, канатларын җәйгән тегермәннәр дә авызларын күтәреп тормыйлар, гигант вентиляторларсыман, бертуктамый зырылдыйлар гына...

Җил яңа гына ишектән чыгучы Бәдерниса карчыкның сарфинка яулыгы белән уйный.

Менә шушы әкрен искән язгы җил дә, түбәләрне куптарып ташларга көче җитә торган давыл кебек, Бәдерниса карчыкның сарфинка яулыгын үзе артыннан эләкте-

реп китәргә чамалый. Яулык ачулана-ачулана җил белән тартыша. Парадларда җилгә каршы бөтерелә торган байракларның берсе шикелле болгана.

Ләкин җил юкка гына маташа, юкка гына хәленнән тая; юкка гына Бәдерниса карчыкның болай да чепелче күзләренә чүп кертергә омтыла. Бәдерниса аның ул омтылуларына, ул маташуларына, ул көчәнүләренә каршы бер генә хәрәкәт ясый. Чыра кебек ябык беләген суза да, сарфинка яулыкның очын эләктереп ала. Шул яулыкның очы белән чүп кергән күзен сөртә.

Картының ерак кырга сөрергә китүе карчыкның күңелен борчып алды, ул чикмәнен алып киттеме икән соң дип уйлап куйды карчык.

«Нишләп соң бу Җиһан җыелышка дип киткән җиреннән кайтмады. Башка көннәрне төн урталарында булса да кайта иде ләбаса...»

Карчык, таңның соргылт көмеш нурлары белән яктырган зәңгәр ераклыкка тагын бер мәртәбә күзен төшерде дә:

— Ана күңеле балада, бала күңеле далада шул,— дип мыгырдый-мыгырдый әкрен генә атлап өйгә кереп китте.

II

Колхоз идарәсендә булган комсомол җыелышы да Бәдерниса карчыкны борчыган нәрсә хакында тикшерде. Ләкин комсомоллар пошынып кына, әчтән янып, көеп кенә калмадылар. Бар нәрсә дә, барлык эш тә кулларыннан килә алуына үз көчләренә нык ышанган батырлар шул хакта чаралар эзләргә керештеләр. Җыелыш, салкыннар булу уңае белән, чәчелгән ашлыкның хәле турында агроном докладын тыңлады:

— Без быел чәчүне яхшы уздырдык. Хәзер менә игеннәрне тамырда килеш яхшы сакларга кирәк. Без бу эштә дә, язгы чәчүне яхшы үткәргән кебек, үрнәк күрсәтергә тиешбез.

Соңгы көннәрдә салкыннар биш-алты градуска җиткән чаклар да бар. Дөрес, бу салкынга безнең башка ашлыклар барысы да түзәләр. Тик менә яңа гына чыгып килә торган борчак кебек үсемлекләрнең өшеп юкка чыгуы куркынычы бар. Бүген үк, хәзерге минуттан ук чаралар күрергә кирәк.

Агроном әнә шундый сүзләрне сөйләде. Үзе докладын бетергәч, сорау бирүне дә көтеп тормады, урамга чыкты.

Идарә бүлмәсендә тирән тынлык урнашты.

Ләкин агроном тиз әйләнеп керде. Хәзергә кадәр хәрәкәтсез торган, башын түбән игән Җиһан:

— Ничә?— дип сорады.

Агроном:

— Ике ярым!—дип җавап кайтарды.

Аннан җиң эченнән чыгарып, ялтырап торган термометрны өстәлгә куйды.

Алар озак, бик озак сөйләштеләр. Киңәшү байтакка сузылды. Көн кич иде, төнгә әйләнде. Күкне болыт баскан иде, җил чыгып аларны кайсын кая куып бетерде. Тегермәннәр канатларын җәеп торалар иде, җил аларга чыбык буенча килгән ток кебек булды. Алар бердәм хәрәкәтләнергә тотындылар. Әйтерсең, комсомоллар да шуны гына көтеп тордылар. Аларның башларын ваткан мәсьәлә чишелде. Хәрби приказ кебек һәр сүзе кискен, һәр сүзе үткен һәм урынлы куелган карар чыгарылды.

«Социалистик игеннәрнең уңышын саклауны ячейка үз өстенә ала. Бу эшне башкару өчен комсомоллар һәм колхоз яшьләреннән югары уңыш күзәтчеләре оештырырга. Шул эшкә бүгеннән керешү теләге белән, Ташлыяр авылы комсомоллары, шушы вакытлы салкыннардан тиз салкынга бирелә торган борчак кебек үсемлекләрне саклап калу өчен бу эшкә үзләрен мобилизовать итәләр».

Югары уңыш күзәтчеләренең бурычлары турында агрономнан соң ячейка секретаре сөйләп китте:

— Югары уңыш күзәтчеләре былтыр ук төзелгән бул-

са да, алар эшләми яттылар. Үзләренә төшкән бурычны аңламадылар. Менә быел инде без аларны йокыларыннан уятабыз. Һәр күзәтче үзе күргән җитешсезлекләр турында күзәтчеләр вожагына белгертә, яки ул эш хакында ячейкага җиткерә. Аның хәбәре буенча тикшерүләр һәм ашыгыч чаралар күрелә башлый. Кемнәр менә башлап шундый күзәтче булып язылырга телиләр?

Секретарь кулына карандаш алды:

— Мине яз!

— Мине!— дигән җавапларны көтмичә үк, башта үзен язып куйды. Аннан башка исемнәр тезелеп китте. Җиһан да язылды. Комсомоллардан башка союздан тыш яшьләр дә бу эшкә үзләре теләп язылдылар. Язылдылар гына түгел, ә менә хәзер кырга китәсе күзәтчеләрнең беренче отряды белән китәргә хәзер торганлыкларын белгерттеләр. Җыелыш бу сүзләрне алкышлап каршы алды.

Айлы төндә тирес төягән ун олау, алар артыннан җәяүләп алты кеше, беренче күзәтчеләр кырга атладылар.

III

Уңыш күзәтчеләре борчак участогына барып төшкәндә, термометр нәкъ 3 градус күрсәтә иде. Агач калып эченә куелган термометр агроном тарафыннан Җиһан кулына тапшырылган иде. Ул аны, сакчы мылтыгын ничек кадерле күрсә, шулай күрде.

Яңа гына башын калкыткан кыярсыман, әле кабыгын ташларга да өлгермәгән, яңа тишелгән борчакларның докторлары, аларны үлемнән саклап калырга, табигать белән үмәчкә-үмәч килеп көрәшергә уйлаган комсомоллар эшне тиз тоттылар. Җил астына олаудагы тирес бушатылды. Һәр ике тирес өеме саен кулына шырпы тоткан бер кеше билгеләнде.

Менә таң якынлашты. Таң алдыннан салкын тагын да көчәйде. Төн тагын да суынды. Нәкъ менә шул вакытта Җиһанның командасы яңгырады:

128 биткә

— 4 кә житте!

Шушы җөмлә нәрсә эшләргә кирәклекне барына да аңлатты. Бердәм ашыгып шырпылар сызылды, бердәм ут ялкыны күтәрелде. Борчак участогы буендагы тиресләр пыскып янарга тотындылар. Әкрен генә искән таң җиле төтенне борчак участогына куды һәм Ташлыярга таба алып китте. Туңарга әзерләнгән борчаклар төтен җылысы белән бераз сулыш алдылар.

Җиһан әнә шушындый салкын бер төнне кырда уздырды. Участок буенча термометр селкеп йөреп, нишләргә белми торган Җиһан, комсомол Шәриф күзенә: бер караганда, шакылдавыгын тоткан төнге каравылчы кебек тә, икенче караганда, караңгы төндә юл тапмый адашкан бер кыз булып та күренде. Сызылган таң яктысында күзләргә йокы төшсә дә, алар йомылмадылар. Колаклар һаман-һаман:

— 4 кә житте!— дигән команданы көтеп кенә тордылар.

IV

Иртәгесен кояш югары күтәрелгәч, уңыш күзәтчеләре шатланып Ташлыярга кайттылар.

Җиһан кайтып кергәндә, Бәдерниса карчык торып кына килә иде әле. Ишек ачылуга ул артына әйләнеп карады. Караса: елмайган йөзле, өстенә фуфайка, башына ак бәрән шәл бөркәнгән Җиһаны басып тора иде. Ул нишләргә белмичә бер-ике минут сүзсез калды. Аннан үрдәк адымнары белән кызына таба атлады. Ләкин җитез кыз үзе анасының кочагына атылды. Алар бер-берсен күптән, бик күптән күрмәгән төсле кочаклаништылар. Кызның ак бәрән шәле читеннән чыккан чәч бөртекләрен карчык үзенең хәлсез куллары белән сыйпады. Аның җыерчыклы бите буенча аналарча сөю уты белән януына шаһит булган кайнар яшь бөртекләре йөгерделәр. Ул көчкә генә:

— Кайда кундың, бәбкәм?— дия алды.

Җиһан ашыкмады. Җавап биргәнче, кулындагы термометрны өстәлгә куйды. Аннан соң гына:

— Кырда кундык, әни, кырда...— дип куйды.

Карчык аптырап кызының сүзләрен үк кабатлый язды:

— Кырда кундык... Ул ниткән сүз. Шушындый салкындамы?

— Әйе, салкын белән көрәшеп...

Алар кочакланышкан килеш, сәкегә барып утырдылар. Җиһан шуннан, шатланган йөрәк белән эшне сөйләп китте.

Карчык та кызына үзенең йөрәген ачты: «Игеннәр бу салкында өшерләр инде»,— дип төн буе йокламыйча капка төбенә чыгып йөрүләрен, борынына кереп йөдәткән төтенне дә кызга сөйләде: «Мөгаен, сезнең төтен булгандыр әле ул»,— дип, төтеннең хуҗасын тапты. Аннан гына үпкәләгән тавыш белән:

— Җә инде, киткән чакта, шунда бер минутка булса да өйгә туктап бишмәт-фәлән алган булсаң, өйгә кереп кая китәсеңне миңа әйтсәң, ни булган булыр иде инде.

Җиһан җиңел генә итеп:

— Әнкәй, андый чакта минуты да кадерле була бит,— дип куйды.

— Борынгылар белми әйтмәгәндер шул: «Ана күңеле балада, бала күңеле далада», и таки бу сүз дөрес икән,— диде.

1933

ҚАДЫЙР БИКМУРЗИННЫҢ ҖИНАЯТЕ

ЗАВОД ГУДОГЫ

Язгы көннәрнең һавасы сулышны иркенәйтә. Язгы аяз көннәрнең кояшы матур була. Кыш буе сагынылган ул кояшны тереклек дөньясы елмаеп каршылый. Кояш та, шуны сизгәнсыман, үзенең якты нурларын, чәчү тубалыннан ыргытылган гәрәбә орлыклар кебек, җир өстенә сибә.

Агачларның ботаклары бөреләнә башлыйлар. Шул бөреләрдән, шомырт чәчәге иседәй, хуш ис бөркелә. Шундый матур язгы көннәрдә яшәгән саен яшисе, алдагы киләчәк матур язларны күрәсе килә. Чөнки бу язгы матур көннәрдә барлык тереклек дөньясында хәрәкәт башлана.

Шундый язгы көннәрнең берсендә, язу машиналары эзерли торган заводның гудогы, сузып-сузып кычкырып, смена беткәнлекне белдерде. Заводның кызыл кирпеч стеналары капкасыннан эш киеме, блузалар, кепкалар, шәлләр, бүрекләр кигән эшчеләр чыга башладылар.

Ишек төбендә торучы яшел күлмәкле, сары мыеклы сакчы бүген көндәгегә караганда да ачулы күренде. Завод бусагасын атлаган һәрбер кешене үзенең үткен карашы аша үткәрде. Һәрбер эшченең, һәрбер өйрәнчекнең күзләренә үзенең соргылт күзләренең үткен карашын кире кайтармас кебек итеп кадады.

Завод ишеге янындагы контроль будкасы аша чыгучы

эшчеләр төркеме эчендәге бер малайны бүген бигрәк тә нык тентеләр. Сары мыеклы сакчы малайның барлык кесәләрен капшап чыкты. Малай инде китәм дип кенә атлаган иде, тагын ул аны туктатты:

— Я әле, яшь егет, итекләреңне салып җибәр әле.

Малай: «Алар аякны бик кысалар, нәрсәгә газаплыйсыз, барыбер бернәрсә дә юк»,— дип, күн итекләрен салмаска да уйлаган иде, ләкин сакчы каты торды:

— Безне хөкүмәт милкен сакларга куйганнар икән, без синең аягың авырту белән хисаплашмыйбыз. Синең аякны салдырмасак, бәлки хөкүмәтнең җилкәсе авыртыр!— диде.

Әле күптән түгел генә заводка эшкә кергән Садыйк абыйга бу җитә калды. Ул сакчыга таба борылып:

— Хөкүмәт түзәр әле, аның җилкәсе калын, баланы юкка газаплыйсыз,— дип куйды.

Башка эшчеләр шунда ук аңа каршы төштеләр:

— Юк, энекәш, шалишь! Хөкүмәт кем соң ул! Ул бит менә без барыбыз да.

Малай никадәр генә зарланмасын, сызланмасын, карышып барыбер эш чыгара алмады. Ул кызарган йөз белән, ояла-ояла, итеген салды. Киндер чолгаулар арасыннан тык-тык тавыш чыгарып, цемент идәнгә корыч метчиклар, пружиналар коелдылар. Аларны сакчы җыя барды. Аннан соң яшел козыреклы кепкасы астыннан малайга таба күтәрелеп карады да җирәнгеч бер көлү белән:

— Балтырыңа ул кадәр метчиклар, пружиналар төягәч, аягың авыртыр да шул,— дип куйды.

Кайсысыдыр ямьсез итеп сүгенеп алды. Кемдер шаркылдап көлде. Кемдер яшь кенә малайны бу эше өчен кызганды: «Эх!»— дип авыр сулады. Ләкин малай аларның берсен дә аермачык ишетә алмады. Ул, багана булып каткан хәлдә, берни белмичә, сары мыеклы сакчы каршында басып тора иде.

АНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ

Кадыйр матур гына булып ФЗУда укып килә иде.

Үсеп зур булырга, зур кеше булып, халык бәхете өчен үзенең бөтен иҗат көчен бирергә — ул менә шундый теләкләр белән янды. Шундый матур уйлар аның саф башында уйнадылар. Менә тизрәк-тизрәк зур үсәсе иде дә зурлар татыган авырлыкларны, шатлыкларны татыйсы иде. Күңел, чаптар ат кебек, алга ашкынды.

Ул туган елны, сыйнфый көрәш бугазга-бугаз, үмәчкә-үмәч килеп тартышкан елны, кан елгалары яңгыр сулары белән бергә акты. Ул туган елны ил өстендә ирек кояшы балкыды. Ул елны елап-сыкрап төннәр уздыручы аналар, ач-ялангач балалар белән җир өсте капланган иде. Заводлар-фабрикалар бертуктамый үкергән пушкаларның снарядларыннан пыр тузып җимерелеп беттеләр. Ул елны корыч ленталар кебек сузылган юллар буенча паровозлар да йөгермәделәр. Завод-фабрикаларның морҗалары төтен чыгармадылар. Кырларның күп өлешенә сабан кермәде ул елны.

Менә шундый елларны Сафия апаның баласы туды.

Сафия апа ябык йөзле, эшли-эшли бөкрәеп беткән бер авыл хатыны иде. Сызганып байга урак урыр чакта, баланың вакытсыз тууы аңа бик ошап бетмәде. Кендек әбие дә тиргәнә-тиргәнә генә: «Яман сыер ярда бозаулый»,— дип сукрана-сукрана Сафияләргә килде. Мулла да җимерелеп бара торган өйгә теләр-теләмәс кенә килеп балага Габделкадыйр исемен биреп китте. Бәдига карчык, Сафия апаның актык тавыгын кунакчасыннан тотып алды да мулланың суынып җитмәгән эзләре буенча сәдакага илтергә кушты.

Баланың тууын атасы гына күрә алмады. Герман сугышыннан яраланып кайткан атаны аклар отряды тагын сугыш кырына алып китте. «Кухня буенда бәрәңге арчырга булса да ярарсың әле»,— дип, мескен атаны ярлылардан оешкан Кызыл Армиягә каршы сугышырга

куштылар. Ул, башын түбән игән килеш, бик төшенке, бик моңлы күңел белән авылны калдырды. Ул вакытта Сафия апа, үзенең авырлы булуына карамастан, кыр капкасына кадәр, елый-елый хәле бетеп егылып калганчыга кадәр аны озата барды. Атаның бер-ике хаты килде дә, аннан ул бөтенләйгә каядыр югалды.

Ана: «Син генә кирәк идең»,— дигән шикелле, бала йөзенә карап, аны ертык чүпрәк-чапракларга төрә-төрә бик күп уйлар уйлады. Өйдә телгә алырлык, бер умачлык, дип елап сорасаң да он заты юк. Йорт тирәсе читәннәре күптән ягылып беттеләр. Бер аш кайнатырлык, менә шушы сабыйны юарга су елытырлык та утын юк.

Ә шул авылда ук яхшы яшәүче кешеләр бар. Аларның гаиләләрендә тигезлек, өс-башлары бөтен, тамаклары тук, алар рәхәт яшиләр... Ана, баласын күкрәгенә кыса-кыса, бертуктаусыз күз яшьләре коя. «Төкерәм мин ул бирәшнәрнең яшәүләренә, бар да күз яше, бар да кеше хакы. Алла тотар әле үзләрен»,— ди ул.

Кадыйр үзе болай яңгырлы елда да туган иде. Ләкин картлар аның кечкенә буйлылыгыннан: «Кадыйр, син туган елны яңгыр булмаган, ахры»,— дип көлделәр. Кайсылары: «Бүректә үстеңме әллә?»— дип сорау да биргәләделәр.

Ләкин алар Кадыйр үскән шартларны, аның күргән җәфаларын берсен дә искә алмадылар. Ә бала күпне күрде. Революциянең кабынган вакытында туган бала, тормыш өермәләре, көнкүреш газаплары аркылы менә бүгенге көнгә килеп җитте. Яхшылап тиресләнгән дымлы җиргә төшкән таза орлык кебек, бүгенге иркен шартларны татый алды. Соңгы таяныч — анасы да ачлыктан үлгәч, ул җылы ана кочагыннан урамга ташланды. Таш урамнар буенда тәрбиясез бала булып йөрде. Аннан балалар йортына эләкте. Иң соңыннан гына әнә бу язу машиналары ясый торган заводка өйрәнчек булып эшкә керде. Ә бүген исә ул метчик, пружиналар урлап тотылды.

Әйтергәме, әйтмәскәме?

Кадыйрны ябылган җиреннән икенче көнне үк чыгарып җибәрделәр. «Ярый, егет, иптәшләр судына кадәр чыгып тор»,— диделәр аңа.

Димәк әле иптәшләр суды булачак. Нинди-нинди куркыныч эш. Элек яхшы малай булып танылган Кадыйр иптәшләре алдына карак булып басачак.

Менә зал. Шыгрым тулы халык. Монда кечкенә Кадыйр Бикмурзинга суд бара. Менә алдынгы сафта ук Кадыйрның иптәшләре утыралар. Алгы рәттә үк гомер буенча бергә балалар йортында йөргән Васька утыра. Күрәсезме, ул үзенең ачулы күзләре белән ничек итеп Кадыйрга карый...

«Социалистик милеккә кул сузучы кечкенә карак Бикмурзинга...» Гаепләү акты шулай башланыр инде...

Кадыйр урам буйлап кайта-кайта әнә шул уйларны уйлый. Аның йөрәгендә шундый бер үкенү көче кузгалган. Ул аны сүзләр белән әйтеп бирә алмас кебек сизә: «Барыбер инде аңа иптәшләре элеккегечә ышаначак түгелләр. Барысы да аны чит итеп күрәчәкләр. Чөнки ул карак. Чөнки ул кеп-кечкенә башы белән эшче мәнфәгатен[1] саткан кеше. Чөнки ул үз милкен үзе урлаучы, иң соңгы кабахәт кеше! Ничек иптәшләр йөзенә күренергә?»

Көн инде кичкә авышкан иде. Баганаларда электр лампалары кабынды. Урам чатындагы репродуктордан моңлы җыр тавышы ишетелде. Кадыйрның йөрәге әрнегәннән-әрни барды.

Кадыйр чатта трамвай көтүче халык төркеменә якынлашты. Трамвайлар бер-бер артлы тезелеп киткәннәр, һавада сузылган чыбык өзелгән. Кадыйрның кызарган йөзен яктыртып, караңгылык эченнән менә шул кешеләр күзенә үзен күрсәтеп янган утларга, җырлаучы радиога, трамвай көтеп торган халыкка Кадыйрның ачуы килде.

---

[1] *Мәнфәгать* — интерес.

Алар барысы да бергәләшеп Кадыйрдан көләләр кебек тоелды.

Менә, трамвайлар кызу итеп кузгалып киткәч, шуларның берсе астына ташланса, Кадыйр барысыннан да котылам дип уйлады. Аяклар экрен-экрен шул якка таба атлый башлаганнар иде, ләкин ул кинәт туктады:

— Мин гаепләме соң?..

Ул үзен бу эшкә котыртучы Садыйк турында уйлап алды.

— Әйтергәме, әллә әйтмәскәме?

САДЫЙК АБЗЫЙ КЕМ СОҢ УЛ?

Завод гөрли.

Станоклар хәрәкәттә. Фрезер станоклары үзләренең үткен тешләре белән тимерләрне кырып, кирәкле хәлгә китерәләр. Сверильный станоклар бертуктамыйча әйләнәләр. Шул барлык станокларның берьюлы әйләнүләреннән завод эчендә бер тавыш туа. Бу хезмәт музыкасы. Ул тәрәзәләр аша урамга сибелә. Эшчеләр бар да башларын күтәрмичә эшлиләр.

Кинәт нидер шартлады. Садыйк кырма сакал баскан йөзен шартлаган якка таба борды:

— Ни булды?

— Берни юк, метчик кына сынды.

— Карап эшләргә кирәк, егетләр...

— Садыйк абый, яңа метчиклар бармы?

— Әйе, юк шул, акыллым, ясаганнар әлегә беткән, шунда ничек булса да рәтләп тор инде...

— Урлап бетерәләр дә, аннан коры кул белән эшлә!— дип куйды берсе.

— Тиздән, егетләр, метчикларны ясап өлгертәләр инде, заказ биргәннәр икән. Аңа бит особый корыч кирәк, без аны үзебез дә әүмәкләр идек шунда...

Садыйк өйрәнчекләрне шулай юатты.

Садыйк абый кул астында берничә өйрәнчек эшли.

Ул үзе бишенче разрядлы слесарь. Ул моннан элек кайдадыр пароходлар ясый торган заводта эшләгән, ди. Ләкин аннан нигәдер күчеп менә монда килгән. Мастер ничә айлар инде Садыйк абый хакында мыгырдап йөри: «Үзе бишенче разрядлы, ә гади детальләрне дә эшли алмый, адәм имгәге!» — ди. Әллә Садыйк абый картаеп эшли алмый инде, алай дисәң, әле ул бик карт та түгел. Булса бер утызлар тирәсендә булыр. Шулай да дөньяны күргән кеше инде. Аның аяк басмаган җире калмаган: ул Кырымда булган, Кавказда торган, Баку аша узган, Тифлис портында эшләгән, Архангельски ягында урман эшендә йөргән, ачлык елны Ташкентта үткәргән. Советлар илен буйлаган да, аркылылаган да кеше инде ул безнең Садыйк абый...

Кайвакыт шулай сүз ара сүз чыга. Төшке аш вакытында тәмәке тарта-тарта үзенең башыннанниләр үткәнен яшьләргә сөйләргә тотына:

— Сез яшь әле, борын астыгыз кипмәгән әле сезнең,— ди.— Менә сез бу дөньяга чыгып карагыз. Болай гына тормышны белеп булмый, булмый ул җанкисәкләрем...

Карчыга борынлы, яңак сөякләре калкулы йөзле, кырма сакаллы Садыйк шулай күп сөйләнә иде.

СЕКРЕТАРЬ ЯНЫНДА

Кадыйр элеккечә ук үз эшен эшли бирде.

Иптәшләренең аңа булган карашлары да үзгәрмәгән кебек тоелды. Ләкин күңелдәге җәрәхәт һаман әрнеде. Аның күңеле һаман-һаман сыкранды:

«Тиздәнме инде иптәшләр суды булачак?» Аның булуын Кадыйр зарыгып көтте. Ул төшләрендә дә шул ук суд белән җәфаланып бетте. Иптәшләр судына үзенең йөрәктәге барлык нәрсәләрен ачып салырга, ә менә болай һаман сер саклап йөрергә теләмәде. Ул берничә мәртәбә заводның партия җитәкчесенә барып ул турыда әй-

тергә дә уйлады. Ләкин нигәдер курыкты. Ничә тапкырлар бусага төбеннән кире борылды.

Беркөнне эшчеләр төшке ашка туктагач, комсомол ячейкасы секретаре Кадыйрны үз бүлмәсенә чакырып алды. Кадыйрга үзе утыра торган урындыкны бирде. Ә Кадыйр секретарьдан тиргәү җөмләләрен көтеп торды: «Менә хәзер һич күзне дә ачырмас, сөйләргә дә ирек бирмәс. Әх, тиргәр, әх, тиргәр!»— дип уйлады ул. Ләкин секретарь Кадыйр көткәнчә усал булып чыкмады. Ул сүзне метчиклар, пружиналар тирәсенә бик сак китерде:

— Я, нихәлләр бар, эшләп буламы?— Секретарьның беренче сүзләре шул булды.

Кадыйр батырлана төште һәм кинәт:

— Фатыйх абый!— дип куйды.

Секретарь бер дә исе китмәгәндәй:

— Сөйлә, туган!— дип, Кадыйрның сөйләвен көтте.

— Мин сезне яратам Фатыйх абый. Мин сезнең миннән нәрсә сөйләтергә уйлаганыгызны да беләм. Әйе, беләм. Сез метчиклар турында сорарга телисез...

— Әйе, мин бу тарихны ишеткән идем инде. Ләкин аның дөреслеген тикшерәсем килә. Хәер, ул кадәр кызыксынмыйм да.— Секретарь кулы белән хәрәкәт ясап, үзенең чыннан да ул вакыйга белән кызыксынмаганлыгын күрсәтергә тырышты.

Ләкин Кадыйр туктамады:

— Юк, сез кызыксынасыз. Мин аны сезгә тулысы белән ачып бирергә тиешмен... Мин шул вакыйга булганнан бирле бөтенләй ярты кеше. Аңлыйсызмы, Фатыйх абый, ярты кеше мин!.. Минем көчем дә юк, шатлыгым да...— Ул бераз туктап тын алды.— Беләсеңме, ул көннән алып мин күп уйлар уйладым. Үзем белми торган никадәр яңа әйберләрнең серенә төшендем. Ләкин хәзергә кадәр минем сездән яшергән бер генә нәрсәм бар иде. Мин сезгә бүген барысын да әйтәм. Моны әйтергә минем йөрәгем куша, мин эшче сыйныфына хыянәтче булып кала алмыйм...

Секретарь үзенең кызыксынганын белгертеп якын ук килеп тыңларга кереште.

— Мине бу эшкә Садыйк абый котыртты. Урларга миңа ул кушты, ирексезләп кушты,— диде Кадыйр.

— Садыйк?— дип гаҗәпләнеп кабат сорады секретарь.

— Әйе, ул кушты!— диде Кадыйр ышаныч белән һәм түзә алмыйча кычкырып елап җибәрде.

...Кадыйрның секретарь бүлмәсеннән елап шешенгән күзләре белән чыгуын күрүчеләр: «Малайны шәп пешергәннәр булырга кирәк»,— дип уйладылар.

Шул көннән башлап Кадыйр ачыла барды. Әз-мәз көлгәли дә башлады. Кайгыру, уңайсызлану баскан яшь егетнең күңелендә кояш чыккан кебек булды.

Завод һаман гөрләде.

* * *

Мине язу машиналары эшли торган заводның Вахитов исемендәге пионерлар отрядына вожатый итеп күчерделәр. Мин бу эшкә шатланып риза булдым. Берничә атналар эшләгәч, мин, кайбер пионерларны фамилияләре белән үк белә башладым. Безнең отрядта иң карт пионер булып Кадыйр Бикмурзин санала иде. Мин карап торам да болай һәр эштә актив булып эшли, тырыш кына кебек тә күренә. Ләкин бер генә нәрсә мине гаҗәпләндерде: аны нигәдер һаман комсомолга алмыйлар иде. Мин беркөнне, җаен китереп, Бикмурзиннан бу хакта сораштым:

— Кадыйр, сиңа ничә яшь?

— Мин абый 17 нче елны туганмын. Октябрь революциясе белән яшьтәш,— дип җавап кайтарды ул.

— Ә нигә соң сине һаман комсомолга алмыйлар?

Ул башта оялыбрак:

— Белмим, нигәдер алмыйлар,— дип куйды.

Мин бик ныклап сораша башлагач, әлеге югарыда

язылган метчик-пружиналар вакыйгасын сөйләп китте. Мин бу материал белән бик кызыксындым: «Хикәя итеп язарга бик әйбәт нәрсә икән»,— дип уйладым да, ул вакыйганы Кадыйрдан баштанаяк сөйләтеп чыктым.

— Ә синең Садыйк абый дигәнең заводта әле дә эшлиме?— дип сорадым мин, чөнки Садыйкның соңгы көннәре минем хикәяне укучылар өчен бик кирәк иде.

Ул башта көлеп җибәрде, аннан гына:

— Аның кулга алынганына хәзер биш ай була бугай инде,— дип куйды. Аннан кызып:— Ул бер эт, кулак булган икән. Раскулачивать ителгәч, Ташкент ягына киткән. Анда ниндидер бер кышлак рәисенә акча төртеп язулар ясаткан булган. Болар барысы да суд вакытында ачылдылар.

Хикәям язылып беткәч, мин аны Кадыйрга укып чыктым. Хикәя Кадыйрга, әллә үз тормышы язылган булганга инде, бик ошады. Ул үзенең кечкенә буе белән чүмәшеп, дикъкать белән хикәяне тыңлап утырды. Хикәянең азагына җиткәч, аның күзләренә яшьләр килде. Хикәя аңар бик ошады, ләкин сезгә ошар микән соң?

1933

———

КАДЕРЛЕ БҮЛӘК

Без сөйли торган вакыйга балалар йортында, аның яңарак оешкан көннәренең берсендә булды.

Иртәнге аштан соң балалар залга җыелдылар. Үзара шаярыштылар, зал гөр килеп торды.

Бераздан залда Шакир күренде. Ул башына малахай бүреген, өстенә бумази бишмәтен кигән иде. Балалар барысы да аның аягына карадылар. Аның аягында да, башкаларныкы кебек үк, брезент чүвәк иде. Менә Шакир алгы бүлмәгә үтте. Ул аннан астына салынган, башлары кәкрәйгән, кыска балтырлы киез итек күтәреп чыкты. Зал уртасында тукталды, акрын гына итеп, рәхәтен татыгансыман, бик озак итеп аны киде. Башка балалар борыннарын тартырга да онытып, күзләрен елтыратып, Шакирга карап тордылар. Карамаслык та түгел шул. Шакир бүген балалар йортындагы бердәнбер киез итекне киеп уйнарга чыга. Шакир нинди бәхетле: ул бүген рәхәтләнеп чаңгыда шуачак. Ә башкалар, песи балалары шикелле, беркая чыкмыйча өйдә генә утырып калачаклар. Чыгарлар иде шул, Кыш бабай бик яман куыра, брезент чүвәкләр белән бик тиз өйгә куып кертә, «киез итек киеп чыгыгыз» ди. Апалары да чыгармый, салкын тияр, ди.

Менә инде Шакир киенеп тә бетерде. Тирә-яктагыларга да исе китмәгән кыяфәт белән зур-зур атлап, өйалдына чыкты.

Өй алдында чаналар, чаңгылар, конькилар өелеп ята иде. Ул, дөбер-шатыр китереп, шулар арасыннан шома

гына бер чаңгыны сайлап алды да, урамга чыкты. Өйдәге балалар тәрәзәгә каткан бозны шул арада инде сулышлары белән шактый эретеп тә өлгергәннәр иде.

Шакир, аларның карап торуларын күргәч, кызу-кызу шуып китте, һәм ара-тирә аларга таба борылып карап та алгалады.

Килгән мәлгә ул таудан бертуктамый биш-алты мәртәбә шугач, үзендә ниндидер бер талчыгу сизде. Һәм якягына каранды. Тау буенда берәү дә юк иде. Менә шушы ялгызлык Шакирның күңелен боектырды. Тилмерешеп өйдә калган иптәшләрен үзе белән бергә тау буенда күрәсе килде аның. Хәзер инде ул тауга да баягы кебек йөгерә-йөгерә менми, атлар-атламас кына күтәрелә, иптәшләрен көткәнсыман, як-ягына карана иде.

Кинәт ул ерактан үз атларының юртып килүен күрде. Артлы чанага әйберләр төягән, толып кигән зав абыйлары шулар өстенә менеп яткан.

Шакир үз күзләренә үзе ышанмады. Чаңгыларын ике кулына тоткан килеш бераз вакыт шаккатып басып торды һәм аннары, чаңгыларын теләсә кай җирләреннән өстерәп, бар көченә өйгә таба йөгерде.

Чаңгыларны ишек алдында калдырып, өйгә атылып керде дә үзен-үзе белештермичә:

— Малайлар! Кызлар!— дип кычкырды, артык бер сүз дә әйтә алмыйча, ишекне каты итеп ябып тагын өйалдына чыгып китте.

— Ни бар соң? Ни бар?— дип бер-ике зуррак малай өйалдына чыгып, аны карап кермәкчеләр иде, ишектән дулап яңадан өйгә керүче Шакир аларны бәреп ега язды. Алар артка чигенделәр. Малайларның: «Ни бар? Шакир, ни бар?» —дигән сорауларына да җавап бирмичә, Шакир:

— Мәгез, киегез итекне, мәгез!— дип, аларны салырга ук тотынды.

Малайлар аны юри шулай юләрләнгән булып шаярта дип уйладылар, тик тордылар, ә соңгарак киез итекнең сыңары саен өчәр-дүртәр малай ябышты.

— Шакир арты чират минеке!

— Минеке!

— Биш минутка гына, хәзер әйләнеп керәм,— дигән тавышлар ишетелде. Шау-шуга тәрбияче апалары килеп җитте.

Тартышулар кызып, сугышка әйләнер дигән чакта гына Шакир:

— Әй, юләрләр, юкка талашасыз, зав абый бер олау киез итек алып кайтты!— дип кычкырды.

Шау-шу шунда ук тынды. Бар да аптырашып калдылар. Шакир сүзенә ышанырга да, ышанмаска да белмиләр иде.

Шул вакыт ишектә бер кочак киез итекләр күтәреп завхоз Иван Петрович күренде. Балалар төрлесе-төрле шатлык тавышы чыгарып, киез итекләрне сырып алдылар.

Яңа киез итекләр турында шатлыклы хәбәр ишетелгәч, иске киез итекне барысы да ташлап киттеләр.

Кочак-кочак киез итек алып кергән саен балалар йортында шатлык арта барды.

Йөрәкләрдәге:

— Барыбызга да җитәр микән?— дигән яшерен икеләнү дә югалды.

Шатлыктан ни эшләргә белми торган балалар һәрберсе үзенә киез итек сайлый башладылар. Тәрбияче апалары аларны бу эштән бик тиз туктатты.

Өйалдында нидер дөбердәп ишелеп төште. Чаңгыларның, чаналарның, конькиларның шәпләрен сайлап алырга чыккан малайлар анда да үз эшләрен шулай тизрәк бетерергә ашыгалар иде.

— Салкын тия, керегез, балалар!— дип аларны да бик тиз чакырып керттеләр.

Менә балаларны залга җыйдылар. Балалар йорты мөдире сөйләп китте:

— Балалар! Хәл кискен. Күп нәрсәләр җитешми. Безнең пальтоларыбыз юк иде, ул булды. Киез итекләребез юк иде, менә хәзер алар да булды. Бу киез итекләр, бала-

лар, безнең өчен кадерле бүләк, аларны юлбашчыбыз Ленин бабай җибәргән. Ул балаларны бар кешегә караганда да артык ярата. Без аңа хәлебезне аңлатып хат язган идек. Рәхмәт Ленин бабайга.

Балалар көчле итеп кул чаптылар.

Менә зав абый исемлек буенча кычкыра башлады.

— Абдуллин Шакир!

— Монда, монда!— дип, балаларны ера-ера, Шакир өстәл янына ашыкты.

Ә үзе әлеге кәкрәеп беткән киез итекләрне, бик авыр нәрсә китереп куйган шикелле, куйды да:

— Моны инде, абый, чыгарып ташлыйсы гына калган,— диде. Аның бу сүзеннән бар да шаркылдап көлеп җибәрделәр.

Шакирга кап-кара, шоп-шома киез итек бирделәр.

Ул, бу кадерле бүләкне кочаклап торган килеш елмаеп, залның бер кырыена барды һәм стенада көлемсерәп торган Ленин рәсеменә карый-карый яңа киез итекләрне киде.

Шакирның аягы рәхәтләнеп китте. Ул бозлы тәрәзәгә күз салды. Аның өчен хәзер бертөрле салкын да куркынычлы түгел иде инде.

БЕРЛИН

Бертуктамый зырлап әйләнеп торган пропеллер кинәт тынды. Аэроплан ниндидер зур шәһәр читендәге аэродромга килеп төште.

Аэропланнан күн кием кигән кешеләр чыктылар. Күн перчатка кигән кешенең берсе юлчылар утыра торган кабинаны ачты да:

— Рәхим итеп төшегез, кунаклар, Германиянең башкаласы Берлин шәһәренә килеп җиттек,— диде.

Берлин сүзе Гәрәйне кинәт сискәндереп җибәрде. Ул янында торган чемоданын алды да аэропланнан төште.

Аэродром бик зур иде. Аэродромның тирәсен тимер рәшәткә белән әйләндереп алганнар. Рәшәткә буендагы акациягә ошаган бер агач сап-сары булып чәчәк атып утыра. Агачның бер дә яфраклары юк. Аның яфраксыз ботакларына шул сары чәчәкләр, авыл кызларының муенсалары кебек, тезелеп киткәннәр. Гәрәй гаҗәпләнеп агачка бик озак карап торды. Аннан гына капкага таба атлады.

Аэродром капкасына җитү белән, капка автомат рәвештә, үзеннән-үзе ачылды. Капка янында автомобильләр тезелгән иде. Гәрәй аларга утыруны кирәк санамады, ахры, көзге кебек ялтырап торган тротуардан җәяүләп алга атлады.

Тротуарда халык күп иде. Аннан ак якалы күлмәк, биек цилиндр, әллә нинди койрыклы киемнәр кигән зур корсаклы кешеләр уздылар. Гәрәй аларны буржуйлар

дип уйлады. Аннан өсләренә күк блузалар, башларына кепкалар кигән чандыр кешеләр, серле генә нидер сөйләшә-сөйләшә уздылар.

Ике урам чатында күн сумкалы бер малай газета сатып йөри. Малайның: «Иртәнге газета... яңа хәбәрләр... Рейхстагны яндыручылар тотылды»,— дигән сүзләре урам тавышына кушылып югала. Ашыгып узучылар жилетларының күкрәк кесәләрен карыйлар да, малайга көмеш акча сузалар. Аннан газетаны кулларына алып тагын ашыга башлыйлар.

Гәрәй дә газета сатучы малай янына килеп чыкты. Газета сатучы кечкенә Карл Гәрәйнең көзге пальтосы эченнән кызыл галстугына бармагы белән төртте дә: «Кызылыңны яшер, Берлинда кызылны яратмыйлар»,— диде. Гәрәй малайның сүзен аңламаса да, хәрәкәтеннән аңлады. Шуннан пальтосының якасын кайтарыбрак куйды.

Ничектер, алар сөйләшеп киттеләр. Сүз татарчамы, немецчамы булды, Гәрәй белмәде, ә шулай да алар берберсен аңлаштылар. Шуннан шактый вакыт үткәч, газета сатучы немец малае Гәрәйнең колагына иелеп әкрен генә нидер әйтте. Үзе сумкасын ипләде. Салынган газета-журналларны сумкасының эченәрәк яшерде. Алар урамның аргы башына таба ашыга-ашыга атлап киттеләр.

Юлда аларга муеннарына җеп белән картон аскан кешеләр очрады. Ул картоннарга нидер язылган иде. Гәрәй ашыгып барган Карлның җиң очыннан тартып:

— Ул кешенең картонына нәрсә дип язылган?— дип сорады.

— «Мин инженер Макс, нинди генә эш булса да, эшләргә риза!» — дип язылган.

Карл шуннан кызып сөйләп китте:

— Бездә андый эшсез кешеләр күп, минем әти дә элек Крупп дигән буржуйның пушкалар ясый торган заводында эшли иде. Коммунистлыкта гаепләнеп аны заводтан чыгардылар. Ул ничә айлар эшсез йөрде. Ә инде менә соңыннан, соңыннан...

Ул әйтеп тә бетермәде, киң урамны тутырып соры күлмәк кигән, фашистлар значогы таккан бик күп кешеләр уза башлады. Гәрәй иелеп кенә сорады:

— Болар кемнәр соң?

— Болар — безнең дошманнарыбыз — фашистлар. Германиянең вакытлы хуҗалары. Ә киләчәктә Германия— халыклар Германиясе булырга тиеш. Әйе, Берлин — эшчеләр Берлины, безнең Берлин булырга тиеш.

Гәрәй дә эченнән генә шуны уйлады.

Гәрәй белән Карлга урам аркылы чыгарга кирәк. Ә фашист колонналары аларның бара торган юлын бүлеп, бертуктамый узып торалар. Гәрәй бара-бара да, тагын шул колонналарга борылып карый. Алар эчендә атлаучы фашистлар аңар котырган бүреләр төркеме булып күренәләр. Аларның кара байракларына адәм башының сөяге төшереп куелган. Бу — «Безгә каршы килүчеләргә үлем!» — дигән сүз. Ләкин алардан куркып тормыйлар. Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә, эшчеләр, фашистлар төзелешен җимерү өчен көчле көрәш алып баралар: эш ташлаулар, фашистларга каршы демонстрацияләр оештыралар. Килер бер көн: Германия эшчеләре, коралланган килеш, дошманнарга ут ачарлар, властьны үз кулларына алырлар,— Гәрәй әнә шулай уйлый.

Алар урам буйлап атлыйлар.

Менә бик зур йорт, анда күптән түгел пожар булганлыгы әллә каян беленеп тора.

Гәрәй Карлдан сорый:

— Бу нинди йорт?

— Шул инде фашистлар яндырган Рейхстаг йорты. Алар аны үзләре яндырдылар да коммунистларга сылтадылар. Хәзер менә шул эшне сылтау итеп коммунистларны, революцион эшчеләрне кулга алалар. Менә шушы эштән соң Германия Коммунистлар партиясе юлбашчысы, эшчеләрнең якын дусты Эрнст Тельманны һәм башка бик күпләрне кулга алдылар...

Гәрәй уйлады:

«Бит аларның «Тельман» исемендәге звенолары бар. Күптән түгел алар бу звенода Тельман иптәшнең кулга алынуы турындагы хәбәрне бик ачу белән укыдылар. МОПР файдасына һәр пионер 50 шәр тиен акча җыйды. Ә хәзер Гәрәй кайчандыр вожатый сөйләгән сүзне менә шушы немец эшчесе улы Карл авызыннан ишетә».

Урам чатлыгында саргайган йөзле кешеләр, киселгән аякларын, кулларын ялтыр шома асфальт өстенә чыгарып салганнар да, узучылардан ярдәм сорыйлар. Үткән һәм киләчәк сугышның дәһшәтен хезмәт халкының һәрвакыт исенә төшереп торган бу гарипләргә Берлин урамында икмәк тә юк, акча да юк, кунар урын да юк. Аларны урамнардан куалар. Аларга пособие бирүне бетерәләр. Пособие урынына пушкалар, сугыш самолетлары, сугыш кораблары ясыйлар.

Карл Гәрәйгә шулай сөйли:

— Менә безнең өйгә кайткач, немец эшчесенең һәм аның семьясының ничек торганлыгын үз күзең белән күрерсең. Без иске вагонны өй иттек тә шунда торабыз. Энем белән сеңелем менә мин кайтканны көтеп ач торалар. Ә мин күп көннәрне буш кайтам.

Карл сүзен дә сөйләп бетермәде, аның янына бер эшче килде дә, әкрен генә: «Синдә «Роте Фане»[1] юкмы?» — диде. Карл сакланып кына ниндидер газета чыгара. Шул вакытта ук чаттан соры кием кигән бер фашист чыгып Карлга ташлана. Гәрәй дә инде түзә алмый: аңар Карл кызганыч, аның Карл белән бергә төрмәгә барасы, буржуйларга каршы бергә сугышасы килә. Гәрәй фашистка ташлана. Кемдер аның җилкәсенә резин таяк белән нык кына итеп суга. Гәрәй егылып китә...

Кроватенда сискәнеп уянганын ул үзе дә сизми, шап итеп идәнгә килеп төшкәч тә әле, озак вакыт үзенең кайда ятуын аңламады. Бераз торгач кына идәнне капшап үзенең Берлин урамында түгел, бүлмәсе идәнендә ятканын

---

[1] Германия Коммунистлар партиясенең газетасы.

белде. Шуннан соң ул экрен генә торды да, уйлана башлады:

— Ул бит кич белән генә отряд сборыннан кайткан иде. Вожатый Германиядә булган хәлләр турында бик күп сөйләгән иде анда.

Җитмәсә отряд сборыннан соң алар «Фрес Вавер» дигән кинокартина караганнар иде. Әнә бая гына төшендә күргән Карл нәкъ кинодагы Фрес инде.

Ә Берлинга очу хыялы Гәрәйнең күптәнге хыялы инде ул. Осоавиахим лотерея билетларының һәр тиражы уйналган саен, Гәрәй почтага йөгерә. Һәр тиражы уйналган саен Гәрәйгә дөньяны очып әйләнү отышы чыгар төсле тоела. Тираж таблицасы басылган газета килгән саен, бүгенге Берлинны төшендә генә түгел, үз күзе белән күрер вакыт якыная кебек аңар.

1933

ЧУАР ТАВЫК

I

Безнең Җамал әбинең бер чуар тавыгы бар. Бер авылда да юк бу тавыкка пар. Чуар тавыкны тавык димәсәң, Җамал әбинең хәтере калып, бу сүзне улы Гата да күнеленә авыр алыр. Күгәрченнән кечкенә, сыерчыктан зур— чуар тавык әнә шундый ул.

Чуар тавык ул күпне күргән, ике-өч еллык гомерендә берничә оя чебеш тә үстергән. Ул да, Җамал әби төсле, үзенең якыннарына: «Әкренләп картаям инде»,— дигән, аның төсле үк итеп, башына бүрек тә кигән.

Ләкин Җамал әби җимне бик әз бирә. Чуар тавык кайда туры килсә, шунда тибенә, атнага бер-ике йомырка сала, күп вакыт кыртлап кына кала.

«Салгандыр»,— дип оясын капшыйлар, ләкин йомыркасын тапмыйлар.

II

«Ай күрде, кояш алды» дигәндәй, көннәрнең берендә, чуар тавык каядыр югалды. Эзләмәгән урынны калдырмадылар, бөтен дөньяны актардылар, һичкайдан да таба алмадылар.

Эзләп-эзләп тә тапмагач, ашарга да кайтмагач, Җамал әбинең инде өмете тәмам өзелгән иде, чуар тавыкны үлгәндер дигән иде. Ләкин бер дә көтмәгәндә, кайтыр дип

һич өмет итмәгәндә, чуар тавык кайдандыр үзе килеп чыкты.

Амбар алдында җим чүпләгән башка тавыклар арасында кыртлап йөрүче чуар тавык күренде. Җамал әби белән Гата аны күрделәр дә: «Чуар тавык утыра башлаган икән»,— диделәр. Гата тавыкны күзәтергә булды, шуның өчен ул бер почмакка посып торды.

Җим ашап туйгач, берничә тамчы су да эчеп куйгач, чуар тавык борынын бер-ике тапкыр җиргә ышкыды. Канатларын кагып, тузаннарын койды.

«Утыра торган йомыркаларым суынмасыннар, чәберчек булмасыннар»,— дип, оясына ашыкты чуар тавык.

Гата да йоклап тормады, поскан җиреннән чыкты да тавык артыннан атлады. Кетәклек башында, өрлек астында, салам куышында иде чуар тавыкның оясы. Оясына менеп җиткәч кенә, йомыркаларны җылытыйм дигәч кенә артка чигенде чуар тавык. Бөтен көченә чырлый башлады һәм, күп тә үтмичә, оясындагы дошманга ташланды. Һөҗүмгә түзә алмыйча, оядан нидер атылып чыкты, хәтта Гата да курыкты, арткарак чигенде, озак уйлап тормады, әнисенә йөгерде.

III

Әнисе белән икәүләп килделәр. Югары мenделәр. «Кара син аны, качкын тавык!» — диделәр, азрак тиргәделәр.

Чукуына исе китмәде, куркынмады, артка чигенмәде, Җамал әби чуар тавыкның канат астыннан тотып, югары күтәреп карады. Чуар тавык чырлады, тыпырчынып әбинең кулын чукыды. Гата да тик тормады, тавык астындагы йомыркаларны санады.

Җамал әбигә берьюлы ике шатлык туды: ярты дистә йомырка да булды, чуар тавык та табылды.

Гата йомыркаларга үрелде, берсен кулына алды һәм хәйранга калды, йомырка, ничектер, бик җиңел күренде, ныклабрак караса, коры кабык кына лабаса. Әйе, өч

йомырканың коры кабыгы гына калган, эчен нәрсәдер бик чиста итеп суырып алган.

Кем эше икәнне шунда ук сизенделәр, качып баручы соры песине күрделәр. «Бу — синең эш!» — диделәр. Шулай итеп, мәченең юлы уңмады, Җамал әби белән Гата очрады. Шуңа күрә ул койма тишегеннән аргы якка сикерде, башлаган эшен шулай бетерде: мыек буялмады, тамагы туймады, берни булмады.

Җамал әби чуар тавыкны кыртлавыннан биздерергә тотынды. Чуар тавыкның кайнар түшен суга тидерде. Тагын бер әмәл тапты, тавыкны сулы кычыткан белән чапты. Ләкин чуар тавык кыртлавыннан бизмәде. Һаман-һаман утырырга оя эзләде.

IV

Төрле юллар белән дә кыртлавыннан бизмәгәч, һаман утырырга йомырка эзләгәч, чуар тавыкны утыртырга булдылар.

Җамал әби йомырка сайларга утырды. Аның бу эшен Гата күрде:

— Ул йомыркаларны куырып ашарбыз, менә дигән эреләрен табарбыз. Күрше колхозның фермасына барырмын, нәселле тавыкларныкын алырмын,— диде.

Һәм шулай да итте. Җыенып фермага китте.

Ферма эче күркә хәтле зур-зур тавыклар белән тулган: ап-аклар, кып-кызыллар — кыткылдый-кыткылдый йомырка салалар.

Ферма мөдире Миргалим абзый Гатаны көлеп каршы алды, исәнлеген сорашкач, ферманы күрсәтә башлады:

— Менә бусы безнең тавыклар, алар шушы чиста тигәнәләрдән ашыйлар, үләнлеккә чыгып йөриләр, ояларына кереп йомырка салалар.

Миргалим абзый комод төсле бер әйбер янына туктады, үзе Гатага сорау бирә башлады:

— Сезнең чуар тавык ничә чебеш чыгара?

— Күп булса егермене,— ди Гата.

— Ә безнең тавык, туганкай Гата, берьюлы биш мең чебеш чыгара ала.

— Сездә чебешләрне җәй көне генә күреп була, ә безнең ферма кыш көне дә чебешләр белән тула. Безнең тавык менә нинди уңган, асрасаң, шундый тавык асра син, туган.

Бу сүзләрне тыңлаган Гата шакката:

— Ул нинди тавык, күрсәтегез зинһар табып,— дип ялынырга тотына.

Ә Миргалим абзый, мыек астыннан елмаеп, Гатага тавыкны күрсәтеп тора:

— Менә бу нәрсә комод түгел — инкубатор. Электр белән эшли торган чебеш анасы. Шушы тартмасына йомырка саласы. Электр лампалары тартма эчендәге һаваны җылыта, йомыркаларны һава җылытып тора.

— Ә йомыркалар ничек пешмиләр. Чебешләр ничек үлеп бетмиләр?— ди Гата.

— Бу машинаны уйлап табучы кеше бик башлы булган, ул да синең кебек төрлечә уйлаган. Артык кызуга китсә, бу лампочка үзеннән-үзе сүнә.

— Чебешләр чыккач, аларны башка җиргә күчерәбез, менә шулай итеп күп чебеш үстерәбез,— ди Миргалим абзый.

— Мин, Миргалим абзый, сиңа зур йомыш белән килдем, әнигә: «Без дә нәселле тавыклар асрыйк!» — дидем, ярдәм сорап сиңа килдем, Миргалим абзый кире какмас, дидем.

— Үрнәк күрсәтерлек эшкә тотынгансың, тырышырмын, кулымнан килгәнчә булышырмын,— ди Миргалим абзый.

Ферманы карап бетергәч, Гата җырлый-җырлый өенә кайта. Шатлыгыннан авызы ерыла, туктаусыз елмаеп тора. Кепкасындагы йомыркаларны әнисенә бирә, ферма хәлләрен сөйләп аны да сөендерә. «Ялгыш алып кайткансың, улым, кире илт, бар, каз йомыркалары ич болар?»—

ди Җамал әби. Гатага кызык, ул һаман көлә-көлә әнисенә сөйли: «Нәселле тавык йомыркасы шул ул!» — ди.

Җамал әби кычытканын да ташлады, чуар тавыкны суга да манчымый башлады, ящикка салам түшәп оя ясап бирде, йомыркаларны йомшакка тезеп куйды, чуар тавыкны сөендерде.

V

Икенче көнне Гата, сазга бата-бата, куып йөрде бака. Бакалар Гатадан хәйләкәррәк булдылар, ул килгәнне ишетүгә, берәм-берәм суга чумдылар. Шуңа күрә аларның берсен дә тота алмады, авызын ачып тик карап калды. Камышлыкка кача-кача, Гатаны үртәгән шикелле, кычкырды бака: «Ба-ка-ка-ка... Ба-ка-ка-ка».

Йөри торгач саз буйлап, төрле-төрле уй уйлап, Гатага йомыркалар очрады.

Саз эчендә кыяклы тумгак өстенә чыбык-чабыклар, йон-мамыклар өеп үрдәкләр оя ясаганнар. Шунда ана үрдәк йомырка салган. Бала чыгармакчы булган. «Нәни генә бәбкәләр үстерербез, җәйне рәхәтләнеп үткәрербез»,— дип уйлаганнар иде үрдәкләр.

Гата бу йомыркалар өчен бик сөенде, үз-үзенә: «Боларны алып кайтыйм мин»,— диде. Биш йомырканы да эшләпәсенә салды, маяга берәрсе калсын да димәде.

Гатаның уйлары бик озак сугыштылар: «Син табигать сөюче, файдалы кошларның тормышлары өчен көюче, аларга булышлык итүче, иркенлек бирүче, ни эшлисең син?» — диделәр. Гата бу уйларны тыңламады, үзенекен итте, үрдәкләрне кызганмады, йомыркаларның барысын да алып китте.

Үрдәкләр тирги-тирги баш очында очып әйләнделәр, җитмәсә башка кошлар да бәйләнделәр. Акчарлак:

«Кызганмадың, барын да алдың»,— диде. Тәкәрлек: «Син бик начар егет»,— диде. Ә Гатаның берсенә дә исе китмәде.

Акчарлак, акчарлак,
Акчаң булса миңа бир,
Тәкәрлек, тәкәрлек,
Тәңкәң булса, миңа бир,—

дип җырлый-җырлый өенә кайтып китте.

VI

Әллә ни булган төсле, Гата ишектән йөгереп керде дә эшләпәдәге йомыркаларны тизрәк әнисенә бирде:

— Менә, әни, нәрсәләр таптым, бер кызык эшләр өчен алып та кайттым,— диде.

Җамал әби башта аптырап калды. Соңыннан гына аңлап алды. Әй орышырга тотынды Гатаны:

— Хәзер үк кире илт, күземә күренмә, моннан соң бер кошның да йомыркасына үрелмә!

Гата аптырамады, җавапсыз калмады:

— Мин дә бит аларны уйнарга дип алмадым, берсен дә ватмадым, яхшы сакладым, бер тәҗрибә эшләргә уйладым,— диде.

Гата теләгенә бик тиз ирешмәде, Җамал әби тиз генә бирешмәде. Аңа бик озак ялынырга туры килде, Җамал әби бик авырлык белән генә күнде.

Чуар тавыктан бәбкә чыгартырга булдылар. Шул теләк белән үрдәк йомыркаларын да тавык оясына куйдылар.

VII

Өч атна дигәндә, йомыркалар борынладылар, берәмберәм чебешләр чыга башладылар. Өч-дүрт көн үткәч, бәбкәләр дә чыктылар, Җамал әби чыккан берсен җылы бүреккә җыя барды. Чебешләр унике булды, бәбкәләр белән унбишкә тулды. Бу чебешләр һич тә элеккегеләр кебек түгелләр, бик тереләр. Аларга караганда күп өлеш зурлар, мондыйларны кем хурлар!

Ике көн үткәч, чебешләр һәм бәбкәләр бары да чыгып беткәч, Җамал әби куптәнге уен эшкә ашырды. Чебешләр һәм бәбкәләрне чуар тавыкның үзенә тапшырды.

Гата да чебешләрне Җамал әби төсле үк сөйде. Аларның язмышы өчен көйде. Күп вакыт аның көне чебешләр янында үтте, ул аларны саклады, усал дошманнардан яклады, я су эчертте, я ярма сипте.

Ишек алдын бер итеп кыртлый чуар тавык, үзе чебешләре тирәли йөри чабып: «Пи-пи-пи, әни, бир ипи»,— диләр чебешләр. Әниләре чакыргач, йөгерешеп килделәр, җим эзләделәр, нәни тәпиләре белән тибенделәр, ямьяшел чирәмлеккә сибелделәр.

Кинәт, ала каргамы, кара каргамы күренде. Әйтерсең, ул берәр чебешне эләктерергә үрелде. Чуар тавык моны бик тиз сизенде, бик әче тавыш белән кыртлап җибәрде. Минут эчендә, әйтерсең, ут эчендә калдылар чебешләр. Кайсы кая качып беттеләр. Кайсылары әниләре канаты астына кереп киттеләр.

Ләкин карга тиз югалды, чөнки чуар тавык та сизенеп калды, җитмәсә Гата да кузгалды. Тиз генә кулына таш алды, һавага җибәрде, ташы әз генә каргага тимәде.

Беләсезме, ул карга түгел икән, ул булган тилгән, күрәсең, чебеш ите ашыйсы килгән, ах, үләт тигән!

Әнә, ничек кызарып байый кояш...

Яктылык сүнә, әзәя, караңгылык үзенең канатын җәя...

Чебешләре дә чәрелдиләр: «Йоклыйсыбыз килә, әни, йоклыйбыз!»— диләр. Чуар тавыкның канат астына тулалар, күзләрен йомалар, татлы йокыга чумалар.

VIII

Төн уртасы җиткәч, барлык шау-шу тынып беткәч, кош-корт йокыга киткәч, Җамал әбигә тагы эш чыкты.

Йоклый иде ул тәмле төш күреп, төшендә көмеш кебек чәчләрен бер сүтеп, бер үреп, нәкъ шул вакыт нидер чырлады, бу тавыш төнге тынлыкта тагын да куркынычрак булып яңгырады.

Галошын да эләктермәде, өстенә дә кимәде, Җамал әби ишек алдына атлады.

Ни күзе белән күрсен, ни җаны белән тузсен, чуар тавыкның чебешләре тузгыган. «Тукта әле, тукта, чебешләр нигә болай аз калган?» — ди Җамал әби.

Уидүрткә кадәр санады,
Барысын да барлады.
Ә унбишенчесе кая?
Югалган бит, бичара!

Йокысы йокы булмады, күзе йомылмады, йокы күрмәде, һаман чебеш урлаучы дошманны тиргәде: «Минем чебешемә тигән өчен муены астына килсен!»

Ләкин дошманның кем икәнен тиз сизделәр. Гата да усал, кайдандыр капкын алып кайтты, аңа ит кисәге куйды, ә үзе тыныч кына йокларга ятты. Чуар тавыкны да ишек алдында калдырмадылар, җыйнак кына оя ясадылар, чебеш һәм бәбкәләре белән шунда яба башладылар.

Иртәгесен Гата, чыгып капкынын караса, шакката, капкында авызын ачкан көзән ята...

IX

Чебешләр дә, бәбкәләр дә үсә башладылар, ишек алдында йөрүне генә ташладылар. Чуар тавык аларны урамга да алып чыгарга күнде, ләкин бу эшенә соңыннан бик үкенде, чөнки ул эш аңа зур кайгы китерде.

Яңгыр арты иде. Көн бик матур иде. Чебешләр капка астыннан урамга сибелделәр. Черкелдәп-черкелдәп җим эзләп тибенделәр.

Чуар тавык үзенең балаларына карап куанды. Аларның киләчәкләрен, зур үсәчәкләрен уйлап юанды.

Әнә, анда көмеш сулы күл ялтырап ята. «Ашап туючыларны сыйлыйм, татлы сулы мин»,— дигән төсле, бу күл безнең танышларны үзенә чакыра. Чебешләр йөгереп киләләр дә суны тамчылап кына эчә бирәләр.

Әнә, бәбкәләр дә килеп җиттеләр. Алар инде тамчылап кына эчеп тормадылар, шуптырдый-шуптырдый, күл эче-

нә кереп киттеләр. «Ничек боларның йөрәкләре житте!» — дип, яр кырыендагы чебешләрнең исләре китте. Бәбкәләр үзләре генә булса, бер хәл иде, ә әниләре — чуар тавыкны хур иттеләр. Ул да балаларыннан калышмаска теләде, күлгә якын килде, ләкин кермәде, бер-ике тамчы су чәчрәве чуар тавыкны куркытырга житте.

Бәбкәләр бер-берсенә: «Без дә яшәгәнбез, ләкин шушындый рәхәт барын белмәгәнбез!» — диештеләр. Куышып уйнадылар, уйнап-уйнап туймадылар. Чуар тавыкның: «Кайтабыз, каласыз, кузгалабыз, югаласыз»,— дип кыткылдавы да һич файда бирмәде. Бәбкәләр күлдә калдылар, әниләре чакырган саен эчкә керә бардылар.

Чуар тавык, чебешләрен генә ияртеп, аһ-ваһ итеп кайтып керде. Җамал әбигә: «Тыңламадылар, калдылар, котырдылар!» — дип сөйләп тә бирде. Үзенчә кыртлап күрсәтте, ә әби аңламады, кыртлауны тыңламады. «Көш тә көш!» — дип куып йөдәтте.

Бәбкәләрне күл буеннан Гата алып кайтты... Ул бу эшкә артык әһәмият бирмәде, аларны чебешләр белән бергә үк япты.

Шул көннән башлап бәбкәләр чуар тавыкны ана итмәделәр. Өчәүдән-өчәү күлгә йөри башладылар, чуар тавыкның канат астын һәм чебеш туганнарын мәңгегә ташладылар.

X

Көз якынлаша, бай көз. Сез шуны сизәмсез? Ашлык төягән арбалар шыгырдый, бертуктамый яңгыр шыбырдый. Ә кояш исенә төшсә генә бер карый, анысы да күңелгә ярый.

Чебешләр инде тавыктай зур булдылар, әниләреннән аерылдылар. Хәзер аның белән бергә дә йөрмиләр, канат астына да кермиләр. Колгага менеп кунаклыйлар да рәхәтләнеп йоклыйлар. Әтәч чебешләр таңны каршы алалар, шапылдатып канат кагалар, киерелеп-киерелеп кычкыралар, үзләренчә күңел ачкан булалар.

Бәбкәләр тәмам үрдәк булдылар, элеккечә һаман судан туймыйлар. Көне-төне күл буенда йөриләр, өйгә кайтып та кермиләр.

Их син, чуар тавык, бичара, балаларың белән үлчәшеп кара! Арагызда аерма бар күп кенә, алар янында син үзең хәзер чебеш күк кенә!

XI

Уңыш бәйрәмендә бик шәпләп сыйланырга, үрдәкләр суярга, шулпалы бәлешләр салырга уйлаганнар иде...

Матур уйларының, уңыш туйларының бу өлеше күңелсез булып бетте, эшләре шактый чуалып китте.

Мондый усал ниятне үрдәкләр ишеттеләр, җыелып киңәш иттеләр, котылу юлын эзләргә керештеләр.

Кайсы әйтә: «Суга чумарга кирәк»,— ди, кайсы: «Болында кунарга кирәк»,— ди.

Берсе әйтә: «Урманга качыйк»,— ди, икенчесе: «Ничек тә котылып калыйк»,— ди. «Очыйк!» — дип берсе дә әйтмәде, шуңа төшенергә башлары җитмәде.

Бары да үзенчә тырышкан була. Котылырга план корышкан була.

Йолдызлар чекрәеп карап торганда, күл өсте ай нуры белән тулганда, үрдәкләр шулай уйга чумганда, күктән бик җитез итеп канат җилпегән тавыш ишетелде. Кыр үрдәкләре очтылар: «Җылы якка әйдәгез, монда калсагыз, туңып үләрсез!» — дип кычкырып уздылар.

Муеннарын сузып, башларын кыңгыр салып, күлдәге үрдәкләр бу тавышны тыңладылар.

Бу тавыш күңелләрен уятты, «Безгә дә очарга кирәк!» — дигән теләкне кузгатты. Канатларын җилпеп күлдән күтәрелделәр, очып баручы кыр үрдәкләренә иярделәр.

Җамал әбинең моржалары турында өч мәртәбә әйләнделәр: «Безне кабат күрмәссез, хушыгыз инде!» — диделәр.

ЭШЧЕ АБЫЙ

Люция белән абыйсы бергәләп урамга чыгарга җыендылар. Һәр ял көне саен әтисе аны шулай йөртеп керә. Урамда Люциягә әллә нинди кызыклы нәрсәләр күрсәтә.

Люция бар нәрсәне дә белергә тырыша, һәрнәрсә белән дә кызыксына торган кыз. Аның бер белгән соравы бар:

«Кем ясаган да, кем ясаган?» Ул һәрвакыт шулай дип сорый. Бүген дә әле ул әнисе кулындагы киез итекләрне кия-кия әтисеннән сорады:

— Әти, киез итекләрне кем ясаган? — диде.

— Эшче абыең ясаган, кызым. Кадерле балаларның аяклары туңмасын дигән, — дип җавап бирде әтисе.

— Ә бүрекне кем ясаган?

— Эшче абыең теккән, кызым. Салкында балаларның колаклары өшемәсен дигән.

— Бияләйләрне дә ул ясаганмы, әти? — диде Люция.

— Әйе, бияләйләрне дә ул бәйләгән — балаларның куллары туңмасын дигән.

Менә алар урамга чыктылар. Люция бу вакыт һәрнәрсәне дә эшли белә торган эшче абый турында уйлый иде. Ул аның күз алдына өй хәтле бер зур кеше булып килеп басты. Ә шундый зур булса да ул нәниләрне бик ярата булса кирәк. Әнә бит ул бар нәрсәне дә балалар өчен эшли. Балалар да эшче абыйны ярата торганнардыр. Люция дә аны бик ярата.

Люция уйлапып барганда, чеңгел-чеңгел итеп, трамвай үтеп китте. Хәзергә кадәр эндәшми барган Люция:

— Трамвайны да ул ясаганмы?— дип куйды.

Әтисе әйтте:

— Әйе, трамвайны да эшче абыең ясаган, менә бу зур йортларны да ул салган, юлларны ул төзегән...

Шул вакыт язгы кояш болыт арасыннан чыгып үзенең якты нурларын сибә башлады.

— Кояшны да ул ясаганмы?— диде Люция.

Ата беразга аптырап калды. Алар ниндидер бер зур йорт янына килеп туктадылар. Атасы кызына:

— Анысын хәзергә әйтмим. Үзең зур үскәч, менә шушы мәктәп атлы йортка килеп укый башларсың, менә шунда барысын да аңлатып бирерләр,— диде.

Бу вакыт Люция, уйларының очына чыккандай, «менә шул эшче абыйны күрергә кирәк» дип үз-үзенә карар биргән иде. Ул әтисенә:

— Әти, әти, минем эшче абыйны күрәсем килә. Ул кайда була?— диде.

— Һәркайда бар ул, кызым,— диде атасы.

— Юк, ул бер генә,— диде Люция.

Аныңча бар нәрсәне дә ясый белә торган шундый көчле кеше, ни өчендер, дөньяда бер генә булырга тиеш иде.

— Эшче абыйларың бик күбәү,— диде әтисе.— Мин үзем дә эшче.

Бу җавап баланың башына берьюлы сыеша алмады: ул Люциягә шундый көлке булып тоелды. Кечкенә кыз эче катканчы көлде.

— Юк, эшче абый мондый булмый, син әти ич!— диде ул.

Люция зур булгач, эшче абый кебек булырга, бар нәрсәне дә эшли белә торган кеше булу турында уйлана иде.

Менә алар биек морҗалы бер зур йорт янына килеп

җиттеләр. Кечкенә моржа пар аттырып бик каты кычкырта башлады.

— Смена бетте,— диде әтисе. Бу зур йортның завод булуын аңлатты. Шул вакыт завод капкасыннан бик күп кешеләр күренде,— ә менә болары эшче абыйларың, эшче апаларың. Балалар чиста булсыннар дип, алар хуш исле сабыннар эшлиләр,— диде.

— Нинди күп!— диде Люция.

КЕШЕЛӘР НИШЛИЛӘР

Балалар бакчасында бик зур малайлар да, зур кызлар да бар. Алар матур-матур итеп рәсемнәр эшли дә беләләр, әллә нинди билгеләр язалар. Аларны «хәрефләр» диләр. Әллә нинди кызыклы шигырьләр сөйлиләр. Ә Марс әле боларның берсен дә эшли белми. Ул бит әле бакчага да быел гына йөри башлады.

Беркөнне апалары аларга тезелергә кушты:

— Балалар, без бүген урманга барабыз,— диде ул.

— Урманга, их, урманга!— дип сикерештеләр балаларның кайберләре.

Марслар шактый озак бардылар. Ә юлда ниләр генә очрамады аларга.

Әнә тегендәрәк, юлга кешеләр тезләнеп утырганнар да, чүкечләре белән ташларга бәргәлиләр.

Марс, аларны матур-матур ташлар сайлап, шулай уйныйлар ахры, дип уйлады.

Бу турыда апаларыннан сорады:

— Апа, бу әтиләр уйныйлармы?— диде ул.

— Юк, уйнамыйлар. Бу кешеләр эшлиләр. Атлыларга да, автомобильләргә дә йөрер өчен тип-тигез, шоп-шома юл төзиләр алар,— диде апасы.

Бераз баргач тагын бер кызыклы әйбергә очрадылар. Бер зур машинаның лентасы әйләнеп тора. Аның өстендәге кирпечләр үзләреннән-үзләре югарыга йөгерәләр. Ул кирпечләр нәкъ кубиклар кебек. Кешеләр шул кирпечләрне берсе өстенә берсен өяләр. Өйләрнеке шикелле сте-

калар килеп чыга. Марс бара-бара башын югары күтәреп шуларны карады. «Уйныйлармы, әллә эшлиләрме болар?» — дип уйлады ул. Апасыннан сорарга булды:

— Әнә теге абыйлар үзләре кубиклар өяләр, алар да уйнамыйлармы?— диде ул.

— Юк, уйнамыйлар,— диде апа,— алар төзүче абыйлар, йорт салалар. Ул йорт салынып беткәч, безнең бакча менә шунда булыр,— диде ул. Ул арада булмады, тузан туздырып алар яныннан автомобиль узып китте. «Менә бу абый рәхәтләнеп уйный ичмасам»,— дип уйлады Марс.

Их, бу абыйның автомобиле нинди зур, бер дә туктамый, ничек озак бара, ә Марсныкы бик кечкенә, аңа утырып та булмый. Борып җибәргәч тә ул азрак бара да шунда ук туктый. Ул янындагы иптәшенә теге абыйның автомобильгә утырып ничек шәп итеп уйнап йөрүен сөйләде. Аларның сөйләшүләрен апалары ишетеп калган икән, ул:

— Юк, шофер абыең бер дә уйнамый, ул бик кирәкле йөкләрне автомобильгә төяп, бер урыннан икенче урынга ташый,— диде.

Менә Марслар яныннан винтовка күтәргән кызылармеецлар уза башлады.

Алар: «Исәнмесез, балалар!» — дигән шикелле, көлемсерәп үттеләр, тигез адымнар белән зур-зур атладылар. Бу юлы инде апасы Марсның соравын да көтмичә үк үзе аңлатты:

— Кызылармеец абыйлар да уйнап йөрмиләр, алар безнең илне дошманнардан саклыйлар,— диде ул.

Менә бит кешеләр нишлиләр икән! Ә ни өчен Марслар һаман уйнап кына йөриләр, ни өчен алар эшләмиләр? Ул түзмәде:

— Апа, без нигә һаман-һаман уйныйбыз?— диде.

— Юк, без дә гел уйнап кына тормыйбыз. Менә бүген урманга баруыбыз да уйнар өчен түгел, ә урман белән танышу өчен,— диде апасы.

Аннары Марс үсеп торган үләнне күрде:

— Их, нинди үлән! — дип аны кочаклап алмакчы иде ул.

— Әй, Марс, игенне таптама, күмәч бирмәсләр үзеңә, — диде бер зуррак малай. Менә кирәк булса, күмәч үлән булып җирдә үсә икән!

Шундый күп нәрсәләр күрде, күп нәрсәләр белде Марс, ә урман юк та юк иде.

Менә берәм-берәм үсеп утыручы агачлар күренде. Аннары агачлар бик күп булып киттеләр.

— Урман кайда соң, апа? — диде Марс.

Бер малай:

— Ә бу нәрсә соң! — дип кычкырды.

Урман аларны, аналары кебек, яшел кочагын җәеп каршылады. Балалар урманга кереп югалдылар.

ӘБИЛӘРГӘ КУНАККА...

Беркөнне әни миңа:

— Кызым Гөлгенә, яратканым син генә, кил әйдә, киен әйдә, әбиләреңә барабыз, бүләк илтеп кайтабыз,— диде.

Мин бик шатландым. Шатлыгымнан җырлый да башладым:

— Барабыз, барабыз, әбиләргә кунакка!

Карагыз, карагыз, без барабыз кунакка!

Әни дә мин — без икәү, киттек әбиләргә. Әбиләр бездән ерак торалар.

Безнең капканы чыгасың — бер, Маратлар капкасы— ике, Хәлимнәрнеке — өч, Гарифларныкы — дүрт, Асияләрнеке — биш. Ә аннан соң бик күп, бик күп капкалар бар.

Безнең урам белән туп-туры барасың, барасың да сулга борыласың. Аннары тагын барасың, барасың да унга борыласың. Аннары бер урамга борылып керәсең дә, кырыйдан бер йорт кала, икенчесен дә үтәсең, өченчесенә дә кермисең, дүртенчесен дә узып китәсең, ә бишенче йорт әбиләрнеке.

Беркөнне мин бик яхшы билгеләп кайттым. Аларның йорты каршында гына трамвай туктый. Бик билгеле урында безнең әбиләр йорты!

Әбиләр тора торган өй бик зур. Түбәндә бер тәрәзә бар, аның өстендә тагын бер, аның өстендә тагын. Кул бармакларыңның барысын да берәм-берәм бөгеп бетерә-

сең: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү... тәрәзәләренең очына чыга алмассың.

Әни әйтә:

— Әбиләрең бишенче катта торалар,— ди.

Без баскычлар буйлап шул бишенче катка атлыйбыз.

Берне менәбез, икене, өчне менәбез, дүртне, бишне. Бик күп баскычлар менсәк тә, әле без бары беренче катта гына. Ә безнең әбиләр бишенче катта торалар.

Ял итәбез дә тагын менәбез: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү... тагын бик күп баскычлар менәбез. Бу әле бары икенче кат кына. Ә безнең әбиләр бит бишенче катта торалар.

Тагын баскычның бер басмасы артта кала, ике басмасы, өч, дүрт, биш басмасы. Бик күп, бик күп басмалары артта кала. Без әле бары өченче катта гына. Ә безнең әбиләр бишенче катта торалар.

Без тагын менәбез, тагын менәбез. Беренче катны менгәч ял итәбез, икенчене, өченчене, дүртенчене менгәч ял итәбез дә бишенче катка менеп җитәбез. Безнең әбиләр менә шушы бишенче катта торалар.

Анда ишекләр бик күп: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү...

Ә ишек янагында бер түм-түгәрәк әйбер бар, аның уртасында бер төймә дә бар. Әни шул төймәне бармагы белән басарга тотынды. Бер мәртәбә басты, эчтә «чылтыр!» итте. Икенче мәртәбә басты — тагын «чылтыр!» итте, өченче мәртәбә баскан иде, берәү:

— Кем бар?— дип сорады.

Әни әйтте:

— Кызым Гөлгенә дә мин генә.

Ишек ачылды. Аннан әби килеп чыкты, ул көлә иде. Ул мине күтәреп алды.

— Ай, кызым Гөлгенәм килгән икән, бик сагындырдың, бер атна бит инде сине күргәнем юк,— диде.

Без өйгә кердек.

Мин әнидән акрын гына сорадым:

— Әни, атна нәрсә соң ул?— дидем мин.

Әни әйтте:

— Җиде көн,— диде.— Дүрткә берне кушсак — биш була бит. Бишкә берне кушкач, алты көн була, алты көнгә тагын берне кушсаң — җиде көн була. Менә шул бер атна инде.

Әби безгә чәй эчертте. Безне коймак белән сыйлады. Мин биш коймак ашадым. Әни биштән дә күбрәкне ашады.

Мин бер чынаяк чәй эчтем, әни өчне эчте, ә әби биштән дә күбрәк, җидедән дә күбрәкне эчте.

Без әбигә бүләгебезне бирдек. Алар кып-кызыл алмалар иде. Әби ике кулына икешәр алма тоткач та, өстәлдә әле тагын да биш алма калды. Барысы күпме булгандыр, мин белмәдем. Биштән дә күп, җидедән дә күбрәк.

Аннары без өебезгә кайтып киттек, әби безне озатып калды.

170 битка

УТЛЫ ЙОМЫРКА

Безнең әбинең ак тавыгы бар. Ул көн дә кыткылдый-кыткылдый йомырка сала. Әби ак тавыгын бик ярата, аны төрле тәмле җимнәр белән сыйлый, ә йомыркаларны иләккә җыя бара. Ул иләктә ак тавыкның йомыркалары бик күп:

— Бер, ике, өч, дүрт... сигез, ун тугыз...

Бер дә санап бетерерлек түгел. Ул йомыркаларның ничә икәнен әби үзе дә белми торгандыр әле...

Беркөнне әби, ах-вах итеп, ишектән килеп керде.

— Иләктә унбиш йомырка бар иде. Ундүрткә калган. Унбишенчесе утлы йомырка иде. Мин аны вакытлыча гына иләккә куеп торган идем. Эх, харап булдык,— ди әби.

Мин әйтәм: Әллә ул янган?—дим.

Әби үзенекен сөйли:

— Күрше карчык биргән иде, бер үк сакла, дигән иде. Менә хәзер югалган ахрысы, кем дә булса берәү алган,— ди.

Мин бер сүз дә эндәшми торам. Ә әби минем күзләремә туп-туры карый. Алай тегәләп карагач, минем күзләрем оялалар.

Әби һаман-һаман сөйләнә:

— Башкасы булса бер хәл иде, утлы йомырка бит, утлы йомырка. Ә менә бит пожар чыгачак. Ул авылыбыздагы бөтен өйләрне яндырып бетерәчәк. Йомыркасы аның миңа берни түгел...

Минем колакларым ут кебек яна башладылар. Үземә дә әллә ничек эссе булып китте. Ахры күргәндер.

— Әйтергәме, әйтмәскәме?

— Әйтер идем — ул йомырканы мин сорамыйча алдым, әби орышыр. Әйтмәс идем — ул утлы йомырка белән кибет яначак. Бөтен авыл, безнең өй дә, Җәмилләр өе дә яначак.

Мин йодрыгым белән күзләремне уа башладым һәм:

— Әби, утлы йомырканы мин алган идем!— дип елап җибәрдем.

Әби әйтә:

— Харап булганбыз, әйт, кая куйдың?— ди.

Мин әйтәм:

— Җәмил белән кибеттән конфет алып ашадык.

Шунда ук әби каядыр чыгып йөгерде. Ахрысы кибеткә киткәндер. Ә мин оялуымнан көн буе өйгә кайтмыйча йөрдем. Авыл өстендә бер нәни генә төтен күрсәм дә, куркып китәм. Ярый әле морҗадан чыккан төтен була.

Пожар чыкмады. Кич белән генә өйгә кайтсам, әле һаман йокламаганнар. Барысы да өстәл тирәли тезелешеп, чәй эчеп утыралар.

Сеңелем Гөлчирә:

— Әнә, утлы йомырка кайтты!— дип көлә.

Ә башкалар көлмиләр. Мине чәй эчәргә чакыралар. Мин, песи кебек булып, бер кырыйга барып утырам.

Әби көлә-көлә чәй ясый:

— Әй, юләр, юләр, йомырканың утлы булганын кайчан күргәнең бар? Утлы булгач, аннан чебеш ничек чыксын? Тик зурлардан сорамыйча әйбергә тияргә ярамый,— ди.

Ә мин тагын кып-кызыл булам. Нигә сөйли торгандыр бу әби. Әйтерсең, инде аны хәзер мин белмим.

КАРА КАРГАНЫҢ КАРА БАЛАСЫ

(Тел күнекмәсе)

Каенсар артындагы каенлыкка кара каргалар оя ясаганнар.

Бер караңгы төнне ике кара карга, караңгыга да карамыйча, карылдарга тотынганнар:

— Кар-р-р! Кар-р-р! Кар-р-р!

— Кайгы хәбәр бар! Бар! Бар! — дигәннәр кара каргалар.

Ник алай карылдаганнар соң каргалар?

Кара каргалар карлыган кебек кап-кара балаларын каядыр югалтканнар. Кара каргаларның күз карасы кебек кап-кара балаларының кап-кара канаты каерылган. Шуннан кап-кара бер каурый төшеп калган булган.

— Кап-кара балабызны комсызланып козгын чукымады микән? — дип кайгырганнар кара каргалар.

— Әллә карчыга кыерсыттымы икән? — дигәннәр алар.

Карт кара каргалар кап-кара балаларын, карагайлы кара урман артына барып, эзләп караганнар. Карамаган камыш арасын калдырмаганнар. Ләкин кадерле балаларын таба алмаганнар.

Караңгыга да карамыйча, каңгырап очканнар да очканнар кара каргалар. Кара урман артына кырыкмаса кырык тапкыр очып барып кайтканнар. Ә аларның кордашлары — башка кара каргалар, караңгының кадерен белеп, йоклаганнар да йоклаганнар.

Ә тынычсыз әлеге ике кара карга оча-оча балаларын эзләп караганнар, таба алмаганнар.

Кара каргаларга кара карлыгач очраган. Кара каргалар кара карлыгачтан сорап караганнар:

— Кара карлыган кебек чем-кара балабызны күрмәдеңме?— дигәннәр.

— Юк, күрмәдем,— дигән карлыгач. Ә кара каргалар тагын алгарак очканнар. Аларга кап-караңгы төндә, кара урман эчендә бер карчыга очраган. Ул да:

— Күрмәдем!— дигән.

Кара каргаларга козгын очраган. Ул да:

— Күрмәдем,— дигән.

Кара каргалар, кайгыра-кайгыра, ояларына кайтсалар, кап-кара канатлы кап-кара балалары карама ботагына кунаклаган килеш:

— Кар! Кар!— дип кычкырып торалар икән.

Кара карга баласы караңгы төндә оядан ялгыш егылып төшкән булган.

Кап-кара канатлы, кара карлыган кебек кап-кара балаларына карый-карый шатланганнар кара каргалар.

КЕМГӘ КИРӘК, КЕМГӘ КИРӘКМИ?

Әтисе белән бергәләп Таҗи балык тотарга барды.

Көн әле бик иртә. Кояш та юк, ә шулай да якты. Су өсте тып-тын. Өф иткән җил дә юк.

Билгеле, мондый вакытта балыклар яхшы чиртәләр, кармакны бер дә тик тотмыйлар. Калкавычны томрып, су төбенә алып төшеп китәләр. Таҗиның әтисе балыкларны сөйри дә чыгара, сөйри дә чыгара. Ялтырап торган ап-ак чабакларны, көмеш тәңкәле кызылканатларны, әрсез алабугаларны. Таҗи аларның барысын чиләккә җыя бара. Менә инде аларның балык сала торган чиләкләре дә тулып килә. Балык бик шәп эләгә. Шуңа күрә вакытның үтүе дә тоелмый. Әнә инде кояш та күптән күтәрелеп килә. Таҗи аны сизмәде дә. Төшлеккә җитә башлагач, кояш бик нык кыздырырга тотынды. Монысын Таҗи да тойды. Әтисе дә. Әтисе, кесәсендәге кулъяулыгын алып, маңгаендагы тирләрен сөртте. Ә Таҗи:

— Фу... Нәрсәгә кирәк булды инде бу кояш!— дип зәңгәр күктән елмаючыны тиргәргә тотынды.

— Кемгә кирәк, кемгә кирәкми,— диде әтисе, шуннан тагын ялгады,— кояш бер дә булмаса, һаман төн генә булыр иде, ә төнлә балыклар эләкмиләр. Кояш булмаса, җир өстендә үсемлекләр дә үсмәс, син дә, мин дә булмас идек,— диде.

Кояш кыздыргач, балык та эләкми башлады. Таҗи кояшны ачуланып торганда, кинәт җил күтәрелде. Күзгә кебек тигез елга өсте шадраланды. Дулкын кузгалды,

калкавычлар бер күтәрелделәр, бер төштеләр. Балык чиртүе дә беленми башлады.

Таҗи:

— Фу, нигә кирәк булды инде бу җил!— диде.

— Кемгә кирәк, кемгә кирәкми,— диде әтисе.

Елга өстендә җилкәнен киергән көймә йөзде. Тау башындагы тегермәннәр берсеннән-берсе узышып әйләнә башладылар.

Әтисе Таҗига:

— Әнә күрәсеңме, җилкәнгә җилне ничек җиккәннәр. Җил көймәне этеп бара. Җил әнә тегермәннәрне дә әйләндерә. Ул тегермәндә арыш, бодайлар онга әйләнәләр. Ә ул оннан әниең безгә күмәч салып бирә,— диде.

Шул арада җил күк читеннән болытларны куып китерде дә кара-кучкыллы болытлардан яңгыр төшкәли башлады.

— Фу, яңгыр нигә кирәк булды инде, елгада болай да су күп ич!— диде Таҗи.

— Кемгә кирәк, кемгә кирәкми,— диде әтисе. Ашлык сукканда, печән җыйганда, безнең кебек балык тотканда яңгыр кирәкми. Ә менә бу болыннардагы үләннәр, урманнардагы агачлар, кырлардагы игеннәр үссен өчен яңгыр бик кирәк,— диде.

Яңгыр астында алар, аталы-уллы икәүләп, кармакларын чорнадылар.

Шул чак яшен яшьнәде, күк күкрәде. Яңгыр коеп яварга тотынды.

Таҗи:

— Яңгыр, яу-яу, чиләкләп-чиләкләп!— дип кычкыра-кычкыра агач ышыгына йөгерде.

Бераздан әтисе дә килеп җитте. Ул:

— Табигатьтә барысы да кирәкле, улым,— диде. Ачылып килә торган офык читенә күз төшереп:— Эх, яңгыр артыннан балык шәп тә эләгәчәк соң!— дип куйды.

ПЬЕСАЛАР

СЕРТОТМАС ҮРДӘК

5 КҮРЕНЕШТӘ

КАТНАШУЧЫЛАР:

Алып баручы.
Аучы.
Актырнак — аучының эте.
Сертотмас үрдәк.
Керпе.
Куян.
Бүре.
Аю.
Төлке.
Әтәч.
Сарык.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Алып баручы. Еракмы — аны белмәдем, якындамы — аны күрмәдем, безнең илебезнең бер почмагында бер аучы яшәгән. Аның Актырнак исемле эте, төз атар мылтыгы, йорт хайваннары, кош-кортлары да бар икән. Шулар арасында башы бүрекле, аягы төкле Сертотмас дигән бер үрдәге дә булган. Менә шул үрдәк, телен тик тотмау аркасында үзен дә һәлак итә язган, хуҗасын да бәлагә төшергән. Яхшы карагыз, күңел биреп тыңлагыз. Бүгенге кичәбез менә шул Сертотмас үрдәк турында булачак.

Урман каравылчысының ишек алды. Бер кырыйда ялгыз кечкенә генә өй. Икенче кырыйда җыйнак итеп эшләнгән лапаслар. Аларның артында бакча. Бакчада ике-өч баш умарта күренә. Пәрдә ачылганда сәхнәдә берәү дә юк. Бераздан аптыраган кыяфәт белән Актырнак йөгереп керә.

Актырнак.

Хужа, хужа, тизрәк чык.
Зур бәла бездә:
Явыз дошман килеп чыккан
Өй тирәбезгә.

Өйдән аучы йөгереп чыга.

Аучы.

Ни бар, ни бар, кай юньсезе
Курыкмыйча килгән?
Монда аучы йорты икәнен
Онытты микән?

Актырнак.

Әйе, дошман үз башына
Шулай котырына,
Күрерсең үзен. Әйдә тиз
Өйнең артына.

Бергә чыгып бераз югалып торалар. Аучы бүре имгәткән сарык бәрәнен күтәреп керә.

Аучы.

Нәселле сарык бәрәнен
Харап иткәннәр.
Кызганмыйча, мескенемне
Буып киткәннәр.

Сарык кычкырган тавыш ишетелә.

Юксынасыңдыр, мескенем,
Газиз балаңны,
Менә ничек имгәткәннәр
Күрәмсең, аны.

(Күрсәтә.)

Актырнак

(кайгырып).
Күреп калдым ул явызның
Качып киткәнен,
Куган идем дә артыннан,
Ләкин җитмәдем.

Аучы

(ачуланып).
Бу эш өчен, ул бүреләр
Кыйбат түләрләр,
Җавап бирерләр баш белән
Һәм кан түгәрләр.

Актырнак.

Мин эзләрмен, исе белән
Эзен табармын.
Кая таба киткәнен дә
Күрдем мин аның.

Аучы.

Белсеннәр, ничек Аучының
Ачуы кабара,
Күрегез, явыз усаллык
Кая алып бара!
Болай булмый, киттек без, дус,
Мылтыкны алып,
Җәзасын бирик явызның,
Икәүләп табып.

Актырнак.

Йөрсәк йөрик, гизсәк гизик
Бөтен урманны,
Бездән һич котыла алмас —
Табабыз аны.

Аучы йөгереп өйгә кереп китә. Актырнак югалып тора. Бераздан сумка, мылтык таккан аучы чыга, әче итеп сызгыра. Актырнак килеп җитә.

А у ч ы.

Чакырып кил син, Актырнак,
Бар хайваннарны,
Бер сүзем бар, аларга мин
Сөйләрмен аны.

Актырнак сызгырып кош-кортларны, хайваннарны чакыра. Абзарның ишекләре ачыла. Аннан Сарык, Әтәч, Үрдәк чыгалар. Һәрберсе кычкыра. Алгы планда Сертотмас үрдәк.

А у ч ы.

Күрәсезме, кулымдагы
Сарык бәрәнен?

С а р ы к.

Ах, балакай, җанкисәгем,
Матур бәрәнем!
(Елый.)

А у ч ы.

Сорамыйча чыгып киткән
Үзе утардан.
Үлән ашап йөргән чакта,
Бүрегә тарган.
Ә ул явыз харап иткән,
Буып үтергән.
Актырнакны күргәч, Бүре
Ташлап йөгергән.

А к т ы р н а к.

Шул явызның эзе буйлап
Без барачакбыз,
Бу кечкенә бәрән үчен
Без алачакбыз!

Аучы.

Без, Актырнак белән бергә,
Җыендык ауга.
Шул явызны табар өчен
Киттек урманга.
Безнең өйдә юк икәнне
Һичкем белмәсен.
Беләсезме, сезнең өчен
Сер бу бик яшерен.
Бу серне сез һәркайсыгыз
Яхшы саклагыз,
Анда без озак йөрмәбез,
Бик тиз кайтырбыз.

Сертотмас.

Юлыгыз уңсын, явыз тотылсын!
Тыныч булыгыз, рәхәт йөрегез.

Аучы.

Ярый, хушыгыз!

Актырнак.

Хуҗа әйткәнне
Истә тотыгыз.

«Хушыгыз!» — дигән тавышлар. Хайваннар, кошлар Аучы белән Актырнакны озатып, хәерле юл теләп калалар. Алгы планда Сертотмас үрдәк. Ул кулъяулыгын селкеп кала.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Алып баручы. Хайваннар, кошлар хуҗасыз бер төн кундылар, берни булмады. Икенче көн: «Тагын бүре килгән»,— дигән хәбәр таралды. Сарыклар куркыштылар, кошлар да кайсылары-кая качтылар. Соңыннан җыелдылар да инде нишләргә кирәк?— дип киңәшергә тотындылар. Бик күп сөйләделәр һәм түбәндәге карарга килделәр.

ДЕКОРАЦИЯ ШУЛ УК

Сертотмас. Бу кичне, хуҗасыз һәм туры сакчысыз — Актырнаксыз куну мөмкин түгел. Үткән төн Бүре тагын килгән, безнең абзар тирәсендә дә йөргән. Тизрәк-тизрәк хуҗаны эзләргә берәүне җибәрергә кирәк.

Хайваннар *(бергә)*. Әйе, кирәк, бик кирәк, ләкин тизрәк!

Сертотмас. Әтәчне җибәрсәк ничек булыр? Бәлки, юлы уңар?

Сарык. Юк, аңардан булмас, ул тотылыр. Оча да белми ул, йөзә дә; йөгерүен йөгерә дә, ләкин тиз арыячак, табып кайта алмаячак.

Сертотмас. Сарыкны җибәрсәк ничек булыр? Бәлки, юлы уңар?

Әтәч. Сарык та аңгыра. Бер ялгызы абзарда ятарга да курка әле ул. Син бер сүз кушарсың, ул башкача аңлар. Бу эш өчен батырны, җитезне табарга кирәк. Минемчә, бу эшне башкарса үрдәк башкарыр. Чөнки ул йөгерә дә, йөзә дә, оча да ала.

Сарык. Әйе, әйе, үрдәк барсын, бу эшне башкарып чыгуны үз өстенә алсын.

Тавышлар. Дөрес, дөрес, үрдәккә тапшырырга кирәк, ләкин тизрәк.

Әтәч. Безнең хакка өйдәге серне нык сакла. Әгәр белсәләр, эшнең ничеклеген сизсәләр, килерләр дә хуҗалыкны да тар-мар итәрләр, үзебезне дә ашап китәрләр.

Сертотмас. Минемчә, Әтәч батыррак. Бу эшне аңа тапшыру яхшырак.

Әтәч. Юк. Ул эш булмый миннән, яхшы беләсең ич, чыкканым юк кетәклегемнән.

Сертотмас. Минем барганым юк урманга, бик куркынычтыр анда.

Сарык. Йөри ич әле Актырнак, аның кай җире бездән артыграк?

Әтәч. Хуҗага ияреп барырга кем дә булдыра, ә син

менә бер ялгызың барып кара. Ә үрдәк бу эшне булдыра, чөнки ул оча ала.

С е р т о т м а с. Авыр эш инде авырын. Ярар, сезнең хакыгызга барсам барырмын. Сер саклау турында тыныч булыгыз, ярый, хушыгыз.

Үрдәк очып китә, кошлар, хайваннар озатып калалар.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Аның эченә таба юл сузылган. Урманның аргы башында елга. Пәрдә ачылганда үрдәк юл уртасында ял итеп утыра.

С е р т о т м а с *(такмаклый)*. Эзли-эзли арып беттем, бераз ял итим. Үзләре барысы да рәхәтләнеп өйдә калдылар, миңа гына шундый авыр эш тапшырдылар. Ә мин, юләр, шуларның сүзләрен тыңладым. Шундый авыр эшне үтәүне үз өстемә алдым.

К е р п е

(агач арасыннан җырлап килә).
Балаларым, йомшакларым,
Бик ачыкканнар.
Күренми микән еланнар
Яки тычканнар.
Тукта әле, такыр юлда
Кемдер селкенә,
Үтермәсен, хур итмәсен,
Качыйм тиз генә.

С е р т о т м а с

(күреп ала).
Керпе, керпе, нигә болай
Качасың? Кая?
Мин үрдәкне санадыңмы
Әллә усалга?
Һичбер кемгә тими торган,
Мин юаш үрдәк,

Бары синнән сорый торган
Сүзем бар әзрәк.

Керпе

(куркыбрак үрдәк каршына чыга).
Нишләп утырасыз?
Кемне көтеп торасыз?

Сертотмас. Иптәшләремнең тапшыруларын үтим, хуҗабыз белән этебезне эзлим. Икәүләп ауга киттеләр, эшне хур иттеләр. Хуҗалыкны сакчысыз калдырдылар, безне куркуга салдылар. Күрмәдеңме, Керпе, шуларны? Ишетмәдеңме мылтык атылганны?

Керпе. Ишеттем мин мылтык шартлавын, күрдем кошларның куркып качканын. Ләкин ишетелде бик еракған, әнә теге яктан. Ә сезнең өегез кайда? Кайсы юл анда таба алып бара? Сездә юкмы еланнар һәм тычканнар? Минем балаларым бик ачыкканнар.

Сертотмас. Менә шушы сукмак безнең өйгә туптуры алып бара. Ләкин, берәүгә дә әйтмә, кара. Бездә еланнар бөтенләй күренми. Ә инде тычканнарга песи абзый көн бирми. Ярый, хуш. Китим тизрәк, хуҗаларны эзләп табарга кирәк.

Керпе. Киемем энәле булса да, эч серенне алсам да, мин сиңа начарлык эшләмәм: сак бул, очраган берәүгә сереңне сөйләмә. Серең эчеңдә торса — йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр — корыч булыр.

Сертотмас. Тотындың инде акыл сатарга, керештең шунда сару кайнатырга. Син өйрәтмәсәң, белмиләрме әллә, кем белән ничек сөйләшергә.

Керпе. Башкалар әйткәнгә дә колак сал, ул сүзләрдән гыйбрәт ал. Үзең белгәнчә эшлә, тик авыр хәлгә төшмә. *(Куаклык эченә кереп югала.)*

Сертотмас. Мылтык тавышы да юк, эт тавышы да... Җитмәсә, берәрсе очрамый да шунда. Чү, әнә, ниндидер озын колаклар күренә. Әһә, димәк, кемдер килә!

Куян

(җырлый).

Юк микән тәмле кайрылы
Япь-яшь агачлар.
Балаларым, ап-акларым,
Алар бик ачлар.
Килер идем кимерергә
Барысын иялтеп,
Урмандагы сукмакларның
Серен өйрәтеп.

(Үрдәк янына килә.)

Нигә монда торасың?
Нишләп утырасың?

Сертотмас.

Хуҗабыз белән этебез
Ауга киттеләр,
Нәкъ бер тәүлек узды инде,
Кайтмый йөриләр.
Алардан башка,
Йорт-җиребез, кош-кортыбыз,
Хайваныбыз, умартабыз
Һәм бакчабыз
Саксыз калды.
Менә шуңа, беләсеңме,
Әтәчләрне, тавыкларны,
Үрдәкләрне, сарыкларны
Нык курку алды.
Актырнак белән хуҗаны
Күрмәдеңме син?

Куян.

Актырнак белән аучыны,
Юк, күрмәдем мин!

Мылтык шартлавын ишеттем,
Бик-бик еракта,
Әнә теге якта.
(Үрдәк яныннан китеп, аланлыкта туктап җырлый.)
Хуҗасы да, этләре дә
Өйдә юк, диген,
Җайлы вакыт, алмагачны
Кимерергә бүген.
(Ашыгып тиз генә китә.)

Сертотмас. Рәхәтләнеп җәелеп сөйләшергә, сорашырга алгы юлны, киңәшергә очрамый бит тагы берәрсе, озын колаклыдан юньлесе.

Куаклар арасыннан «ох-ох» килеп Аю чыга.

Аю

(ялварып сорый).
Шәфкатьле кошкай,
Очратырмын дип
Уйламадым да,
Зинһар ярдәм ит.
Бал кортларыннан
Усал бөҗәкләр
Күргәнең бармы?
Менә шул кортлар —
Аучы аткандай,
Төзәп мылтыгын
Менә шушында
Кадады угын.
(Табанын күрсәтә.)

Сертотмас

(муенын сузып-сузып карый).
Вакытым да юк-югын,
Ашыгам мин бүген.
Хуҗабыз белән этебез

Ауга киттеләр,
Нәкъ бер тәүлек узды инде,
Кайтмый йөриләр.
Алардан башка:
Йорт-җиребез,
Кош-кортыбыз,
Хайваныбыз,
Умартабыз
Һәм бакчабыз
Сакчысыз калды.
Менә шуңа, беләсеңме,
Әтәчләрне, тавыкларны,
Үрдәкләрне, сарыкларны
Нык курку алды.
Күрмәденме, Аю, шуларны?
Безнең хуҗаларны?
(Борыны белән укны тартып чыгара.)

Аю. Юк, юк, күрмәдем, ул хакта берни дә ишетмәдем. *(Куаклар арасына кереп, үрдәк күзеннән югалгач җырлый.)*

Ләкин тамак һаман туймаган,
Туярга да ул уйламаган.
Хуҗасы да юк,
Эте дә өйдә юк,
Алайса, димәк,
Мишем тамак тук!
(Тиз-тиз атлап югала.)

Сертотмас.

Ял итү җитәр,
Ашыгу кирәк.
Кызурак атла,
Әйдә, син, үрдәк!
Табарга кирәк,
Әйтергә кирәк,

Кайтсыннар алар
Өйгә тизрәк.

Теш шыкырдаткан тавыш ишетелә. Сертотмас куркына.

Бүре.

Куяннар да күренмиләр,
Качканнар бар да;
Җәйге урман яфраклары
Сакчы аларга.
Ә шулай да эч бик бора,
Карыным бик ач,
Булырсың ач, тәүлегенә
Берни капмагач!
Кара, кара, ул үләннәр
Нигә селкенә?
Куяннар йөриме әллә?
Тукта, кем килә?

Сертотмас.

Хуҗабыз белән этебез
Ауга киттеләр,
Нәкъ бер тәүлек үтте инде,
Кайтмый йөриләр.
Алардан башка,
Йорт-җиребез,
Кош-кортыбыз,
Хайваныбыз,
Умартабыз
Һәм бакчабыз
Сакчысыз калды.
Менә шуңа барысын да:
Әтәчләрне, тавыкларны,
Үрдәкләрне, сарыкларны
Нык курку алды.
Актырнак белән хуҗамны
Күрмәдеңме син?

Бүре.

Актырнак белән аучыны? —
Юк, күрмәдем мин.
(Аланлыкка барып чыга.)
Этләре дә юк,
Хужа өйдә юк,
Ә сарыклар күп,
Димәк, тамак тук.
(Йөгереп китә.)

Сертотмас.

Булмас ахры табып,
Йөрим юкка чабып,
Йөрим юкка, тиле,
Кайтыйм ахры кире.
(Кайтырга дип борыла.)

Куаклар арасыннан борынын югары күтәреп, иснй-исни төлке килә.

Төлке

(исни).
Нинди тәмле ис
Керә борыныма? —
Кайда да булса,
Үрдәк бар монда!
Балаларыма
Бүлеп бирермен,
Үзем дә азрак
Авыз итәрмен.
(Үрдәк каршысына килеп чыга.)
Сылу кош, үрдәк,
Әйтче тизрәк,
Нишләп болай монда йөрисең?
Югалттыңмы балаларыңны,
Шуларнымы әллә эзлисең?

Сертотмас

Балалар өйдә, тыныч торалар,
Тавыкларыбыз да күкәй салалар.
Умарталар да балны мул бирә,
Алмагачлар да алма үстерә.
Ул як бар да шәп —
Җаныбыз тыныч.
Тик, саклаучы юк —
Безгә куркыныч!
Эт белән хуҗа ауга киттеләр,
Бер тәүлек инде, кайтмый йөриләр,
Эт иярткәнне, мылтыклыны,
Шундый кешене очратмадыңмы?

Төлке.

Күрдем аларны урман эчендә,
Баралар иде икесе бергә.
Мине дә куды сезнең этегез,
Бик усал икән ул егетегез.

Сертотмас.

Табасы иде менә шуларны,
Әйләндем бит бөтен урманны.
Иптәшләрем зарыгып беткәндер,
Балаларым сагынып көтәдер.

Төлке.

Кызганам мин сине, шуңарга
Ярдәм итәм эзләп табарга,
Рәхәтләнеп кайтып китәрсең,
Иптәшләреңне шат итәрсең.

Бераздан елга буендагы төлке оясына якынлашалар. Анда төлке балалары уйнап йөриләр.

Минем өйгә килеп җитәбез,
Бераз кунак булып китәрсез.

Сертотмас.

Башка вакыт кунак булырбыз,
Яхшы хәзер юлда булуыбыз.

Төлке балалары аны сырып алалар.

Төлке балалары

Ачыгып беттек, киттең, югалдың,
Безгә нәрсә алып кайта алдың?

Төлке

(үрдәккә күрсәтеп).
Үрдәк ите алып кайттым,
Менә карагыз,
Тигез итеп бүлеп бирәм,
Шәпләп ашагыз.

Үрдәккә һөҗүм итәм дигәндә генә, Сертотмас очып китә.

Үрдәк

(һавадан).
Мин генә иң хәйләкәр дип,
Ялгыш уйлама!
Хәйләкәрне дә җиңәләр
Кайчак дөньяда.

Төлке.

Йөзем әле пешмәгән дип,
Ашамый киттем.
Монысын да ычкындырдым,
Әх, әрәм иттем.
(Кызып.)
Ярый, ярый, барыбер син

Кайтырсың өеңә,
Мин анда да бара беләм,
Артык сөенмә!

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче күренештәге декорация. Ерткычлар төрле яктан аучы хуҗалыгына һөҗүм итәләр.

Куян

(бакча коймасы янында).
«Эх, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары!»
Җимерәсе иде койманы,
Кимерәсе иде шуларны.
(Азаплана, тырыша-тырыша сикереп карый, керә алмый.)
Бакчасына кереп булмады,
Каһәр суксын, юлым уңмады.
Я хуҗалар кайтып килерләр,
Кызганмаслар, атып үтерерләр.
Кире китим ахры мин моннан,
Әйләнермен бәлки соңыннан...
(Аюның килүен күреп поса.)
Аю бабай нишләр икән ул,
Табар микән берәр керер юл?
Аю бакча коймасына ышкынып килә.

А ю.

Бу коймаларның артында
Матур бакча бар,
Ул бакчада бал кортлары
Рәхәт торалар.
Керәсе иде, ашыйсы иде
Шуларның балын,
Бәлки, бераз туяр иде
Минем тамагым.

(Ачуланып.)

Коймаларын җимерәм, керәм,
Күрсә күрсеннәр.
Көмлегемне, батырлыкны
Минем белсеннәр!

(Койманы җимереп бакча эченә кергәндә, «Ух!»— дип бәрәңге базына егылып төшә. Баздан башын калкытып.)

Бер юньсезе кирәкмәскә
Баз казып куйган,
Бу бәладән котылырсыңмы
Син, аю туган?
Юкса тиздән беләсеңме,
Хуҗа кайтачак,
Һич кызганмый, туры төзәп,
Сиңа атачак...

Куян, поскан җиреннән чыгып, бакчага керә.

Куян.

Болай булгач, җайлы булды
Миңа керергә,
Бик тиз генә алмагачларын
Кимерергә.

Аю.

Куян энем, зинһар димен,
Ярдәм итсәнә,
Бу бәладән котылдырып
Мине китсәнә!..

Куян.

Эшең начар икән, бабай,
Колакка тотын,
Сөйрәп чыгарыйм үзеңне,
Чыкмасын котың.

(Аюны сөйрәп чыгара, икәүләп бакчага керәләр.)

Куян алмагач кимерә, Аю умарта баса.

А ю.

Алмагачны кимерү белән
Артык мавыкма,
Аучы бакчасында бит син,
Шуны онытма.

Куян.

Туйдым инде, урманыма
Кайтырга кирәк,
Я хуҗалар кайтып килер,
Китик тизрәк.

А ю.

Безнең өчен урман яхшы,
Урманда бик шәп,
Хуҗа кайтканчы тизрәк
Сызарга кирәк.

Китәләр.

Төлке.

Хуҗа да юк, эте дә юк —
Йөриләр ауда,
Кетәклеккә, хуҗалыкка
Мин хуҗа монда.
Бар әтәчләр, бар тавыклар
Минеке хәзер,
Телим икән үрдәк ите,
Ансы да әзер.
(Кетәклеккә таба бара.)

Тавык кыткылдаган, үрдәк бакылдаган тавышлар. Төлке кетәклеккә керим дигәндә генә капкын «шап» итә. Төлкенең аягы кысыла, ул чыелдый.

Төлкедән дә хәйләкәррәк
Кеше дигәнең,

Киләсемне, керәсемне
Каян белгән ул?

Бетте бит баш йөри торгач
Тамак артыннан.
Хәзер инде котылып булмас
Явыз капкыннан.
Эх, авырта соң аягым,
Бигрәк авырта...
Ничек чыдыйм бу сызлауга,
Бу зур хурлыкка!
Инде исән котыла калсам,
Мин тагын әгәр,
Килмәс идем, үзем кадәр
Алтын бирсә дә!

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Декорация шул ук. Аучы белән Актырнак кайтып керәләр.

Актырнак

(күреп, гаҗәпләнеп).
Коймабызны җимергәннәр,
Базны ишкәннәр,
Алмагачны кимергәннәр,
Харап иткәннәр!

Аучы.

Бу ни эш бу? Бакчабызда
Кайсыдыр булган!
Күрәсеңме, умартаны
Ничек туздырган?
Димәк, өйдә юклыгымны
Минем белгәннәр;
Шуңа күрә, курыкмый-нитми
Бире килгәннәр.
Ярый-ярый, эзегезгә

Төшәрбез эле.
Вакыт җитәр, бу серне дә
Чишәрбез эле.
(Утырып тәмәке тарта.)

Бүре бакча буендагы лапас тирәсендә йөргәли дә койма башыннан лапас түбәсенә менеп китә. Аучы белән эт аны күреп калалар.

Бүре.

Эт һәм хуҗаның
Юклыгын белеп,
Тиз генә йөгереп,
Мин җиттем килеп.
Ләкин ни файда?
Сизгер шул хуҗа,
Эчкә керә алмый
Гомерем уза.
(Өзгәләнә.)
Бик нык эшләнгән
Нарат тактадан,
Куптарып булмый,
Нык кадакланган.
Яхшы чагында
Сызарга кирәк.
Хуҗа кайтмасын,
Китим тизрәк.
(Китәргә тели.)

Шул вакыт аны Актырнак күреп ала.

Актырнак.

Менә кайда икән явыз,
Түбәгә менгән,
Димәк ауда икәнлекне
Бусы да белгән.
Кем дә булса бер сертотмас
Эшне хур иткән.

Серне эчтә тота алмыйча,
Берсенә чишкән.

А у ч ы.

Ә шулаймы? Ачуымны
Бик нык китерден.
Эзләп табалмаган идек,
Син үзең килдең.
Мә алайса, көткән сыйны
Ал син, бездән ал,
Күп ерткычлыклар эшләдең,
Бәдбәхет, кадал!
(Атып җибәрә.)

Аучы белән Актырнак Бүрене сөйрәп ишек алды уртасына керәләр.

А у ч ы.

Хайваннарым, кош-кортларым,
Без кайттык менә,
Яле, Әтәч, йортта ни бар,
Барысын да сөйлә!

Ә т ә ч.

Барыбызны үтерергә,
Алып китәргә,
Бик әйбәтләп тәмле генә
Азык итәргә
Уйлаучы дошман әләкте
Үзе капкынга.
Башын югалтты ул явыз
Тамак хакында.

А у ч ы.

Кая, кайда, кайсы явызы?
Ничек килгән курыкмый берүзе?
Ә, син икәнсең әле, хәйләкәр.
Бездә дә бит әзрәк хәйлә бар.

Төлке.

Үтермәче, зинһар, үтермә,
Балаларым ятим иттермә.

Аучы.

Ярый, тыңлыйм инде сүзеңне,
Зоосадка бирәм үзеңне.
(Төлкене бер читкәрәк алып китә.)

Әтәч, Тавык йөгереп чыгалар, Аучыны урап алалар.

Әтәч.

Бу эштә бит төп гаепле
Сертотмас үрдәк.
Хәер, безнең барыбызда да
Гаеп бар әзрәк.
Лыгырдавык Сертотмаска
Зур эш тапшырдык,
Шулмы инде, зур йомышны
Эшкә ашырырлык.
Курку алгач, сезне эзләргә
Җибәрдек аны,
Кая инде сезне табу,
Үзе югалды.
Соңыннан тик аңладык без
Аны аңлавын,
Сер тотмавы аркасында
Һәлак булганын.

Актырнак

(ерактан очып килгән Сертотмасны күрсәтеп).
Карагыз әле, карагыз,
Кем кайтып килә!..
Үлгән дигән идең, Әтәч,
Күр әнә син дә.

Сертотмас.

(һавадан).

Җәфа күрдем сезнең хакта,
Михнәтләр: бак-бак,
Беләсезме, сезнең хакта
Үлмәдем чак-чак.
Төлке дигән йөзе кара
Үтерә язды,
Беләсезме, тик бары бит
Очуым коткарды.

(Җиргә куна.)

Аучы.

Ә шулай да син гаепле,
Телең тик тормас,
Яхшы белдек, син икәнсең
Һичбер сер тотмас.
Хуҗалыкка күпме зарар
Синең аркада.
Син лаеклы бүгенге көн
Авыр җәзага.
Гафу итәм бу юлга мин,
Суеп ашамыйм,
Ә шулай да җәза кирәк,
Асыл кошка, дим.
Берни бирмәм ашарыңа
Өч тәүлек буе,
Шушы авыр җәза сиңа
Миннән бу юлы.

Сертотмас.

Болай булыр дип, дусларым,
Һич уйламадым,
Серне әйтеп ташлавымны
Сизми дә калдым.

А у ч ы.

Сабак булсын синең бу эш
Барыгызга да,
Бардыр әле үрдәк күкләр
Сезнең арада.
Үтерсәләр үтерсеннәр,
Серне һич бирмә;
Дошманнарга һичбер вакыт
Серне белдермә.
Үрдәк хәленә калмагыз,
Сез дә, балалар.
Сер тотмаучы, лыгырдавык —
Яраксыз алар.
Сер тотмауның начарлыгын
Исеңдә тот син.
Кирәксезне һич сөйләмә,
Телең тик торсын!..

п ә р д ә.

ЙОЛДЫЗ

4 ПӘРДӘЛЕК ПЬЕСА[1]

КАТНАШАЛАР:

Миңгаян — укучы, соңыннан пионер.
Салихҗан — аның атасы.
Мәрфуга — аның анасы.
Нур — отряд вожатые.
Хәйруш бабай — каравылчы.
Вәли — } укучы-пионерлар.
Рауза — }
Валя — отряд вожатые.
Завхоз.
Укучылар һәм пионерлар.

I ПӘРДӘ

Колхоз амбарының ишек төбе. Пәрдә ачылганда, мылтыгын тоткан Хәйруш бабай авыз эченнән көйләп, әрле-бирле йөреп тора. Кинәт аяк тавышлары ишетелә, каравылчы мылтыгын тавыш килгән якка төзи.

Хәйруш. Кем килә? Якын килмә, яхшы булмас! Кем килә? Бер. Кем килә? Ике... кем килә?..

Вәли. Йолдыз отрядының пионеры Вәли Гыйльметдинов килә.

Хәйруш. Ни эш бетереп йөргән була?

Вәли. Чәчелергә тиешле орлыклар аякланмадылар микән дип тикшерергә килә. *(Вәли сәхнәгә керә.)* Әй, Хәй-

[1] Бу пьеса А. Әхмәт белән бергә язылган.

руш бабай, әле генә бер котырган эткә очрадым. *(Еш-еш сулый.)* Шундый чаптым, шундый чаптым.

Хәйруш. Әй, җан көеге, эттән дә курыккач, буржуй күрсәң, син күптән шыр җибәрерсең.

Вәли. Мине бик яман итеп эт тешләгәне бар, шуна гына куркам мин. *(Хәйрушка таба килә.)*

Хәйруш. Якын килми сөйләш, җебегән. Буржуй тешләгәне юк әле сезне. Буржуй котырган эттән дә яманрак тешли ул.

Вәли. Орлыклар аякланмадылармы, дим, Хәйруш бабай?

Хәйруш. Һе, кая китсеннәр, ди. Аяклары юк ич аларның.

Вәли. Кайвакыт аяксызлар да аякланалар икән шул. Әнә «Марс» колхозында биш капчык арыш аякланган, ди.

Хәйруш *(исе киткән булып)*. Кит аннан, булмас ла! Мин соң инде мылтык белән каравыллый торып та каракларга әйбер бирәм диме. *(Вәли якын килә башлый.)* Якын килми генә сөйләш, юк исә?

Вәли. Хәйруш бабай, кара әле, Салихҗан абзыйлар нигә һаман йокламыйлар икән. *(Уң якка таба төртеп күрсәтә.)*

Хәйруш *(игътибарсыз)*. Крачиннары күптер. *(Вәли сызгырына-сызгырына йозакларга кырын-кырын карап бер-ике әйләнә дә чыгып югала.)*

Хәйруш. Бала-чагасына кадәр зурлар эшенә борынын тыгып йөри. Менә кая китте бит дөньялар. Борынын җыя алмаган нәрсә олылар белән зур булып, гәп сугып тора бит. Салихҗан абзыйлар ник йокламыйлар имеш. Кара син, хәчтерүшне. Юк-барга күз төшерә, сорашкан була. Ай-һай, бу елгы балаларны, кече яшьтән үк тикшеренергә өйрәнәләр. *(Йөри. Бераз тын торганнан соң, тагын аяк тавышлары ишетелә)* Кем ул? *(Эндәшүче юк.)* Кем килә диләр бит сиңа. Кем килә — бер. Кем килә —

ике, кем — ки-лә-ә-ә, атам... *(Аяк тавышы килгән якка мылтыгын төзи.)*

Сәхнәгә Миңгаян, Салихҗан һәм завхоз керәләр.

Салихҗан. Шаулама, Хәйрулла абзый, үз кешеләр.

Хәйруш. Котны очырдыгыз. Ата яздым бит, чәпчелеп киткере.

Завхоз. Сүзнең вакыты бу түгел, сүз өчен чәй яны яхшы була ул. Тимерне кызуында сугарга кирәк, юкса суына башлар.

Салихҗан. Кая, Хәйрулла абзый, ач та безне кертеп җибәр әле. Юл кешесенең юлда булуы яхшы дигәндәй, эштә булуыбыз хәерлерәк булыр. *(Завхоз кесәсеннән ачкыч ала һәм амбар йозагын әкрен генә ача. Уң кулы белән Салихҗанны үзенә таба чакыра. Култык астына капчыклар кыстырган Салихҗан завхоз янына килгәч, завхоз сул кулы белән аңа амбар ишеген күрсәтә, шул ук хәрәкәтләр белән берәм-берәм, Миңгаянны, Салихҗанны амбарга кертә. Миңгаянның кулында лампа. Алар кереп киткәч, Хәйруш як-ягына каранып, амбар ишеген ябып куя.)*

Салихҗан *(амбардан башын сузып)*. Ул-бу юктыр бит?

Хәйруш. Юк. Әгәр дә кеше-фәлән килә башласа, мин «Галиябану»ны көйләрмен. *(Йозак белән амбарны бикли дә, әрле-бирле йөри. Пауза. Бераздан Хәйруш кемнеңдер килүен ишетеп, «Галиябану»ны көйли башлый.)*

Хәйруш. Кем бар?

Нур. Мин — Нур, Хәйруш бабай, ни хәл, ул-бу юкмы?

Хәйруш. Күрәсең ич, нәрсә булсын.

Нур. Сиздермичә, еракта ук әкрен генә киләм. Мин әйтәм, Хәйруш бабай йоклаган булса, мылтыгын әләктереп китим әле дим.

Хәйруш. Һе, йоклатырсың Хәйруш абзаңны, мамык түшәктә генә йокларга ярата ул. Алай да әле төненә җиде

уяна. Ә инде монда — халык малын каравыллаганда, аны-сы бездән булмас, Нур энем.

Н у р. Шулай кирәк, Хәйруш абзый, колхоз милеген... *(Амбар эченнән кыштырдаган тавыш ишетелә.)*

Н у р. Әһә, тукта әле, анда нәрсә кыштырдый. *(Хәйруш «Галиябану»ны көйләп ала.)*

Х ә й р у ш *(көчләнеп елмая)*. Андамы, анда колхоз дошманнары. *(Нур аптырап берничә адым алга атлый да йозакка кулын суза. Хәйруш мылтык түтәсе белән Нурны кире чигендерә.)*

Х ә й р у ш. Андамы, күселәр.

Н у р. Ә, шулаймы? Мин әле колхоз дошманнары дигәч...

Х ә й р у ш *(аны бүлә)*. Нигә, күселәр колхозның дусларымыни? Контр бит алар.

Н у р. Алай булса аның чарасын күрергә кирәк. Минем пионерлар ул эштә дә менә дигән мастерлар. Без тотынсак, өч көн дигәндә күсенең эзе дә калмас.

Х ә й р у ш. Шәп булыр иде ул, чәнчелгере. Әле бер пионерың монда булып киткән иде.

Н у р. Вәли булгандыр, ул бүген билгеләнгән иде. Ярый, мин тагын теге амбар яныннан да әйләним әле. Хуш, Хәйруш абзый.

Х ә й р у ш. Хуш. *(Үз-үзенә.)* Котым бугазыма килде, белеп тә бетермәссең, кырыкмаса кырык хуҗа. Авыл советы бер килә. Колхоз председателе ике килә, партячейка, комсомол, пионеры унбер килә. Хатын-кызларына хәтле делегатка-милигатка дигән булып эшкә тыгылалар, чәнчелеп киткерләре, һич покой бирмиләр. *(Тагын әрле-бирле йөри. Амбар эчендәгеләр шакыйлар. Каравылчы ишекне ачып саклык белән аларны берәм-берәм чыгара. Ләкин шул арада тагын аяк тавышлары ишетелә башлый. Ашлык урлаучылар аптырашта калалар. Каравылчы аларны тиз генә яңадан амбарга кертеп, ишекне бикләп куя.)*

Х ә й р у ш. Кем килә? Җавап бир! Бер... юк исә... Эшең хөрт булыр.

Нур. Мин бу, тагын әйләндем әле.

Хәйруш *(елмаеп)*. Ә, синмени, әйдә...

Нур. Менә *(кулындагы мәчене күрсәтә)* күселәргә каршы көрәшә торган батыр алып килдем. Кая кертеп җибәрик әле шуны. *(Ишеккә таба бара.)*

Хәйруш *(мылтыгын аркылы куеп)*. Юк, энекәш, шаярма, ансы булмый. Җиде төн уртасында Калинин бабаң үзе килсә дә якын җибәрү юк. Безгә шулай кушылган.

Нур. Мин бит әллә нишләмим, мәчене генә кертәм.

Хәйруш. Эшләмәсәң дә законы шулай, энем, әнә ишек астындагы *(күрсәтә)* тишектән ул үзе дә керә белә.

Нур. Ярый, шуннан кертик. *(Мәчене кертеп җибәрә.)* Хәзер күселәр колхоз ашлыгының бер бөртеген дә ашый алмаслар. *(Чыгып китә. Ул киткәч, каравылчы тагын әрлебирле йөри. Эчтәгеләр шакыйлар, Хәйруш ишекне ача.)*

Салихҗан. Котыбыз калмады, керә дип торабыз.

Хәйруш. Аның эше малай-салайны кертергә ярый рәҗе. *(Капчыкларны берәм-берәм күтәреп ташыйлар.)*

Завхоз азакны капчыкны күтәреп алып чыга, каравылчы амбар ишеген бикләп кала.

пәрдә

II ПӘРДӘ

Сәхнәнең бер кырыенда өй эче күренә, икенче кырые урам. Пәрдә ачылганда сәхнәдә берәү дә юк. Бераздан йөгереп Миңгаян керә һәм ул юл буйлап китап укып килүче Вәлигә килеп бәрелә.

Вәли. Кая болай ашыгасың?

Миңгаян. Кая булсын, менә, менә. *(Муенындагы галстугын күрсәтә.)*

Вәли. Ә, тантаналы вәгъдә биреп кайтасыңмыни?

Миңгаян. Син нигә килмәдең, Вәли?

Вәли. Мин дежур идем бит, Миңгаян.

Миңгаян. Ялгыштың, Вәли. Миңгаян булмый гына торсын әле.

В ә л и. Нәрсә, әллә минсез Гаянга әйләндеңме?

М и ң г а я н. Юк, мин ул искергән исемне алыштырдым. Миңа хәзер Йолдыз дип кенә эндәш.

В ә л и. Ә, шулаймы?! Тәбрик итәм. *(Кулын суза. Йолдыз салют бирә. Вәли кулын сузган килеш кала. Аннан тиз генә салют бирә, пауза.)*

М и ң г а я н. Рәхмәт, Вәли.

В ә л и *(якынрак килеп).* Сиңа, Йолдыз *(җитди тон белән),* колхоз амбары якын. Күз-колак бул! Усал куллар шаярмасыннар.

М и ң г а я н. Әллә берәрсеннән шикләнәсеңме?

В ә л и. Югын юк та, сак булган яхшы. Андый эшләр булгалый бит ул.

М и ң г а я н *(уңайсызланып, каушап Вәлигә якын килеп).* Вәли, менә мин бер китап укыган идем...

В ә л и. Я?

М и ң г а я н. Бик кызык китап ул. Анда бер кешенен колхоз малын урлавы турында язылган. Ә малае моны белеп торган икән.

В ә л и. Малае белеп торган, ә ул малай пионермы соң?

М и ң г а я н. Пионер шул.

В ә л и. Пионер. *(Уйга кала.)*

М и ң г а я н *(йомшак кына).* Вәли, син менә шул малай булсаң, нишләр идең?

В ә л и. Минме? *(Уйлый.)* Мин аны бер нигә карамый тотып яптырыр идем.

М и ң г а я н. Үз атаңнымы? Ә соң аннан сине кем туйдырыр? Кем сиңа күлмәкләр алып кайтыр?

В ә л и. Тфү андый этиләргә, ә колхоз?

М и ң г а я н. Шулаймы? *(Бераз уйлап тора да кинәт кулы белән маңгаена суга һәм йөгереп өйгә кереп китә.)*

В ә л и. Йолдыз! *(Миңгаян киткән якка карап торганнан соң.)* Нишләгән бу? *(Ашыгып сәхнә артына кереп югала.)*

Сәхнәнең өй эче ягы.

М и ң г а я н *(көзге алдына барып галстугын рәтли).* Ничек килешә! Нинди матур! Ә икенче яктан нинди зур кайгы. *(Уйлый.)* Нишләргә? «Мин аны тотып яптырыр идем» диде дә бит Вәли. *(Уйлый.)* Дөрестән дә шулай түгелме? Вәли дөрес әйтә, бугай? *(Кайгырып галстугын тота.)* Ә эти күрсә нәрсә әйтер икән? Әй, нигә куркырга соң. Курку пионер эше түгел. *(Шул вакыт көянтәчиләкләрен күтәреп сөйләнә-сөйләнә Мәрфуга кайтып керә.)*

М ә р ф у г а. Кай җәһәннәмендә йөрисең син, Мингаян? Атаңа кирәк булдың — юк. Үземә кирәк булдың — юк.

М и ң г а я н. Мин клубта идем, әни.

М ә р ф у г а. Шул клубыгыз да бетмәде инде. *(Сулы чиләкләрен куя.)* Атаңның гадәтен беләсең ич.

М и ң г а я н *(шатланып галстугын тотып).* Әни, күрәсеңме, мин кем булдым? *(Әнисен барып кочаклый.)*

М ә р ф у г а. Әй, кызым, кызым! *(Башыннан сөя.)* Нигә болай үз белдегең белән йөрисең син. Башта атаңан белән киңәш итәргә кирәк иде.

М и ң г а я н *(үпкәләп).* Сиңа киңәш итсәң, юк-бар артыннан йөрмә дип кепә җибәрәсең. Ә эти... *(Күңелсезләнеп.)* Эти булса, сөйләшеп тә тормый, йодрыгын гына күрсәтә.

М ә р ф у г а. Этиеңә ни күзебез белән күренербез, балам. Атаң күркә кебек бит ул, бер дә кызылны яратмый. Нишләрбез, кызым, нишләрбез? Аның холкын беләсең ич, кыргый ат кебек бит.

М и ң г а я н. Әллә ни булмас әле, әни, күп булса, бер кыйнар да бетәр.

М ә р ф у г а. Булмас микән, кызым! Әллә нигә күңелем куркып тора. Бүген ямьсез төшләр дә күреп бетердем шунда.

М и ң г а я н. Кайгырма, әни, берни булмас. Юк-бар төшләргә ышанма син. *(Дәрескә йөри торган сумкасын ала.)* Әни, мин хәзер почтарь Гариф абыйга барып га-

зеталарны алып кайтып куйыйм әле. Иртәгә таңнан чәчүчеләр янына илтергә булыр. *(Ашыгып чыгарга барганда ишектә атасы белән очраша. Салихҗан исерек. Ул Миңгаянны булмә эченә төртеп җибәрә.)*

Салихҗан. Кая таймакчы буласың? Әйдә өйгә! *(Галстукны күреп.)* Ә, тү-тү, бу ни бу? Атаңнан узып син пионер булдыңмыни? Күз алдымда тотма! Хәзер үк сал да мичкә ыргыт!

Миңгаян. Салмыйм, салыр өчен такмадым мин аны.

Мәрфуга. Атасы, бала белән бала булма инде, үзем рәтләп салдырырмын әле.

Салихҗан. Әле син яклашасыңмыни? Миңгаян, сиңа әйтәләр бит. Яхшы чакта ташла шул кызыл чүпрәгеңне.

Миңгаян. Минем хәзер исемем Миңгаян түгел, алмаштырдым — Йолдыз.

Салихҗан. Ә, синең эшләр шулаймыни әле. Мулла кушкан исемеңне дә ташладыңмыни... Хәзер Йолдызмы, Йолдызмы син. *(Эләктереп алып яңагына суккалый.)* Я, йолдызлар күрендеме инде? *(Миңгаян елый.)*

Мәрфуга. Шул гына калдымыни инде сиңа. Балалар белән сугышу да ирлек булдымы инде.

Салихҗан. Әллә сиңа да кирәкме? *(Мәрфуганы куып барганда ишек шакыйлар, Салихҗан кулын селтәп, кинәт туктый. Ишек артыннан: «Салихҗан абзый, без килдек»,— дигән тавыш ишетелә. Салихҗанның тавышы үзгәрә.)* Хәзер, бара торыгыз. *(Үзгәреп, йомшап.)* Әйдә, кызым Мингаян, тагын да бер генә чыгып керик әле, капчык авызын тотышырсың.

Мәрфуга. Харап булмассыз микән, карт. Бик ешайта башладыгыз.

Салихҗан. Өйрәтмә. Камыш тешләгән үрдәк кебек, теленне генә тешләп тор. *(Йомшап.)* Әйдә, кызым Миңгаян. Каладан үзеңә сатин күлмәк тә алып кайтырмын. *(Аркасыннан сөя.)* Әйдә.

М и ң г а я н. Мин чыкмыйм, хәзер мин колхоз әйберенә тиючеләр белән бергә йөрмим.

С а л и х җ а н. Ә, әле син шулаймы? Атаңа акыл өйрәтә башладыңмыни. Ах, яхшыдан яман туган нәрсә. *(Йолдызны кыйнаганда Мәрфуга арага кереп аера. Салихҗан Мәрфуганы сугып ега да җиңнәрен сызганып, яңадан Йолдызга ташлана.)* Тукта әле, мин сине кызыл чүпрәгең белән түшәмгә асып куйыйм әле. *(Йолдыз тәрәзәдән урамга сикерә.)*

М ә р ф у г а *(тәрәзәгә таба йөгереп)*. Ах, харап иттең бит кызымны, ерткыч! *(Елый.)*

ПӘРДӘ

III ПӘРДӘ

Матур итеп җыештырылган кызыл почмак. Звено сборының беткән вакыты. Балаларның кайсы газета-журнал укый, кайсы шашка уйный. Йолдыз бер читтәрәк журнал бөгәрләп, нишләргә белми, уйланып утыра. Вәли белән Рауза шахмат уйныйлар.

В ә л и. Син, Рауза, бер йөргәч хутыңны кире алма инде. Чигенмә дим, башың белән уйлап йөр.

Р а у з а. Куеп бетермәгән идем әле.

В ә л и. Инде дә бетермәдеңме? Бетердеңме?

Р а у з а *(тиз генә атын ала)*. Бе-тер-мә-дем!

В ә л и. Я, йөр!

Р а у з а. Йөрдем, бугай.

В ә л и *(ашыгыч)*. Бугай-тугае юк, димәк, йөрдең? *(Кычкырып.)* Мә, шах... сиңа!

Б е р к ы з. Шауламый гына уйнагыз әле.

Й о л д ы з *(халыкка карап)*. Нишләргә? Ике як сугыша. Берсе — колхоз малы харап була, әйт, ди. Икенчесе үз атаң харап була, әйтмә, ди. Әллә вожатыйга гына әйтергәме? *(Журналны бөгәрләп утыра.)*

В ә л и *(кычкырып)*. Йөрдеңме, Рауза?

Р а у з а *(кулына шахмат филен тоткан килеш)*. Хәзер,

хәзер. Болай йөрсәм, тегеләй була, тегеләй йөрсәм, болай була, ыһым, булды, алай була, аннан болай була, тегеләй дә. Я, йөрдем.

Вәли. Болай йөрим, ие, ие. Шулай. *(Шатланып һәм кычкырыбрак.)* Шул-лай, бер генә ход, аннан соң корольгә шах, Раузага мат була. Хәзер ничек йөрерсең икән? Әһә, мин уйлаганча йөрдең, шах корольгә, әһә, ә мат сиңа! *(Торып китә. Нур керә.)*

Вәли. Нур абый, сбордан соң һәрвакыт уйнап ала торган идек, ә бүген?

Нур. Бүген дә уйныйбыз. Мин сезнең укып, шахмат уйнап бетергәнегезне көтеп тордым.

Вәли. Беттек. Мин ике кешегә мат бирдем инде.

Кыз. Ничек уйныйбыз соң?

Вәли. Кармак салыш уйныйбыз.

Пионерлар. Кул чабып уйныйбыз, кул чабып. *(Кулларын чабалар.)*

Нур. Залга! *(Бар да чыга башлыйлар, Йолдыз кала.)* Йолдыз, син нигә адашкан үрдәк бәбкәсе кебек ялгыз калдың?

Йолдыз *(күңелсезләнеп)*. Башым авырта, абый.

Нур *(якын килеп башын тота)*. Ә күз төпләрең нигә күгәргән?

Йолдыз. Юктыр, күгәрмәгәндер.

Нур. Юк түгел, күренеп тора инде. Син, кызый, нәрсәнедер яшерәсең, ахры? *(Йолдыз эндәшми.)* Бер яңагың шешкән бит. Берәрсе кыйнадымы әллә? *(Йолдыз эндәшми.)* Отрядта Йолдыз исеме бирелгәндә сиңа нәрсәләр йөкләтелгән иде. Хәтерлисеңме? Син бу арада бик күңелсез йөрисең, авырыйсыңмы әллә?

Йолдыз. Юк, авырмыйм.

Нур. Отряд вожатые сиңа ата-анаң кебек үк ышанычлы, иң якын кеше. Әйт, кем кыйнады. Балаларның берәрсеме? *(Йолдыз эндәшми, елый башлый.)* Әллә әти, әниеңме?

Йолдыз. Әти, әни!?

Н у р. Шулаймы, этиеңме?

Йолдыз. Әти? Юк, абый, әти дә, әни дә түгел.

Н у р. Кем соң, балалармы?

Йолдыз *(аптырап уңайсызланып)*. Бал-лалар.

Н у р. Кем?

Йолдыз *(халыкка карап)*. Пионер алдарга тиеш түгел, ә мин алдыйм. *(Нурга.)* Зариф малае.

Н у р. Хәсән кыйнадымы? Атасына әйтербез, сугышырга ярамаганын аңлатырбыз, әйдә, уйнарга барыйк. *(Житәкләп алып чыгып китә. Икенче бүлмәдән балаларның кул чабып уйнаулары, көлү, сөйләшү тавышлары ишетелә. Бераздан Йолдыз керә.)*

Йолдыз. Уйный алмыйм, шаяра, шатлана, кул чапылдата алмыйм. Нишлим? Әйтимме? Әйтсәң ни булыр? Ни булсын? Этине тотып ябарлар. Мескен, әни туктаусыз елар, ходаена зарлана башлар, безне кем туйдырыр, кем киендерер? Менә бу күлмәкне дә эти алып кайтып бирде бит. Әти булмаса, кем алып бирер иде? Тукта әле. *(Күлмәген тотып карый.)* Соң бу күлмәк этинекемени? Бу соң этиләрнең колхоз амбарын талагач алып биргән күлмәк түгелме? Шул, шул, үзләренең пычраклыкларын яшереп калдырыр өчен бирелгән күлмәк бит бу. Кызыл галстук тагып йөрим. Ә үзем каракларда н бирелгән күлмәкне киям. *(Күзенә яшь килә, өстәлдәге китапны алып карый.)* Пионер законы:— пионер җәмәгать милкен күз карасы кебек сакларга тиеш, ди. Ә мин? Вәли дә әйтер идем, ди. Юк, әйтәм, үз атам булса да әйтәм. Бүген үк барам да, сельсоветка әйтәм. Юк, нигә сельсоветка? Ячейкадагы абыйга әйтәм. *(Кулындагы журналын ташлый да кызу атлап чыга башлый. Шаулашып балалар керәләр. Нур өстәлдәге газеталарны актара башлый.)*

Н у р. Беренче звенога монда да урын җитә, башлагыз!

Балалар түгәрәкләнеп тезеләләр һәм кулларын чабарга хәзерләнәләр. Вожатый кычкырып саный: 1, 2, 3, һ. б. Ул һәрбер бишенче санны әйткән вакытта гына кулны чабарга кирәк, мәсәлән, 5, 10,

15, 20, 25 һ. б. Вожатый бишенче санны әйткәндә кулын чаба. Барда вожатыйга ияреләр, аның хәрәкәтен кабатлыйлар. Вожатый нинди булса да бер санны әйткәннән соң кулын зур итеп җәя дә тавыш чыгармый гына бер-берсенә якын китерә, ләкин чапмый, уйнаучыларның кайберләре аңа иярeп кулларын чаба башлыйлар. Бу вакыт кем ялгышып кулын чапса, шуңа берәр төрле эш кушыла: мәсәлән, бию, җырлау, шигырь сөйләү кебекләр.

Р а у з а. Иптәшләр, Йолдыз нишләп уйнамый?

В ә л и. Ул мин чакырганны көтә торгандыр.(*Йолдыз янына килә, аны түгәрәккә алып килеп куша, уен башлана.)*

К ы з. Иптәшләр, Йолдыз бишенче санны әйткәндә кул чапты.

В ә л и. Нинди «җәза» бирәбез?

К ы з. Биергә, матур бии бит ул.

В ә л и. Гариф, син гармонь ал. *(Гариф бию көен уйный башлый, Йолдыз биеми.)*

К ы з. Я инде, Йолдыз, ялындырма.

В ә л и. Каршыңа үзем чыгармын. *(Тыпырдап ала.)*

Й о л д ы з. Булмый. Аякларыма әллә ни булган.

Г а р и ф. Мә, иканчесен алайса. *(Кыска, җиңел көй уйный башлый.)*

Н у р *(газетадан кулын алып.)* Менә сиңа кирәк булса пионерка, ялындырып тора. Ничек оялмыйсың?

В ә л и. Биюче була торып ничек түзәсең? *(Биеп китә. Йолдызның каршысына барып бии.)* Ярышка чакырам.

Б а л а л а р. Я инде, ярышны да санламыйсыңмыни?

Й о л д ы з. Ярышкамыни? *(Күңелсезрәк кенә биеп китә, акрынлап кыза. Соңыннан аяклары җәелгән килеш кинәт туктап кала. Гармонь уйнаучы аның туктаганын белмичә зур дәрт белән уйный бирә, үзе сөйләнә).*

Г а р и ф. Менә шулай, Йолдыз, сер сынатма, шулай. *(Вәли биегән кебек аягын дөбердәтеп тора, Гариф аны сизми. Йолдыз бии дип һаман сөйләнә.)* Пулемет шикелле тыкылдата. Ай, молодец, Йолдыз. *(Кызуырак уйный. Балаларның көлүенә кинәт туктап борылып карый.)* Туктадымы әллә?

Р а у з а. Нигә туктадың инде?

Б а л а л а р. Бие инде, Йолдыз, бие *(шаулашалар).*

Й о л д ы з. Аякларым бии, ә менә күңелем... биеми.

Б а р д а. Ник?

В ә л и. Аңлашылмый, аңлашылмый. *(Рауза аның кабыргасына төртә.)*

Й о л д ы з. Артык яшерә алмыйм. Мине биюдән туктатуның серен әйтәм... *(Пионерлар Йолдызны сарып алалар.)* Тик хәзергә аны абыйга гына әйтәм, аннан сез дә белерсез, зур эш ул.

Н у р. Сез уйный торыгыз, без хәзер керербез. *(Нур белән Йолдыз чыгалар, балалар аларның артларыннан карап калалар.)*

Р а у з а. Нәрсә булды икән?

Б а р д а. Әйе шул, нәрсә әйтер икән?

Қ ы з. Минемчә, пионердан чыга торгандыр.

В ә л и. Тәрәзә ватты микән әллә?

Р а у з а. Булмас, акыллы кыз ул.

В ә л и. Авырый мәллә?

Қ ы з. Әй, чыннан да ул авырганга охшый.

I м а л а й. Кыйнаганнардыр аны, яңагы шешкән ич.

Б а л а л а р. Кем кыйнады икән?

Қ ы з. Вәли түгел микән?

Р а у з а. Вәли сугышмый ул.

В ә л и. Бөтенләй ук түгел. Кешесенә карап.

Қ ы з. Әйттем бит.

В ә л и. Әйттен. *(Рауза аңа төртә.)* Йолдыз кеше ич, нигә мин аны кыйныйм. Кешесенә карап дим ич мин.

Қ ы з. Я, кем белән?

В ә л и. Менә фашистлар сугыш башласалар, Вәли борынын тартып кына йөрер дип уйлыйсыңмы? Мин... *(Аны бүләләр.)*

I м а л а й. Вәлигә тимәгез, Вәли шәп ул.

Р а у з а. Әйдә, Вәли, без тагын көчне сынашып карыйк әле. *(Шахмат уйный башлыйлар.)*

II м а л а й. Әйдәгез, уенны дәвам иттерик. *(Бар да*

таралып «кул чабу» уенын уйный башлыйлар. Кыз кулын өч дигәндә чаба да аңа «җәза» бирәләр.)

Кыз. Әһә, эләкте.

I малай. Җырларга! *(Бар да җырларга диләр, Гариф гармонь уйный.)*

Кыз.

Тау башында пар каен
Яфрак яра ел саен,
Яфрак ярган каен кебек
Без үсәбез көн саен.

Ишектән Нур белән Йолдыз керәләр. Йолдызның күңеле бераз күтәрелгән. Балалар Нур белән Йолдызны сарып алалар. Безгә дә әйтегез, нәрсә булган, диләр. Нур кулындагы газетасын селкә-селкә сөйли башлый.

Нур. Иптәшләр, тыныч булыгыз, хәзер барын да белерсез. Менә газетада бер зур хәбәр бар. *(Йолдыз журналны кулына тоткан килеш тыңлый. Вәли һәм Рауза уйнап утыра. Вәли еш кына пешкаларны кузгатмадымы икән дип шахмат тактасына һәм Раузага карый, бармак селкеп куя.)*

Кыз. Ни бар, абый?

Вәли *(җанланып)*. Әллә күрше отряд шахматчылары киләме? Мат бирер идем үзләренә.

Нур. Юк, алай түгел.

Кыз. Я инде, абый, укы инде.

Балалар. Әйт инде...

Нур *(тамагын кыра)*. Менә монда...

Вәли *(чыдый алмый)*. Я инде, тизрәк бул.

Рауза *(җиңеннән тарта.)* Онытма!

Нур. Тыңлагыз. Мари республикасы пионерлары зур батырлык күрсәтәләр. *(Укый.)*

«Атлар сараенда».

«Скатовка пионерлары колхоз ат сараен күзәтеп тору өчен постлар оештырганнар. Бу постларга ат сараеның чисталыгын, атларны ашату, тәрбияләү, дөрес эшләтү кебек эшләрне күзәтү йөкләнгән. Шулай бер вакыт Саша

һәм Гена исемле ике пионер колхоз ат сараен карарга киткәннәр. Конюхларга үзләренең отрядтан шундый задание белән килүләрен аңлаткач, конюхлар бу ике пионерны типкәләп чыгарганнар».

Кыз. Әй, мескеннәр.

Вәли. Нинди кешеләр бар, ә!?

Нур. «Ләкин пионерлар конюхларның ат сараена кертергә теләмәүләренә карамастан, ат сараена кергәннәр һәм анда чәчләр үрә торырлык тәртипсезлек күргәннәр. Ат сараенда пычрак булган, атлар чистартылмый торганнар, конюхлар печән урынына чергән силос биргәннәр. Корчаңгы атлар таза атлар белән бергә торганнар. Саша һәм Гена болар турында шул ук көнне отрядта сөйләгәннәр, отряд бу турыда тиешле җиргә хәбәр иткән».

Вәли. Шәп иткәннәр.

Кыз. Әх, пионерлар белән сөйләшсәң!

Нур. Ул гына да түгел. Теге ике конюхның эшен тикшергәч, бер ел эчендә генә дә бу ике конюх карамагындагы 3 ат үлгәнлеге ачылган.

Рауза. Менә Саша кебек булсаң иде.

Кыз. Бездән буламы соң ул?

Вәли. Нигә булмасын. Менә мин... *(Аны бүләләр.)*

Нур. Искиткеч эш юк, иптәшләр. Һәр пионер да Саша белән Гена кебек булырга тиеш. Хәзер аның кебек геройлар бездә дә бар инде.

Кыз. Ничек абый, безнең отрядтамы?

Нур. Әйе.

Вәли. Ничек, безнең арадамы?

Нур. Әйе, балалар, ул герой хәзер сезнең арагызда.

Рауза *(шатланып)*. Чынлапмы, абый?

Нур. Безнең отряд героеның эшләгән эше ул пионерларныкыннан да зур. Ул герой колхоз малын урлаучы үзенең туган атасын тотып бирде.

Кыз. Кем ул?

Рауза *(түземсезлек белән)*. Кем инде ул, абый?

Нур. Үзегез табыгыз. Я, карагыз, кем булыр икән?

Балалар бер-берсен тикшереп карыйлар, бөтенесенә карап «Юк, ул түгел» дигән мәгънәне аңлатып кулларын селкәләр. Вәлигә житкәндә барысының да күзе туктый. Вәли күкрәген киерә, йөзенә житди төс кертә, чәчен сыпырып жибәрим дигәндә кулындагы шахмат тактасын төшереп чәчә.

Вәли. Ул — мин. Мин отрядтагы барлык пионерларга «мат» бирә алам. Мин ул герой.

Балалар. Абый, Вәлимени?

Нур. Түгел. *(Вәли шахматын жыя.)*

Балалар. Кем соң ул герой?..

Нур. Әйтсәм әйтим инде. Әнә ул кем! *(Нур башын иеп, журналны йомарлап тоткан Йолдызга күрсәтә. Балалар Йолдызга таба әйләнәләр. Аларның йөзләре ачыла.)*

Рауза *(бик нык шатланып, йөгереп Йолдыз янына бара һәм аны кочаклый)*. Ә, безнең Йолдыз!

Бар да. Отряд йолдызы.

ПӘРДӘ

IV ПӘРДӘ

Жәй. Авыл чите. Уң якта басу киртәсе һәм кыр капкасы күренә. Пәрдә ачылуга Вәли йөгереп керә дә сәхнә уртасында туктап башын сузып карый, шуннан тиз генә киртәгә менеп, ике кулын бинокль кебек түгәрәкләндереп, күзәтә башлый.

Вәли *(каты кычкырып)*. Киләләр, киләләр. *(Килергә өндәп шул якка кулын селки. Ул арада саф белән тезелеп 5—6 пионер керәләр, алда кызыл байрак тоткан Йолдыз, аның артыннан быргычы, барабанчы.)*

Нур. Киләләрме, еракмы?

Вәли *(карый)*. Киләләр, килеп тә житәләр инде.

Пионерлар капка төбенә киләләр, киртәләргә менәләр, алдан сакчы, аннары Салихжан, амбар каравылчысы, завхоз керә башлыйлар, сәхнә уртасына житкәч, алдагы сакчы туктый.

Сакчы *(торкыннарга)*. Туктарга! *(Алга карап.)* Читкә китегез, балалар, күрмисезмени, кулга алынучы-

лар. *(Пионерлар юл бирәләр, карыйлар. Аптыраган Вәлигенә киртә башында кала).*

Вәли. Йолдыз, әтиеңне шәһәргә кунакка алып китеп баралар.

Рауза. Йолдыз, әтиең белән саубуллашмыйсыңмы?

Йолдыз. Юк, колхоз дошманына кул бирмим мин. *(Тоткыннарны алып чыгалар.)*

I кыз. Әйләнеп кайткач тагын кыйнамаса ярый инде.

Йолдыз *(тегеләрнең артыннан).* Пионерларны танытмый кайтармаслар шул инде аны.

Рауза. Дөрес, Йолдыз. Аларны акылга утыртмыйча кире кайтармаслар шул. *(Киртә башындагы Вәли яңадан киләләр, киләләр, дип шатланып бик каты кычкыра башлый.)*

Нур. Тезелергә!!! *(Пионерлар сафка тезеләләр, килүчеләр ягына карап быргычы каршылау сигналын бирә, ул туктауга җавап итеп, арттан быргы тавышы ишетелә.)*

Вәли *(киртәдән төшә-төшә).* Иптәшләр, сер сынатмыйк, отрядыбызның алфавитның «А» сында торуын онытмыйк!

Нур. На месте шагом марш! *(Йолдыз җыр башлый. Отряд «Яшь барабанчы»ны җырлый.)*

Җыр:

Булдык без каты сугышларда,
Үттек без туплар ялкынын.
Алга бардылар безнең сафлар
Дошман сафлары аркылы.

Бар иде бер яшь барабанчы
Безнең сафыбыз эчендә,
Алдан барды ул походларда
Байлар бандасы өстенә.

(Туктыйлар.)

Шул вакыт сәхнә артыннан пионерлар маршы ишетелә. Сәхнәдәгеләр туктыйлар. Паузадан соң басу капкасыннан күрше рус авылы пионерлары отряды вәкилләре керәләр һәм капка төбендә татар отряды звеносына каршы тезелгән килеш туктыйлар, һәр ике як бердән салют бирә.

Р у с п и о н е р л а р ы. Привет, привет, привет!

Т а т а р п и о н е р л а р ы. Сәлам, сәлам, сәлам!

В а л я *(бер адым алга чыга. Кулындагы байрагын югары күтәреп)*. Иптәшләр, бөтен республикага билгеле булган сезнең Йолдыз отрядына — бездән — рус кызыл галстукчыларыннан пионерларча сәлам! *(Ике як та салют бирә. Быргылар тәбриге.)* Социалистик милекне саклауда, үз-үзен кызганмый зур батырлык күрсәтүче Йолдыз безнең дә отрядның йолдызы булып яна. Аның батырлыгы турында укыгач, безнең отряд эше дә җанланды. Аның батырлыгы безгә үрнәк булып тора. Сәлам сиңа, кызыл галстукчылар йолдызы!

Б а р д а. Сәлам!

В а л я. Без сине, Йолдыз, кунакка алырга һәм эшегез белән таныштырга дип килдек. Кызыл галстукчылар йолдызына, «Ленин» отрядына бездән бүләк. *(Уртасына Ленин рәсеме куелган зур кызыл йолдыз суза, аны звено вожатые — Йолдыз ала. Һәр ике якның быргычылары, барабанчылары быргы белән тәбриклиләр.)*

Й о л д ы з. Без эшчеләр эше өчен көрәшкә һәрвакыт...

Б а р д а. Хә-зер!

Н у р. Кадерле кунаклар, әйдәгез, безнең колхозга киттек, марш! *(Барысы да авылга таба борылалар һәм «Яшь барабанчы»ны җырлап чыга башлыйлар.)*

Булдык без каты сугышларда,
Үттек без туплар ялкынын.
Алга бардылар безнең сафлар
Дошман сафлары аркылы.

1935

ШИГЫРЬЛӘР

ТУГАН ИЛГӘ

Булгач давыл ничек шауламасын,
Чайкалмасын камышы,
Ярсый йөрәк, дулкынлана, —
Авыр-авыр сагышы!

Беренче кат күзем кояш күргән
Җирләр ерак калды.
Тирә-ягым көзге болыт кебек
Кайгы чорнап алды.

Туган илем, барлык рухым сиңа,
Барсы синең өчен!..

Якынлыгың синең белмәдем мин
Ерак китми торып,
Ничек яшьлек тәмен без белмибез
Картлык килми торып!

ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҖЫР

Әйтсәләр дә: барып тор син, дип,
Дөньяның иң рәхәт җиренә.
Әйтер идем: кирәк түгел, дип,
Кайтам мин, дип, туган илемә.

Әйтсәләр дә: алтын сарайда тор син,
Ләкин илең ирексез калсын, дип,
Әйтер идем: мине зинданга сал,
Фәкать илем ирекле булсын, дип.

Ничек тели җаның, шулай яшә,
Кара кашлы кызлар үзеңә
Дисәләр дә, әйтер идем: кирәк түгел,
Кайтам мин, дип, зәңгәр күземә.

Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын;
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер ватанын.

ИКЕ УЛЫМ БАР

(Алмаз белән Айвазга)

Һәрбер эшне җитез эшли торган
Корыч кебек ике улым бар,
Ике кулым кебек үсеп килгән,
Булышчым бар, ике улым бар.

Ике күзем минем үткен күз,
Күрә кайда дошман посканын,
Ике күзем кебек ике улым
Сизгер саклар илнең постларын!

Шуышмасын дошман тирә-якта,
Колакларым яхшы ишетә,
Мин үлсәм дә, ике улым кала
Алар ишетер икесе ничек тә.

Ике аягым минем чыдам булды
Ерак поход чыккан чакларда.
Аякларым кебек ике улым да
Сынатмаслар әле ятларга!

ӨЧЕНЧЕ КӨЗ

Саргаешып каен яфраклары
Өченче кат җиргә коела.
Өч кенә ел үтте микәнни соң?
Ун ел үткән кебек тоела.

Ил бәйрәмен инде өченче кат
Тоткынлыкта, читтә үткәрәм.
Бер файдасыз, дуслар, үтә гомер,
Бушка үтә-үтә, әй әрәм!

Бүген тагын инде өченче кат
Килеп җитте менә ул бәйрәм,
Хыялымда бергә бәйрәм итәм,
Дуслар белән бокал күтәрәм.

Дүртенчесен инде насыйп булсын
Каршыларга мул бер табында.
Балаларым, иркәм белән бергә
Чөкердәшеп өстәл янында.

ОЧКЫЧКА КАРАП

Һәр көн саен иртән баш түбәмнән
Очкыч очып китә еракка,
Бик еракка — кояш чыккан якка,
Бары тавыш кала колакта.

Ал син, очкыч, мине үзең белән,
Канат аска шунда сыендыр,
Кеше гомерен чикли торган йөктән
Мин дә бәлки авыр түгелдер.

Күтәрелим әле биеклеккә,
Төкереп үтим дошман башына.
Мотор белән йөрәк кушылсыннар,
Тотынсыннар бергә ярсырга.

Ал син, очкыч, мине үзең белән,
Бомбаларың калдыр бүгенгә,
Бомба итеп илтеп ташла мине
Ерактагы торган илемә.

Йолдыз кебек атылып төшим әле
Туфрагында кабер табарга.
Дошманнарга булган көчле нәфрәт
Хисе белән мәңге янарга.

Юк, кирәкми, үлмим, табыш булып
Кайтып керим туган илемә.
Багышласын калган гомерем дә
Иң кирәкле булган җиренә.

НИЧЕК КИЛЕР ҮЛЕМ

Көрәш куа утлы давыл бөркеп,
Үлем кайный тирә-ягымда.
Ничек килер үлем? дигән сорау,
Һич килмәде минем башыма.

Шаян угы кургаш кисәгенең,
Туры килсә минем йөрәккә,
Калган булыр идем авып шунда,
Ирешә алмыйча изге теләккә.

Явыз ачлык үзенең канлы кулын
Күп уйнатты минем тирәмдә,
Тимер чыбык белән уратылган
Хәтфә кебек яшел чирәмдә.

Үлеп калган булсам инде күптән,
Азык булыр идем кортларга,
Тоткын булып кабат килмәс идем,
Менә мондый салкын йортларга.

Хәзер үлем тагын басып тора,
Баш очымда кайрый хәнҗәрен,
Тик белә алмыйм, тешне кысып
Сыкрый-сыкрый, дуслар, үләрмен.

Китмәс ахры бер кат минем яннан
Шартлап тора һаман кичләрен.

Янгын чыгып, янып үләрменме?
Белмим инде, ничек үләрмен.

Гильотинмы кисәр газиз башны,
Искәртмәстән яки атарлар,
Ачлык белән буып үтерерләрме
Яки биек дарга асарлар.

Ничек килер үлем — белеп булмый,
Тик билгеле шунсы хәзергә;
Тынмас ахры мине алып китми
Үзе белән салкын кабергә.

Ни булса да горур үлем бит ул,
Европаның урта өлешендә.
Мондый үлем — бәхет. Теләсә дә,
Тими әле бик күп кешегә.

Күпме кәгазь языла безнең хакта,
Бәлки кабат аны укырлар.
Иптәше өчен кеше корбан була,
Шундый инде безнең гасырлар.

Көрәш белән тудык, көрәш белән
Керәбез дә ахры кабергә.
Язган икән соңгы сулышыбызны
Илебез бәхете өчен бирергә.

ЯРКАНАТ

Көн буе ачка интегеп
    Йоклый ярканат,
Кайчан кара төн туар дип
    Ярыктан карап.

Мин, ярканат кебек, һич тә
    Яктыдан качмам.
Иркәләп сөйгән кояшка
    булмамын дошман.

Мин барамын якты көнгә
    Ачык йөз белән,
— Хуш киләсез, кәләч иртә,—
    Дигән сүз белән.

Шул таң белән кояш кайта
    Манчылып нурга.
— Сәлам туган авылыңнан!—
    Дигәнсыман миңа.

КӨТМӘ ИНДЕ, КӨТМӘ...

(Әнигә багышлыйм)

Әнә үрдәк бәбкәләре белән,
Ә син ялгыз үзең барасың,
Син көнләшеп аның бәхетеннән
Моңсу гына озатып каласың.

Кайда китте синең балаларың?
Арслан күк батыр улларың?
Өмет белән һаман күзәтәсең,
Кайтырлар, дип, киткән юлларын.

Былтыр койган алма какларын син,
Чикләвекләр җыеп киптереп,
— Аларга!— дип, һаман саклыйсыңмы
Сагыш белән көтеп тилмереп.

Төшләреңдә һаман алар белән,
Көндезләрен укып хатларын,
Теткәләнгән кәгазь битләренең
Һәрбер сүзен инде ятладың.

Язлар килер чәчәк исе бөркеп,
Сыерчыклар кире кайтырлар,
Яңарырлар шунда йөрәгеңдәге
Бертуктаусыз янган кайгылар.

Бал кортлары очар, күбәләкләр
Берсен-берсе куышып уйнарлар,
Чәчәкләргә күмелеп торсалар да
Куандырмас сине тугайлар.

Җир тетрәгән давыл уты бәлки
Карлар белән эреп югалыр,
Дөнья тынып калыр. Йөрәкләрдә
Кавышу хисе кабат кузгалыр.

Өчесенең берсе кайтмасмы дип,
Син көтәрсең һаман аларны,
Ишек каккан саен кочакларга
Хәзерләнеп сөйгән балаңны.

Көтмә инде, көтмә, изге карчык,
Җир куенында ята улларың,
Чәчәкләргә биреп илгә булган
Мәхәббәтле керсез уйларын.

ОЧРАШУ

Әсирләр лагеренда бер иптәшем белән фаҗигале очрашуга карата язылган бу шигырьне күп әсирләр үзләренең дәфтәрләренә күчереп алганнар иде.

...Хәтерләдек ерак туган илне,
Семьяларны, якын дусларны,
Хәтерләдек җырлап исәнлеккә
Күтәрелгән тулы тостларны.

Туган илдә ничек сыйланулар,
Коштай иркен йөргән вакытлар,
Барсы инде, барсы ерак калды,
Илдә үткән татлы минутлар.

Ах, кайда сез, безне тәрбияләп
Үстерүче изге аналар,
Ах, кайда сез, сарылып елый-елый
Озатып калган сабый балалар.

Ах, кайда сез, безнең нечкә билләр,
Эштә чыныгып үскән аталар,
Ах, кайда сез, энекәш, сеңелкәйләр.
Ах, кайда сез, абый-апалар.
Сезнең якын күргән кешеләрегез
Тилмерешеп монда яталар.

Хат-хәбәр юк, үлде ахры диеп,
Ашыкмагыз дога кылырга,
Авыр үлем белән көрәшәбез,
Исәп әле тере калырга.
Теләгебез, сыерчыклар кебек,
Тагын илгә очып кайтырга,
Сезнең белән елап күрешеп,
Тагын бергә рәхәт татырга.

КОШ АУЛАУЧЫ

Иксез-чиксез бөек Рус иленең
Сузылып киткән киң кырларында,
Гөлгә чумып торган тугаенда,
Шаулап торган урманнарында
Тоткынлыкның ни икәнен белми
Бер сандугач гомер кичергән.
Таңны җырлап һаман каршылаган,
Тынмаган ул хәтта кич-иртә.
Мактаган ул бөек иреклекне
Ләгънәт укып богау-чылбырга.
Тоткынлыкның барсы-барсына...
Беркөн шулай өзелеп сайраганда
Сандугачны тоткын иткәннәр,
Читлек эченә ябып куйганнар да,
Сайрасын! дип боерык биргәннәр.
Тоткын сайрамагач рәнҗеткәннәр,
Таяк белән төртеп көлгәннәр...
Ул бичара бер дә сайрамаган,
Йөрәге сагыш белән тулса да.
Түзгән мескен барлык кыенлыкка,
Көннән-көнгә һаман сулса да.
Кош аулаучы егет хәйран калган,
Сандугачны моңсыз дип белгән.
Хаҗәте юк моның ишеңең дип,
Тоткын кошны азат иттергән.
Менә шунда безнең сандугачкай

Ирек яклап сипкән моңнарын,
Хәтерләгән үзенең урманнарын,
Гөлгә чумган матур тугаен.
Еллар үткән...
Әлеге кош аулаучы
Мылтык тоткан көчле кулына,
Дошманнарга каршы чыгып киткән
Илне яклап — сугыш кырына.
Дошманнар безнең бу егетне
Сандугач күк тоткын иткәннәр,
Тимер чыбык эченә бикләгәннәр,
Ирегеннән мәхрүм иткәннәр.
Менә шул чак егет хәтерләгән
Аулап кайткан үзенең тоткынын,
Һәм елаган үксеп баса алмый
Йөрәгенең көчле дулкынын.
Менә шунда егет антлар иткән
Ирек кошларына тимәскә,
Кошлар ауламаска, читлекләргә,
Ятьмәләргә якын килмәскә.

КОЯШ КАРШЫЛАУ

Мин адаштым юлдан, төн карангы,
Белмим, нидер китэм.
Кайда икэн минем якын дуслар?
Кайда минем иркэм?

Басып торам текэ яр читендэ,
Карыйм тирэ-якка,
Шул чак янгын кебек алсуланып
Батыр кояш калка.

Кулы белэн нэфис пэрэнжэсен
Акрын ачкансыман,
Тирэ-ягын һаман яктылата,
Күтэрелэ томан.

Тормыш чишмэсенең горур адымын
Тэбриклилэр кошлар,
Чэчэклэрдэн ява бертуктаусыз
Рэхмэтле алкышлар.

Кызганмый ул — минем өскэ
Сибэ көлэч нурын,
Хэтерлэтеп анам иркэлэвен,
Аның йомшак кулын.

Уртаклашам йөрэк кайгыларын
Мин дэ аның белэн,

Кояш бабай, барыр юлым кайда?
Дигән сорау бирәм.

— Әнә минем нурлар,— ди ул миңа,—
Курыкмый һичбер нидән.
Шулар кебек син дә батыр бул,
Үрнәк алып миннән.

Төн артыннан көннең туарына
Ышанычың тирән.
Китәр кайгы, килер шатлык тиздән,
Тиздән, тиздән, иркәм.

Барыр юлың үлем,— ди ул миңа,—
Мин калыккан чакта
Ыргыт йөрәгеңнән кайгыларны,
Үлеп минем хакка.

Шунда синең дуслар, якын анаң,
Шунда синең иркәң,
Һәр көн саен кайнар сәламеңне
Мин аларга илтәм.

Саубуллаша, үрли югарыга,
Ә мин түбән калам,
Алып килә төсле җылы нурлар
Туган илдән сәлам!

———

ТУГАН АВЫЛ

(Иптәшем альбомына)

Дөнья гиздем — табалмадым һичкайда,
Сөйгән туган авылым Балыклы,
Синдәгедәй мул бер байлыкны,
Җир күкрәтеп уңган ашлыкны,
Синдәгедәй гадел халыкны,
Синдәгедәй юмарт халыкны,
Очратмадым һичбер вакытта...

ЭЧТӘЛЕК

Язучы һәм көрәшче *Г. Кашшаф* 3
Якты истәлек *А. Әхмәт* 19

ӘКИЯТЛӘР

Сертотмас үрдәк 25
Капкорсак патша 30
Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар 44
Нечкәбил 46
Кем көчле? 57
Койрыклар 68
Эт үзенә ничек хуҗа эзләгән 74
Ил гизүчеләр белән хәйлә сөючеләр 77
Ялкаулык — хурлык, тырышлык — зурлык 81
Песиләр һәм күселәр 84
Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык 86
Бик яхшы сабак алды ябалак 89
Бикбатыр белән Биккуркак 92
Бозлар — явызлар 94
Бай белән ялчы 112
Староста белән шайтан 115
Каз белән Аккош 117
Куян кызы 119
Чукмар белән Тукмар 121

ХИКӘЯЛӘР

Термометр 125
Кадыйр Бикмурзинның җинаяте 131
Кадерле бүләк 141
Берлин 145
Чуар тавык 150
Энче абый 160
Кешеләр нишлиләр 163
Әбиләргә кунакка 166
Утлы йомырка 169
Кара карганың кара баласы 171
Кемгә кирәк, кемгә кирәкми? 173

ПЬЕСАЛАР

Сертотмас үрдәк 177
Йолдыз 201

ШИГЫРЬЛӘР

Туган илгә 221
Үзем турында жыр 223
Ике улым бар 224
Өченче күз 225
Очкычка карап 226
Ничек килер үлем 227
Ярканат 229
Кетмә инде, кетмә 230
Очрашу 232
Кош аулаучы 234
Кояш каршылау 236
Туган авыл 238

А. АЛИШ

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

(на татарском языке)

Художество редакторы *Э. Е. Дьячкова*

Техник редакторы *Р. С. Нәбиуллина*

Корректорлары *Р. С. Хәмидуллина, Р. Г. Шәрәфиева*

Наборга бирелде 31/I-1957 ел. Басарга кул куелды 17/IV-1957 ел. 07575.
Кәгазь форматы 84×108¹/₃₂. Учет.-изд. таб. 8,94+рәсемнәре 0,29 табак.
Басма табак 15,0 (12,3)+рәсемнәре 0,75 (0,61) табак. Табакта 44.000 хәреф.
Заказ № 049. Тираж 15.000. Бәясе 5 сум 75 тиен.

ТАССР Культура Министрлыгының Татполиграф типографиясе.
Казан, Миславский ур., йорт № 9.